# ШУРА

№ 39
2023

## 2023 Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы

2000999960642

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

**«ШУРА» дини альманах, №39**

*гыйнвар–март 2023*
*җөмәдәл-ахыр-Рамазан 1444*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Ленар Хамматов
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Айсылу Юлдашева

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Гөлназ Ситдикова

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ООО «Медиа Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420021, Казан шәһ., Г.Камал ур., 53-46.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 08.12.2022
Чыгу көне: 26.12.2022

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый.*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала.*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на
татарском языке

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
«Бишектән алып, ләхеткә кадәр гыйлем алыгыз» . . . . . . . . . . 15
Раҗәб – Аллаһының ае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
«Әйт мөэминә хатыннарга…» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Кыямәт көнендә соралачак нәрсәләр . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Тәвәккәллек күрсәтүче кукпә ирешә . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Исра вә Мигъраҗ – Раббыбызның бүләге . . . . . . . . . . . . . . 43
Тәкәбберлек – гөнаһларның башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Бәраәт кичәсе – догада булу вакыты . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Рамазан ае – зур мөмкинлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Рамазанункөнлекләренең хикмәте . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Рамазан ае – кадерле кунак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Гафиллектән ерак булыйк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Гайбәт сөйләүнең афәтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Октябрь-Ноябрь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89

НӘСЫЙХӘТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Тәүбә бәянының икенче бүлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105

ҮРНӘК ЗАТЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123

ФӘТВАЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Намазда Коръән укудагы хаталар . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ❁ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ❁ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ❁ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ❁ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ❁ دَاعِينَا إِلَى اللهِ❁ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ❁ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ❁ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ❁ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ❁ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ❁ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ!❁ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ❁ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ❁

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللَّهِ:

______________________________ ❁

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ:

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞
أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا

بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

---

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин», – дип әйтә.

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусҙмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ______________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ______________________________

______________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибраaһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибраaһиимә вә галәә әәли Ибраaһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә

вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә'мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин», – дип әйтә.

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[1] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары, элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

> **«Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһлардан] курыккан һәм [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

[1] 3 тапкыр әйтелә.

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

______________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә

сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] гадел булырга, изгелек кылырга һәм [бигрәк тә] якын туганнарга [мохтаҗ булган нәрсәләрен] бирергә [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] әмер итә. [Зина кебек] Фәхешлектән,**

**[көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] тыелганнан һәм [кешеләргә] җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*13 нче гыйнвар вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# «Бишектән алып, ләхеткә кадәр гыйлем алыгыз»

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Әйтегез әле: сезнең бер көнегез икенчесеннән нәрсә белән аерыла? Иртә белән тордыгыз: юыну, иртәнге аш, эшкә китү; эшләп кайттыгыз, барысы да киресенчә генә: кичке аш, юыну, йокларга яту. Һәр көнне бер үк әйбер кабатлана. Әмма безнең тормыш рәвешен балаларыбызныкы белән чагыштырсак, анда бер аерма бар: алар көн саен яңа нәрсә өйрәнә. Балалар бакчасы, мәктәп, университет – мөһим түгел, монда безне кызыксындырганы шул: белем алу. Көн саен белем алу!

Ник безнең тормыш шундый ук түгел соң? Ник бертөрлелеккә тиз ияләнәбез? Монысы һәрберебезнең күңел түрендә яшеренгән, бер актарып карагыз әле.

Инде аңлавыгызча, бүген сүз гыйлем алу турында булыр. Хәзер гыйнвар ае бара. Сентябрь, ягъни уку елы башланган вакыт та түгел, май ае, ягъни имтиханнар вакыты да түгел. Соң алайса ник бу айда гыйлем турында сөйлиләр, дип аптырап утыручылар бардыр. Җәмәгать, Пәйгамбәребездән гыйлем алу турында күпме генә хәдис булса да, ул гыйлем алуның ниндидер чикләрен билгеләмәде. Бигрәк тә мәктәп, университет яшеннән чык-

кан кешеләр, үзләрен гыйлем алудан берникадәр күләмдә азат дип уйлый башлый. Өй эшләре дә юк, яңа сүзләр дә ятлыйсы, ниндидер рефератлар ясап киләсе дә юк. Барысы да артта калды, барысыннан да азат, имеш. Әлбәттә, бу бары тик бер ялгышу гына, ә аның ялгышу икәнен шул ук хәдисләрдән белә алабыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бишектән алып, ләхеткә кадәр гыйлем алыгыз», – дип әйтеп калдыран. Җәмәгать, «гыйлем алырга мөмкин» дип әйтмәгән: алыгыз, дип боерып калдырган. Һәм әгәр дә хәдиснең гарәпчәсенә игътибар итсәк, анда «утлүбү» дигән фигыль килә, ягъни «таләп итегез». Берәребез безнең хакка кереп, без шуны кире кайтарырга теләсәк, без шул хакыбызны ул кешедән таләп итәбез. «Бир инде» дигән сүзләр кулланмыйбыз да, безнеке икәнен төгәл белеп, шул әйберне таләп итәбез. Ник соң алайса гыйлем белән дә шулай түгел? Гыйлем бүген безнең янәшәгә килеп үк басты. Кул сузып алырлык арада басып тора: үрел дә ал!

Инде вәгазебезнең эчтәлегенә тирәнрәк кереп киткәнче, гыйлемнең өстенлеге турында да сөйләшеп алсак буладыр. Адәм галәйһиссәламнең җиргә хәлиф буларак төшерелүе турында ишеткәч, фәрештәләр Раббыбызга мөрәҗәгать итеп, кешелек турында үз фикерләрен әйткән. Әмма Раббыбыз фәрештәләргә Адәм галәйһиссәламнең өстенлеген аның гыйлеме аша күрсәтте:

وَعَلَّمَ ءَادَمَ ٱلْأَسْمَآءَ كُلَّهَا ثُمَّ عَرَضَهُمْ عَلَى ٱلْمَلَٰٓئِكَةِ فَقَالَ أَنۢبِـُٔونِى بِأَسْمَآءِ
هَٰٓؤُلَآءِ إِن كُنتُمْ صَٰدِقِينَ ﴿٣١﴾ قَالُوا۟ سُبْحَٰنَكَ لَا عِلْمَ لَنَآ إِلَّا مَا عَلَّمْتَنَآ ۖ
إِنَّكَ أَنتَ ٱلْعَلِيمُ ٱلْحَكِيمُ ﴿٣٢﴾ قَالَ يَٰٓـَٔادَمُ أَنۢبِئْهُم بِأَسْمَآئِهِمْ ۖ فَلَمَّآ أَنۢبَأَهُم
بِأَسْمَآئِهِمْ قَالَ أَلَمْ أَقُل لَّكُمْ إِنِّىٓ أَعْلَمُ غَيْبَ ٱلسَّمَٰوَٰتِ وَٱلْأَرْضِ وَأَعْلَمُ مَا
تُبْدُونَ وَمَا كُنتُمْ تَكْتُمُونَ ﴿٣٣﴾

**«Ул [фәрештәләргә Адәм галәйһиссәламнең өстенлеген күрсәтер өчен, мәхлүкатлар ия] исемнәрнең [һәм ни сәбәпле яратылганнарын] барчасын аңа [атабыз Адәм галәйһиссәламгә өйрәтте, шуннан аларны фәрештәләргә күрсәтеп: «Әгәр сез хаклы булсагыз, менә бу нәрсәләрнең исемнәрен Миңа әйтегез!» – диде. [Фәрештәләр:] «Син [һәр кимчелектән] пакь! Бездә һич белем юк, мәгәр Син безгә өйрәткәнне генә беләбез. Һичшиксез, Син – [һәрнәрсәне] Белүче, Хикмәт иясе», – диделәр. Ул: «Ий Адәм, аларга [күрсәтелгән нәрсәләрнең] исемнәрен әйтеп бир! – диде. Ул аларга исемнәрен әйтеп биргәч, [Аллаһы Тәгалә] әйтте: «Мин сезгә: «Күкләрдәге вә җирдәге гаиб нәрсәләрне беләмен һәм сезнең ачык эшләгән вә яшерен эшләгән эшләрегезне дә беләмен», – дип әйтмәдеммени?»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:31-33

Шулай ук монда Раббыбызның Үзенең дә белүе турында әйтелеп китә һәм белемнең өстенлек булуы ассызыклана. Башка бер аятьтә Раббыбыз:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِى ٱلَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَٱلَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ ۗ إِنَّمَا يَتَذَكَّرُ أُوْلُوا۟ ٱلْأَلْبَٰبِ ﴿٩﴾

**«Әйт: «Белгән [һәм белгәне белән яшәгән] кешеләр белән белмәгән [шул сәбәпле, наданнарча эш йөрткән һәм адашу эчендә югалып калган] кешеләр тиң була аламы?» Аек акылларга ия кешеләр генә үгетләнә»,** – дип әйтә.

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:9

Гыйлемнең өстенлеген күрсәткән хәдисләргә, иншәАллаһ, алда әле тукталырбыз.

Аллаһыга шөкер, тагын бер елга аяк басырга насыйп булды. Уңышлары белән дә, борчу-кайгылары белән дә, ниндидер матур вакый-

галары белән дә саубуллаштык инде. Яңа елга нәрсә күчә соң дигәндә, һөнәрләребез, алган гыйлемнәребез күчә, дип әйтә алабыз. Кеше яңа елдан соң башлыйм дип, күпме планнар кора. Менә ул вакыт – бүген. Яңа тел, һөнәр, фән өйрәнергә телисеңме, әйдәгез, бисмилләһне әйтәбез дә, керешәбез.

Гыйлем дигәндә, динебездә дөньяви һәм дини гыйлем бер-берсеннән ерак тормый. Киресенчә, икесе бергә үрелеп барганда, без бу дөньябыз өчен дә, Ахирәтебез өчен дә бик күп файда алачакбыз. Моның турында «Шура» журналында дөньяви һәм дини гыйлем турында бик күп вәгазьләр язылды, җомга вәгазьләрендә дә күп вәгазьләр сөйләнелде. Бүгенге вәгазебез дә бер кат искә төшерү генә.

Әйдәгез, барысын да бер рәткә китерергә тырышып карыйк: үзебезнең туган чагыбызны хәтерләмәсәк тә, туган вакытта бернәрсә дә белмәвебезне аңлыйбыздыр. Безнең гыйлемебез дә, нәрсәдер эшләргә көчебез дә юк иде: бар нәрсәне дә безнең өчен йә әниебез, йә әтиебез эшләде. Надан дип әйтергә ярамаса да, тормышыбызны шул чордан башлыйбыз. Һәм акрынлап, үсә барган саен, нindидер яңа булган гыйлем алабыз: сүзләр отабыз, йөрергә өйрәнәбез. Шатланырга, елмаерга, еларга – боларның барысына да тугач өйрәндек. Бүгенге көндә әти-әниләребез янында горурланып басып торсак, йә аларның сөйләмнәрендә хаталар табып, үзебезнең үткән телебезне аларга каршы куллана башласак, шуны белик: безне йөрергә дә, сөйләшергә дә алар өйрәтте. Ә кем дә кем аларга карата ихтирамлы булырга кирәклеген белмәсә, әйдәгез, бүгеннән яңа гыйлем өйрәник:

وَقَضَىٰ رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوٓا۟ إِلَّآ إِيَّاهُ وَبِٱلْوَٰلِدَيْنِ إِحْسَٰنًا

**«Раббың сезгә Үзеннән башкаларга табынмаска, ата-анага игелек [кылырга] әмер итте».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:23

Алга таба: кеше акрынлап балалар бакчасында, мәктәптә башлангыч белемнәр ала. Гыйлем дәрәҗәсен күтәрәм дип, университетка, мәдрәсәгә укырга керә. Илебез гыйлем алу өчен шулкадәр мөмкинлекләр бирә, Аллаһыга шөкер. Һәм менә, «укып туйган» кеше, ниһаять, иреккә чыга. Менә шушы мизгелдән алып, кешенең алдагы тормышы үз карамагына кала. Һәм шушы вакыттан соң да гыйлемгә кызыксыну кимемәсен өчен, әлбәттә, гыйлемнең тормышыбыз өчен никадәр мөһим булуын аңларга кирәк. Без инде аның өстенлеген аятьләрдән күрә алдык. Әйдәгез, Пәйгамбәребезнең дә хәдисләренә тукталып алыйк. Бер хәдистә: «Бу дөнья ләгънәт кылынган. Дөньяның Аллаһыны зикер итүдән һәм аңа бәйле әйберләрдән, гыйлем иясе һәм гыйлем алучылардан кала бар нәрсәсе дә ләгънәт кылынган», – диелгән. Шушы хәдис кенә дә барыбызны да дер селкетергә мөмкин. Шул ук вакытта, Аллаһы Тәгалә өчен бу дөньяның никадәр түбән булуын, ә Аны зикер итүчеләрнең, гыйлем эстәп йөрүчеләрнең никадәр биек урында торуын күреп була.

Без көн саен эшкә йөрибез, шул ук вакытта, янәшәбездә булганнарның да тормышларына карыйбыз. Кемдер эштә безгә караганда югарырак баскычларга күтәрелгән. Яки безнең күршедә генә булган кеше бизнес ачып, баый башлаган икән, күңелдә кабат бер начар сыйфат пыскый башлый: хөсетлек хасил була. Нигә әле ул байрак, ник әле ул уңышлырак, дигән сораулар тынгы бирми. Бер караганда, һәр кеше бу сорауларны үз-үзенә бирергә тиеш, чөнки ул үзеңнең тормышыңа бер кат нәтиҗә ясап алырга этәрә ала. Кадерле җәмәгать, чыннан да, Раббыбыз кемгәдер дәрәҗә бирә икән, димәк, ул Аның вәгъдәләрен өйрәнгән. Нинди вәгъдә? Мәсәлән:

وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ ۖ

**«Шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә [нигъмәтләрне тагын да] арттырачакмын».**

«Ибраһим», 14:7

Икенче мөһим төшенчә: хөсетләнмәү, чөнки бу да безне артка гына этәрә.

Нәрсә эшләргә соң? Әлбәттә, кыска гына нәтиҗә ясап карасак, бар да үз урынына утыра ала:

1. Раббыбызның һәм Пәйгамбәребезнең әйткән сүзләрен тыңлап, акрынлап гыйлемнәребезне арттырырга: фикһ, гакыйдә, әдәп-әхлак һәм башка фәннәр буенча гыйлем алырга.

2. Без һәркайсыбыз кайда булса да эшлибез: димәк, без бу өлкәне тирәнрәк өйрәнә алабыз. Сату-алу эше, редактор, машина йөртүче, тегүче – мөһим түгел, үзеңнең эш өлкәсендәге гыйлемеңне арттыр. Шулвакыт күршеңә килгән дәрәҗә акрынлап синең өчен дә ачыла башлаячак. Без инде алдан ук, динебездә дөньяви да, дини дә гыйлем бергә үрелеп бара, аларны аермыйбыз дип сөйләштек.

3. Булган гыйлемне гамәлгә ашыру. Бүген без сезнең белән бер аятьне карап киттек:

وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ ۖ

**«Шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә [нигъмәтләрне тагын да] арттырачакмын».**

«Ибраһим», 14:7

Әйдәгез, бу сүзләр башта мәгълүмат булып кына калмасын, аларны гамәлгә ашыра башлыйк. Раббыбызга булганыннан разый икәнебезне белгертик.

4. Уку буенча план корыйк. Мәсәлән, әгәр дә без үзебезне барысын да беләбез дип санасак, искә төшерү планын ясыйк. Әгәр дә өйрәнер нәрсә бар икән, үзебезнең көчсез урыннарны барлыйк:

а) күрше хакын беләмме?

б) миңа килгән кунагымның хакын беләмме?

в) хәләл җефетемнең, балаларымның, һәм, әлбәттә, үземнең хакымны, бурычларымны беләмме?

г) тәвәккәлләргә, Аллаһыга тапшырырга, булдыра алганын эшли башларга.

Кемдер акчам юк дип, гомумән, динебезнең кайбер нигезләренә игътибар итми. Боларга зәкят һәм хаҗ керә ала. Хаҗда булган кешеләр бармы монда? Янәшәгездә андый кешеләр булса, җомгадан соң алардан сорарсыз әле: ул хаҗда булган елны ничә процент кеше хаҗга үз акчасына барган икән? Ә ничә кеше, Аллаһы Тәгалә аларга бүләк ясап, бушка бара алган? Хаҗ – ул калган гыйбадәтләр кебек, Аллаһының бүләге. Раббыбыз кемгә тели, шул кешегә бу бүләкне тапшыра. Гыйлеме булган кеше моңа ышана. Ә ышангач, моңа алдан әзерләнергә кирәк. Менә күрерсез: чын күңелдән Раббыбызның ризалыгын алырга теләп, шушы өлкәләрне дә өйрәнә башласак, Аллаһы безгә ул юлларны да ачар, һәм берәр көнне сез дә хаҗ сәфәрләренә чыгып китәрсез. Аллаһының рәхмәте киң, кодрәте чиксез.

Һәм иң соңыннан бер киңәш бирәсем килә. Кичке якта үткәрелә торган дини курсларга игътибар итегез: анда бик күп әби-бабайларны күрергә була. Алардан: «Җиңелме?» – дип сорагыз әле. Кайсысы безгә: «Әйе, улым, картайгач укырга рәхәт, эш тә юк, вакыт та күп, укы да укы гына. Бар да җиңел истә кала», – дип җавап кайтарыр икән? Уйланырга урын бар бит, җәмәгать! Бүгенге көн бар икән, ул әле иртәгә җитәчәк дигән сүз түгел – бүгеннән башлыйк.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил Әхмәтгалиев,*

*Арча районы, Хәсәншәех авылы имам-хатыйбы*

*20 нче гыйнвар вәгазе,*
*җөмәдәл-ахыр аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Раҗәб – Аллаһының ае

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Якынлашып килә торган раҗәб ае һиҗри айларның җиденчесе булып тора. Ул – тыелган ай һәм Аллаһының ае. Раҗәб аен уразалы халәттә, Раббыбыздан гөнаһларыбыз, хата-кимчелекләребез өчен тәүбә-истигъфарлар сораган хәлдә каршылау киңәш ителә. Беренче көнне ураза тотучы кешегә өч ел нәфел уразасы тоткан әҗер-савап язылачак. Икенче көнне ураза тоткан кеше ике ел ураза тоткан әҗер-савапка ия булачак. Өченче көнне ураза тотса, бер ел уразада булгандай саналыр. Ә инде Раҗәб аеның калган көннәрен дә уразада үткәрсә, ай буе ашау-эчүдән тыелып торгандай булыр.

Алдагы хәдистә Расүлуллаһ болай дигән: «Раҗәб аеның беренче көнендә тотылган ураза өч еллык (кече) гөнаһлар өчен кәффарәт. Икенче көнне тотылган ураза ике ел өчен, өченче көнне тотылган ураза бер ел өчен, ә аннары тотылган уразалар бер айның (кече) гөнаһлары өчен кәффарәт булып тора»[1].

Икенче бер хәдистә бу ай Аллаһы ае булганга күрә, «Әл-Ихлас» сүрәсен ешрак уку һәм аның хакында фикерләү хәерле, чөнки бу сүрәдә Яратучыбыз хакында әйтелә. Бу айга хөрмәт йөзеннән һәр көнне 11әр

[1] Имам Әс-Суютый, «Җәмигус-сагыйр».

мәртәбә әлеге сүрәне укырга, салаватлар әйтергә, Раббыбыз Аллаһы Тәгаләдән тәүбә-истигъфарлар сорарга һәм иман кәлимәсен кабатларга кирәк.

Айның беренче төнендә тәсбих намазын уку, шулай ук айның беренче ун көнендә 10 рәкәгатьле намаз уку хәерле булачак. Көненә 7 мәртәбә «Әл-Фатиха» сүрәсен уку һәм 100әр тапкыр «Әл-Ихлас» сүрәсен уку да хәерле гамәл булып санала.

Бу көннәрне ураза тотып үткәрү бик фазыйләтле. Айның 13, 14 һәм 15 нче көннәрендә ураза тоту авырулардан һәм хәлсезлектән котылырга ярдәм итә диелә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм раҗәб ае һәм аның өстенлекләре турында мондый сүзләр әйткән: «Раҗәб аенда күпләп истигъфар кылыгыз. Бу айның һәр мизгелендә Рәхмәтле Аллаһы Тәгалә кайбер мөэминнәрне уттан коткара. Дөреслектә, Кодрәт иясенең (җәннәттә барлыкка китерелгән) сарайлары бар, алар аша раҗәб аенда ураза тотучы кешеләр генә керә алачак»[1].

Шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Догалар кире кагылмый торган 5 төн бар: җомгага каршы төн, раҗәб аеның беренче төне, шәгъбан аеның 15 нче төне (Бәраәт киче), Ураза һәм Корбан гаетләренең төннәре»[2], – дигән.

Раҗәб аеның һәр 10 көне саен 10 рәкәгатьтән торган хаҗәт намазын уку киңәш ителә. Бу өч намаз да бер төрле башкарыла. Аерма намазлардан соң укыла торган догаларда гына. Раҗәб ае дәвамында 30 рәкәгать намаз укыган кеше хакыйкатькә ирешер һәм бу кешеләрнең калебләре үлмәс. Мондый намазның булуы хакында Сәлман Әл-Фариси радыяллаһу ганһе тапшырган. Бу намазларны кичке яки төнге намазлардан соң укырга мөмкин, әмма аларны җомгага яки дүшәмбегә каршы төндә, бигрәк тә

[1] Имам Дәйләми, «Мөснәдел-Фирдәвес».

[2] Имам Әл-Бәйһакый, «Шүгабел-иман».

тәһәҗҗөд намазы кергән вакытта уку хәерлерәк.

Хаҗәт намазын уку тәртибен карап үтик. Болай дип ният кылына: «Йә Раббым! Дөньяга килүе белән җиһанны яктыртучы сөекле колың хөрмәтенә, изге раҗәб ае хөрмәтенә мине Үзеңнең бәрәкәтең, гафу кылуың һәм ризалыгың белән бүләклә, гыйбадәт кылучы һәм тәкъва колларыңнан ит, дөнья һәм Ахирәт бәлаләреннән коткар. Синең ризалыгың өчен. Аллаһу әкбәр».

Һәр рәкәгатьтә берәр «Әл-Фатиха», өчәр «Әл-Кәфирун», өчәр «Әл-Ихлас» сүрәләре укыла. Намаз 10 рәкәгатьтән тора. Һәр ике рәкәгать аерым башкарыла.

Беренче ун көндә намаздан соң 11 тапкыр әлеге зикер әйтелә:

لَا إِلهَا إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ يُحْيِي وَ يُمِيتُ وَ هُوَ حَيٌّ لاَ يَمُوتُ بِيَدِهِ الْخَيْرُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

**«Ләә иләәһә илләллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһ. Ләһүл мүлкү вә ләһүл хәмдү, йүхйии вә йүмиит. Вә һүә Хәййүл-ләә йәмүүт. Бийәдиһил хайру вә һүә галәә күлли шәй-ин кадиир».** («Аллаһыдан башка гыйбадәт кылырлык илаһи Зат юк, Аның һичбер тиңдәше юк. Ул барлык мөлкәт вә хөкем Иясе. Барча мактаулар Аңа гына хас. Аллаһы Тәгалә һәлак итәр һәм үлгәннән соң кабат тергезер. Ул мәңге тере һәм мәңге үлемсез. Барлык хәерле эшләр дә Аллаһы Тәгаләдән генә ирешә. Аның бар нәрсәгә дә, һичшиксез, көче җитәрлек»). Моннан соң дога кылына.

Икенче ун көндә намаздан соң 11 тапкыр әлеге зикер әйтелә:

اِلَاهًا وَاحِدًا احَدًا صَمَدًا فَرْدًا وِتْرًا حَيًّا قَيُّومًا دَائمًا ابَدًا

«Иләәһән вәәхидән әхәдән самәдән фәрдән витран хәййән каййүүмән дәәимән әбәдәә». («Бердәнбер, бернигә дә мохтаҗ булмаучы, ялгыз булучы, аерым булучы, тере булучы, бар нәрсәгә тереклек бирүче Аллаһыга ялварам»). Моннан соң дога кылына.

Өченче ун көндә хаҗәт намазыннан соң, 11 тапкыр әлеге зикер әйтелә:

اللَّهُمَّ لَا مَانِعَ لِمَا أَعْطَيْتَ، وَلَا مُعْطِيَ لِمَا مَنَعْتَ، وَلَا رَادَّ لِمَا قَضَيْتَ وَلَا مُبَدِّلَ لِمَا حَكَمْتَ وَلَا يَنْفَعُ ذَا الْجَدِّ مِنْكَ الْجَدُّ. سُبْحَانَ رَبِّيَ الْعَلِيِّ الْاَعْلَى الوَهَّاب، سُبْحَانَ رَبِّيَ الْعَلِيِّ الْاَعْلَى الوَهَّاب، سُبْحَانَ رَبِّيَ الْعَلِيِّ الْاَعْلَى الكَرِيم الْوَهَّابُ، يَا وَهَّابُ، يَا وَهَّابُ، يَا وَهَّابُ.

«Аллаһүммә ләә мәәнига лимәә әгътайтә вә ләә мүгътыя лимәә мәнәгътә вә ләә раадда лимәә кадайтә вә ләә мүбәддилә лимәә хәкәмтә вә ләә йәнфәгү зәл җәдди минкәл җәдд. Сүбехәәнә раббийәл галиййил әгъләл вәһһәәб, сүбехәәнә раббийәл галиййил әгъләл вәһһәәб, сүбехәәнә раббийәл галиййил әгъләл кәриимил вәһһәәбү, йәә вәһһәәбү, йәә вәһһәәбү, йәә вәһһәәб». («Йә, Раббым, Син бирергә теләгән нәрсәгә каршылык юк һәм Синең ризалыгыңнан башка берәү дә беркемгә дә нәрсә дә булса бирә алмый. Берәү дә Синең тәкъдиреңне үзгәртә алмый, берәү дә Синең карарыңны алыштыра алмый. Байлыктан файда юк, барлык мөлкәт бары Синнән. Аллаһы кимчелексез, Аллаһы Бөек, Олуг, Мәртәбәле, Аллаһы Ризыкландыручы. Йә Ризыкландыручы! Йә Ризыкландыручы! Йә Ризыкландыручы!»).

Раҗәб аеның җомгага каршы булган беренче төне – Рәгаиб кичәсе. Аны пәнҗешәмбе (атна кич) уразада булып каршы алу кирәк. Рәгаиб кичәсендә кичке һәм төнге намазлар арасында 12 рәкәгатьтән торган хаҗәт намазы укыла. Намаз икешәр рәкәгать итеп башкарыла. Һәр рәкәгатьтә, «Әл-Фатиха»дан соң, өчәр тапкыр «Әл-Кадр» һәм 12 тапкыр «Әл-Ихлас» сүрәләре укыла. Бу намаздан соң җиде тапкыр «Саләт-Үммийә» догасы кылына һәм сәҗдә кылына. «Саләт-Үммийә» догасы бу рәвешле укыла:

اَللّٰهُمَّ صَلِّ عَلٰى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ النَّبِيِّ الأُمِّيِّ وَعَلَى اٰلِهِ وَصَحْبِهِ أَجْمَعِين

«Аллаһүммә салли галәә сәййидинәә Мүхәммәдин-нәбиййил-үммиййи вә галәә әәлиһии вә сахбиһии әҗмәгыйн». («Йә, Аллаһым, әфәндебез, сәййидебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә һәм сәхабәләренә салаватлар һәм сәламнәр ирештер»).

Сәҗдәдә вакытта җитмеш тапкыр әлеге сүзләр әйтелә:

سُبُّوحٌ قُدُّوسٌ رَبُّنَا وَرَبُّ الْمَلَئِكَةِ وَالرُّوحِ

«Сүббүүхүн куддүүсун раббүнәә вә раббүл-мәләәикәти вәр-руух». («Камиллек Иясе, Кимчелексез, Ул – безнең Раббыбыз, фәрештәләрнең һәм җаннарның Раббысы»).

Шуннан соң сәҗдә халәтеннән чыгарга һәм утырган хәлдә әлеге сүзләрне әйтергә кирәк:

رَبِّ اغْفِرْلِى وَارْحَمْ وَتَجَاوَزْ عَمَّا تَعْلَمُ اِنَّكَ أَنْتَ الْأَعَزُّ الْأَكْرَمُ

«Раббигъ-фирлии вәрхәм вә тәҗәәвәз гаммәә тәгъләм. Иннәкә әнтәл-әгаззүл-әкрам». («Йә Аллаһым! Гафу ит, Рәхмәтеңне ирештер һәм Үзеңә билгеле булган нәрсәләрдән коткар. Дөреслектә, Син Кодрәтле һәм Мәрхәмәтле»).

Аннары яңадан сәҗдә кылына. Сәҗдәдә вакытта кабат 70 тапкыр:

سُبُّوحٌ قُدُّوسٌ رَبُّنَا وَرَبُّ الْمَلَئِكَةِ وَالرُّوحِ

«Сүббүүхүн куддүүсун раббүнәә вә раббүл-мәләәикәти вәр-руух». («Камиллек Иясе, Кимчелексез, Ул – безнең Раббыбыз, фәрештәләрнең һәм җаннарның Раббысы»), – дип әйтелә.

Сәҗдәдән соң Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә болай дип дога кылына:

اَللّٰهُمَّ بَارِكْ لَنَا فِي رَجَبٍ وَشَعْبَانَ وَبَلِّغْنَا رَمَضَان

«Аллаһүммә бәәрик ләнәә фии раҗәбин вә шәгъбәәнә вә бәллигънәә Рамәдаан». («Йә, Аллаһым, Безнең өчен раҗәб һәм шәгъбан айларын бәрәкәтле кыл һәм Рамазан аена ирешүне насыйп ит»).

Икенче көнгә, ягъни җомга көнне, өйлә белән икенде намазлары арасында, дүрт рәкәгать шөкер намазын укырга кирәк. Намазның һәр рәкәгатендә бер «Әл-Фатиха», җиде «Аят Әл-Көрси» һәм бишәр тапкыр «Әл-Ихлас», «Әл-Фәләкъ», «Ән-Нәс» сүрәләре укыла. Һәрбер ике рәкәгать саен сәлам бирелә. Намазны тәмамлаганнан соң егерме биш тапкыр:

لَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللَّهِ العَلِيِّ العَظِيمِ الْكَبِيرِ الْمُتَعَالِ

«Ләә хәүлә вә ләә куввәтә иләә билләәһил-галийийл гаҙыыймил-кәбиирил-мүтәгаал» («Бөек, Кодрәтле, Олуг булган Аллаһыдан башка көч вә куәт иясе юктыр»), – дип дога кылына. Моннан соң 25 тапкыр истигъфар сүзләре әйтелә.

Раббыбыз кылган гамәл-гыйбадәтләребезне кабул итеп, әҗер-савапларга һәм Үзенең Рәхмәтләренә ирешүебезне насыйп итсә иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ирек хәзрәт Җиһаншин,*

*Габдрәхим Утыз Имәни исемендәге*

*«Ал Таң» мәчете имам-хатыйбы*

*27 нче гыйнвар вәгазе,*
*ражәб аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# «Әйт мөэминә хатыннарга...»

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгаләдә безне яраткан һәм дөньяда бәхетле булу мөмкинлеге биргән. Шулай ук ничек яшәргә, эшләргә һәм хәтта ни рәвешле киенергә кирәклеген дә өйрәткән.

Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә Расүлебезгә мөрәҗәгать итеп:

يَا أَيُّهَا النَّبِيُّ قُل لِّأَزْوَاجِكَ وَبَنَاتِكَ وَنِسَاءِ الْمُؤْمِنِينَ يُدْنِينَ عَلَيْهِنَّ مِن جَلَابِيبِهِنَّ ۚ ذَٰلِكَ أَدْنَىٰ أَن يُعْرَفْنَ فَلَا يُؤْذَيْنَ ۗ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿٥٩﴾

**«Ий Нәби! Хатыннарыңа, кызларыңа һәм иман китерүчеләрнең хатыннарына әйт, җилбабларыннан [бер өлешенә төренеп, икенче] бер өлешен [әгъзаларының шәкелен билгеле итмәслек итеп] өсләренә салсыннар. Бу [рәвештә төренүләре] аларның [җарияләрдән һәм Ислам тыйган кайбер түбән гамәлләр кылган хатыннардан аерылып] танылулары һәм [начар кешеләр тарафыннан] мыскыл ителмәүләренә якынрак [гамәл]. Аллаһы – Гафу итүче, Рәхимле»,** – дип әйтә.

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:59

Нәрсә ул гаурәт? Ирләрдә һәм хатын-кызларда гаурәт мәсьәләсе аерыла. Ирләрнең кендекләреннән башлап, тез асларына кадәр булган өлешләре гаурәт булып тора, ә хатын-кыз тәненең һәр җире гаурәт, бары тик йөзләре, беләзекләренә кадәр ике учлары һәм тубыкларына кадәр аяк башлары гына гаурәт булып саналмый. Хатын-кызның гаурәт булып саналмаган урыннарын бары тик әтисе, ире, абыйсы, улы, оныгы гына күрә ала, калган ир-атларга аның гаурәтен күрү тыелган. Әгәр ул чит ир-атка гаурәт җирләрен күрсәтә икән, бу очракта үзенә дә, караучыга да гөнаһ языла.

Әйе, хатын-кызларга кием мәсьәләсе буенча Шәригать тарафыннан куела торган таләпләр бик зур, чөнки хатын-кызларыбыз милләтебезнең киләчәге, дәвамчылары. Күпләрнең яулык япмаулары кызганыч, хәтта: «Без бит кеше үтермибез, урлашмыйбыз, яулык япмау – гөнаһ түгел», – дип әйтүчеләр бар. Тик алар яулык япмауның да гөнаһ икәнлегенә төшенми.

Нәрсә ул яулык? Иң беренчедән – ул чисталык. Ягъни Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә хатын-кызга яулык һәм озын күлмәк сәбәпле пәрдә кыла һәм аны бөтен пычрак әйберләрдән: күз тиюләрдән, зәхмәтләрдән саклый. Икенчедән, яулык намуслылыкны күрсәтә, ә намус – әхлак көзгесе. Мондый кеше кыска күлмәкләр, ярым ялангач су керү костюмнары киеп йөрми, ә, киресенчә, үз тәнен капларга тырыша.

Раббыбыз гүзәл затларыбызга гаурәтне каплауны әмер кылган. Хөрмәтле кызлар, апалар! Һәрвакыт яулык белән йөрсәгез, аны бәйләгән саен Аллаһы Тәгалә сезгә әҗер-савабын бирә, хата-гөнаһларны гафу итә, төрле пычрактан, начарлыктан саклый.

Кайвакыт: «Хәзрәт, мин яулык бәйләп йөрим, ләкин囗 эштә миңа сәер итеп карыйлар», – дигән сүзләр ишетәбез. Кызганыч ки, безнең гел башта «кеше нәрсә әйтер, кеше кырын карады» дигән төшенчә яши. Әмма Аллаһы Тәгалә кешене шундый итеп халык кылды ки, һәр кешенең үз мәшәкате, үз дөньясы, үз уйлары бар, аның бездән башка да эше бик күп.

Бер көн безгә караса, икенче көнне игътибар да итмәячәк. Беренчедән, сез кеше алдында түгел, ә Аллаһы мине күрә, дип оялырга тиеш. Әгәр сез һаман да яулык бәйләргәме, юкмы дип икеләнәсез икән, кышын яулык бәйләсәгез, сезгә беркем дә игътибар итмәячәк.

Кайбер ханымнардан: «Хәзрәт, мин яулык бәйләр идем, ләкин ирем каршы», – дигән сүзләр ишетергә туры килә. Менә, хөрмәтле ир-атлар, бервакыт шундый мизгел киләчәк, үзегез хатыннарыгызга «яулык бәйлә», дип әйтерсез, әмма ул вакытта алар ризасызлык белдереп, баш тартыр.

1100 ел буе без мөселманнар. Без намаз укучы, яулыктан йөрүче, ураза тотучы, хаҗ кылучылардандбыз. Әгәр моннан оялабыз икән, димәк, әти-әниләребездән, әби-бабаларыбыздан оялган булабыз.

Шулай ук: «Әниләр гомер буе яулыкларын артка бәйләп йөргән һәм хәзер генә яшь буын, модага ияреп, аларны гарәпчә, төрекчә бәйли», – диючеләр дә бар. Әйе, шулай, әмма элек әниләр өйдә йөргәндә яулыкны бер төрле, урамга чыкканда икенче төрле ябалар иде.

Совет чорын карасак, әлбәттә, бу – динсезлек вакыты. Ул вакытта: «Яулыгыңны сал, күлмәгеңнең кыскарагын ки, ураза тотма, мәчетне яп, манараны кис», – дигәч, дингә карата чикләүләр булгач, әлбәттә, күп карашлар саекты, үзгәрде. Шуңа да яулык бәйләү ысуллары да үзгәргәндер. Ләкин шул чорга хәтле әбиләребез һәрвакыт яулыктан йөргән. Аллаһы Тәгалә аларга фатихасын һәм сәламен бирсә иде!

Кайбер ирләр: «Хәзрәт, хатыным намаз укый, үзем дә намазда, ләкин яулыгын бәйли алмый, ояла, курка», – ди. Хөрмәтле ирләр, сез тормыш иптәшегезгә матуррак, күркәмрәк, миллирәк яулык бүләк итегез. Кайберләре: «Милли кием кыйммәт, мин аның урынына ун күлмәк алам», – ди. Әйдәгез, нәрсә бүләк итим дип уйлаганда, үзебезнең татар милли киемнәрен алып, үз ярларыбызны куандырыйк.

Кайбер хатын-кызлар: «Ирем мине яулык бәйләп йөрергә мәҗбүр итә, аның моңа хокукы юк», – дип зарлана. Әлбәттә, кемгә дә булса яулык

бәйләүне мәҗбүр итеп булмый, ләкин хөрмәтле ханымнар, әгәр дә сез яулык бәйләмәсәгез, бу сезгә дә, иregeзгә дә гөнаһ булып барыр.

Ата-аналар, әгәр дә кызыгызның йөрәгендә яулык бәйләп йөрү теләге булса, баланың теләген юкка чыгармагыз, киресенчә, аны куәтләгез, балагызга ярдәм итегез.

Кызлар, әгәр дә сезгә башыгыздагы яулыкны салу хакындагы уйлар килә икән, аны иң баштан нәрсә өчен бәйләгәнегезне искә төшерегез. Сез аны кемдер өчен бәйләмәдегез бит, ә Раббым Аллаһы кушканга, Аның ризалыгына ирешергә теләгәнгә күрә яптыгыз.

Раббыбыз безне ярата, Ул безгә үтә алмый торган сынаулар бирми. Әгәр Аллаһы Тәгалә сынауларын бирә икән, без аны дөрес итеп үтик. Без – яулыклы, озын күлмәкле, намазлы, уразалы милләт, шуны онытмыйк. Раббыбыз Аллаһы һәрбер хатын-кызга яулыклы булып, гаурәт җирләрен каплап йөрүне насыйп кылсын.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*«Гаилә» мәчетенең имам-хатыйбы*

*3 нче февраль вәгазе,*

*раҗәб аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Кыямәт көнендә соралачак нәрсәләр

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Кыямәт көненә ышану – иманның бер баганасы. Кем дә кем үлгәннән соң терелеп, хисап тотачагына ышанмый икән, Кыямәт көне киләчәгенә шикләнә икән, ул имансыз була. Башына түбәтәй киеп, мәҗлесләр үткәреп, садакалар биреп йөрсә дә, Кыямәт көненә ышанмаган кеше мөселман булмый, чөнки Раббыбыз Коръәни Кәримнең бик күп урынында бу көн турында, Кыямәт көненең куркынычлылыгы, анда булачак вакыйгалар хакында зикер итә.

Билгеле ки, Кыямәт көнендә адәм балалары бик нык куркуда булачак. Ул көннең дәһшәте һәрбер кешегә дә бик авыр тоелачак. Һәм шушы көндә кояш бер чакрым югарылыгында торганда, йолдызлар чәчелеп, җир тигезләнгән вакытта, Адәм балалары үзләренең тирләренә баткан мәлдә, бу дөньядагы иң тәкәббер, үзен өстен санаганнар иң мескен хәлдә булганда, беркем дә Аллаһы Тәгаләнең рөхсәтеннән башка аягын да кузгата алмас.

Имам Әл-Куртуби әйтүенчә, Кыямәт көнендә кешеләр караңгыда кубарылачак. Коръән тәфсирләрендә: «Күк анда төрелеп куелыр, йолдызлар чәчелер, кояш яктылыгын югалтыр, кояш белән ай кушылыр, һәм шунда кешеләр чакыручы артыннан иярер, аларның тавышлары да чыкмас,

илләдә мәгәр акрын-акрын гына пышылдаган тавышлары килер, хәтта аяк баскан тавышлары да ишетелмәс», – дип язылa. Һәм шушы пышылдап кына сөйләшкән көндә кешеләрдән 4 нәрсә хакында соралмыйча, аларның үкчәләре дә кузгалмас.

Шуларның берсе – гомер. Аллаһы Тәгалә биргән гомеребезне ничек үткәргәнбез – шул хакта хисап тотачакбыз.

Раббыбыз Коръәндә җәһәннәмгә төшкән кешеләр хакында болай ди:

وَهُمْ يَصْطَرِخُونَ فِيهَا رَبَّنَا أَخْرِجْنَا نَعْمَلْ صَالِحًا غَيْرَ الَّذِي كُنَّا نَعْمَلُ ۚ

**«Алар анда: «Ий Раббыбыз! [Без тарыган бу газаптан] Безне чыгар [дөньяга кире кайтар] да, [элек] кылган нәрсәбездән башка – изге гамәл эшлик», – дип кычкырып елаячаклар».**

«Фатыйр / Бар кылучы», 35:37

Ләкин аларга җавап каты булыр:

أَوَلَمْ نُعَمِّرْكُم مَّا يَتَذَكَّرُ فِيهِ مَن تَذَكَّرَ وَجَاءَكُمُ النَّذِيرُ ۖ فَذُوقُوا فَمَا لِلظَّالِمِينَ مِن نَّصِيرٍ ﴿٣٧﴾

**«Үгетләнгән кешене дә анда [вакыт эчендә] үгет алырлык кадәр яшәтмәдекме? Сезгә [пәйгамбәр, Коръән, картлык һәм якыннарыгызның үлеме кебек] кисәтүчеләр дә килгән иде. Шулай булгач, [бу газапны] татыгыз. [Сезнең кебек кяфер булган] Залимнәр өчен бернинди дә ярдәмче юк».**

«Фатыйр / Бар кылучы», 35:37

Адәм баласына җитәрлек гомер дигәндә, тәфсир галимнәренең фикерләре төрле. Кемдер 17-18 яшь ди, чөнки, бәлагать яшенә ирешкәч, кеше Аллаһы Тәгаләнең фарызларын үтәргә тиеш, харам нәрсә эшләсә, аңа гөнаһ языла. Кайбер галимнәр – 40, икенче берәүләр 60 яшь, дигән фикердә. Бер хәдистә: «Әгәр кеше 60 яшькә җитә икән, аның акланыр-

лык бернинди дә сәбәбе калмый», – диелгән. Әле яшь кешенең акланырлык нindидер сәбәбе, гозере булса, инде 60 яшькә җиткәннәрнең Аллаһы Тәгалә алдында акланырлык бернинди гозере калмый. Адәм балаларына Раббыбыз билгеле бер гомер биргән, һәм шушы гомер эчендә уйланыр, фикерләр, Аллаһыны таныр өчен һәрберебездә дә җитәрлек вакыт бар.

Кыямәт көнендә кеше тәне, җәсәде, яшьлеге хакында да соралачак: яшьлеген ничек үткәргән, сәламәтлеген ничек кулланган? Яшь чакта кешенең көче дә, куәте дә, зиһене дә яхшырак, шуңа ул бу вакытын файдалы итеп үткәрсә, картлыгы да бәрәкәтле булачак. Яшьлеген дөрес кулланмаса, олыгайган тормышы җиңел үтәр дип әйтүе кыен. Шуңа, без – яшьләр үзебезнең мөмкинлекләребезне дөрес итеп кулланырга тиеш.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә: «Биш нәрсә килгәнче, биш нәрсәнең кадерен бел, дөрес итеп кулланырга өлгер», – дип әйтә. Шулар арасында яшьлек тә бар. Һәрбер кеше картлык килгәнче яшьлеген дөрес рәвештә уздырып өлгерергә бурычлы. Адәм баласы яшьлеген Аллаһы Тәгаләгә итагать кылуда үткәрә икән, иншәАллаһ, котылучылардан булыр. Яшьлеген гыйбадәттә уздырган кешенең Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгаләнең күләгәсендә булачагын да беләбез.

Вакыт дигән әйбер бик тиз үтә. Кызганыч, моны яшьләребез аңлап бетерми. Аллаһы Тәгалә безгә гыйлем алырга, изгелекләр кылырга көч, зиһен биргән. Ә кайбер яшь кешеләр шушы мөмкинлекләрен гөнаһ җыюга сарыф итә, гыйлем, гыйбадәт ише әйберләргә җиңел карый; хәрәкәт, сөйләмнәрендә имансызларга охшарга тырыша; исерткеч эчемлекләр, наркотик куллану, тәмәке тарту белән мавыга. Кызганыч, бүген яшьләр Аллаһы Тәгаләнең китабы Коръәни Кәримне читкә куеп, вакытын җыр тыңлап, йә булмаса зина кылып яки башка шундый куркыныч афәтләр эшләп үткәрә. Әгәр алар мөмкинлекләрен белем алуга, гамәл кылуга, бу дөнья һәм Ахирәт өчен файдага юнәлдерсә, нинди бәрәкәтле яшьлек булыр иде ул.

Кыямәт көнендә соралачак өченче нәрсә – ул байлык, ягъни мал. Нинди генә мал булмасын, зурмы-кечкенәме – без шушы байлыкны кайдан табуыбыз хакында соралачакбыз. Ягъни байлык дигәч тә, байлар гына хисап тотачак дигән сүз түгел. Әгәр безгә 500 сум, 1000 тәңкә керсә дә – аны ничек табуыбыз хакында соралачакбыз. Моннан тыш аның ничек тотылуы да игътибардан читтә калмаячак, чөнки Адәм баласы хәләл юл белән кәсеп итеп тә, акчасын харамга тотарга мөмкин. Мондый кеше Кыямәт көнендә хәсрәттә булачак. Инде кешенең кәсебе дә, аны тота торган юлы да харам икән, аңа тагын да авыррак булачак. Шуңа һәрберебез малыбызны хәләл рәвештә юнәтеп, аны рөхсәт ителгәнгә – гаиләбезне тәэмин итүгә, туганнарга, мохтаҗларга булышуда йә башка төрле изгелекләргә кулланырга тиешбез. Хәдистә: «Харам юл белән үзегезгә ризык эстәмәгез. Сезнең һәрберегезнең ризыгы билгеләнеп куелган, шуңа тәкъдирдә язылган ризыгыгызны хәләл юл белән табыгыз», – дип әйтелә.

Кыямәт көнендә соралачак дүртенче нәрсә – үзеңнең гыйлемең белән ничек гамәл кылуың. Кешенең бу дөньяда гыйлем алуы – ул бер, алган гыйлемен ничек куллануы – анысы инде икенче мәсьәлә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Гыйлем эстәү – һәрбер мөселман өчен дә фарыз», – дигән. Гыйлем алмаган кеше Ахирәттә хәсрәт вә үкенечтә булыр. Раббыбыз Аллаһы Тәгаләнең динен өйрәнү һәрберебез өчен дә фарыз, һәрберебез өчен дә кирәкле гамәл. Мөселман кешесе «Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр-расүлуллаһ» кәлимәсе турында, аның шартлары, шушы шәһадәт кәлимәсен боза торган нәрсәләр хакында белергә тиеш. Көферлек, ширек кебек мәсьәләләргә, олы-кече көферлек, олы-кече ширекләр турындагы белемгә дә мөселман кешесенә игътибарлы булу шарт. Болар барысы да аңа ширек гамәлләр кылмас, алардан сакланыр өчен кирәк. Ә иман, ислам баганаларын белү – ул ислам гыйлемнәренең мөһим бер өлеше.

Һәрбер мөэмин-мөэминә шулай ук Аллаһы Тәгалә алдындагы бурычларын, әдәп-әхлакларын, Аның Расүле Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләмгә бәйле нинди әдәпләр бар икәнен дә белергә тиеш. Аллаһы Тәгаләнең китабы Коръәни Кәрим каршындагы әдәпләрне дә, Раббыбыз бар кылган кешеләр – хәләл җефетләр, балалар, әти-әниләр, туганнар, күршеләр, башка дин вәкилләре алдында нинди хакларыбыз, бурычлар һәм әдәпләребез барлыгын да без бу дөньяда белеп яшәргә, шул гыйлем нигезендә гамәл кылырга тиешбез. Гыйлемең булып, аны гамәлдә кулланмыйсың икән, мондый гыйлемнең файдасы юк. Ә гыйлемсез килеш рөхсәт ителмәгән гамәлләр башкарып куюың ихтимал.

Кыямәт көнендә һәрбер кеше алдан санап үтелгән әнә шул дүрт нәрсә хакында соралачак. Шуңа өстебездән хисап кылынганчы, алдан ук әлеге әйберләр буенча үзебезгә хисап ясарга тиешбез. Раббыбыз барчабызга үзебезнең гомеребезне, яшьлегебезне файдалы итеп үткәрергә, малыбызны хәләл юл белән табып, рөхсәт ителгән юлларда кулланырга, һәм дә файдалы гыйлем алып, аның нигезендә гамәл кылырга насыйп итсә иде!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*Әлмәт шәһәренең 1нче мәхаллә имам-хатыйбы*

*10 нчы февраль вәгазе,*

*раҗәб аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Тәвәккәллек күрсәтүче күпкә ирешә

Галәмнәрне юктан бар кылып, безгә җан бирүче, ризыкландыручы Аллаһы Тәгаләгә дан-мактаулар булса иде. Дөньялыкка ахыргы пәйгамбәр, безгә рухи укытучы булып җибәрелгән Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салаватшәрифләребез ирешсә иде.

Бу дөньяда без һәрвакыт үзебезне көчле, беркемгә дә, бернәрсәгә дә мохтаҗ түгелдер сыман тоеп яшибез. Әмма һәр кешенең тормышында тетрәндергеч хәлләр була, ул вакытта кеше кемгә таянырга, кемгә барырга икәнен аңламый башлый. Шулвакыт күп кеше сына, сыгыла.

Әмма мөселман кешесенең хәле башкача. Иман әһеле Раббысы белән элемтәдә нык тора, җаны-тәне белән Аллаһы Тәгаләне тоя, чөнки Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйткән аятьне бик яхшы белә, ә ул аятьтә болай дип әйтелә:

إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُتَوَكِّلِينَ

**«Һичшиксез, Аллаһы [бөтен эшләрдә Аңа] тәвәккәл итүчеләрне сөя».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:159

Димәк, Аллаһы Тәгалә Үзенә тәвәккәл кылуны сөя, без бер мизгелгә дә шикләнмичә Аңа бөтен дөнья мәшәкатьләрен, якыннарыбызның, балаларыбызның язмышын тапшыра алабыз.

Ихлас күңелдән Аллаһы Тәгаләгә ышанып, бөтен дөньяңны Аңа тапшырып яшәүдән дә мәртәбәлерәк тормыш була аламы?! Юк, була алмый!

Бүген күп кеше рухи арганлык кичерә, төшенкелеккә бирелү белән интегә. Күпләр ачлык, ялгызлык кебек төрле хәлләрдән, бәла-казалардан куркып яши. Һичшиксез, бу хәлләр Аллаһыга ышанып, тәвәккәл кылу булмаганнан килеп чыга.

Әлбәттә, сәбәп кылмый гына, Аллаһыга тапшыру дөрес булмас, чөнки тәвәккәллек – ул сәбәп кылып, шушы сәбәпнең нәтиҗәсе Аллаһыдан икәненә инану.

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Бер кеше Расүлуллаһ янына килеп: «Әй Аллаһының Расүле! Дөямне бәйләп, Аллаһыга тапшырыйммы яки бәйләмичә Аллаһыга тапшырыйммы?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөяңне бәйлә, ә аннан соң Аллаһыга тапшыр», – дигән. Димәк, иң мөһиме – сәбәп кылып, Аллаһыга тапшыру.

Тәвәккәллек үрнәге итеп Коръәннән, пәйгамбәрләр тарихыннан бик күп мисаллар китереп була. Әйтик, Нух галәйһиссәлам Аллаһы әмере белән чүл уртасында көймә төзегән. Кешеләр аннан: «Әй Нух! Син әле күптән түгел безне Аллаһыга ышанырга чакырдың, ә бүген көймә төзисеңме?» – дип көлә торган булганнар. Әмма ул кавемен шушы көймәгә утырткан һәм Аллаһы Тәгалә бөтен дөньяны су астында калдырганнан соң, көймә әһелләре генә котыла алган.

Ибраһим галәйһиссәлам дә Раббыбызга тәвәккәл итүе белән Аның ярдәменә, Рәхмәтенә ирешкән. Аны кырык көн дәвамында пәйгамбәрне юк итәргә дип әзерләнгән утка ыргытканнар. Ибраһим галәйһиссәламнең Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәллеге шуның кадәр нык булган ки, ул фәкать Аллаһы Тәгаләдән генә дога кылып сораган. Һәм Раббыбыз ут эчен гөлбакчага әверелдергән, ут пәйгамбәргә зыян сала алмаган.

Муса галәйһиссәлам һәм Исраил уллары артыннан фиргавен куганда пәйгамбәр үзенең кавеме белән диңгез алдында туктап калган. Шулвакыт аның кавеме аңа: «Бу синең гаебең белән! Сиңа иярмәгән булсак иде», – дип җикеренгәннәр. Әмма Муса галәйһиссәлам бөтен тәвәккәллеге белән эшләрен Аллаһыга тапшырган һәм Аллаһы Тәгалә диңгезне икегә аерып, аның уртасына юл салган. Муса галәйһиссәлам кавеме белән шул юлдан чыгып котылган, ә фиргавен зур дулкыннар арасында калып һәлак булган.

Әгәр хәзрәти Мәрьям анабыз кыйссасына карасак, ул гел ураза тота, гыйбадәт кыла торган була. Мәрьям анабызның еш кына ашарына ризыгы булмый, әмма ул һәрчак Аллаһыга тәвәккәл кыла. Зәкәрия галәйһиссәлам аның янына керсә, кыш көнендә – җәйге җимешләрне, ә җәй көнендә кышкы җимешләрне күрә һәм кызыксынып, бу нигъмәтләрнең каян килүен сорый иде. Хәзрәти Мәрьям анабыз: «Бу Аллаһыдан килгән ризыклар», – дип җавап кайтара. Әйе, Аллаһы Тәгалә аңа ул ризыкларны фәрештәләр аша Үз хозурыннан бирә.

Безнең сөекле Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тормышында да тәвәккәллек күрсәтү очраклары күп булган. Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылган вакытта Мәккә мөшрикләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның иң якын сәхабәсе Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе артыннан эзәрлекләп юлга чыгалар. Бу вакытта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе тау куышына кереп яшеренә. Һәм аларның эзләренә төшкән мөшрикләр шушы тау куышы янына килеп җитә. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе дошманнарның янәшәдә булуларын сизеп, куркып кала һәм: «Хәзер безне күрәләр», – дип борчуга төшә. Әмма Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны: «Аллаһы безнең белән бит, шулай булгач курыкма!» – дип тынычландыра. Шулай итеп алар эзәрлекләүләрдән котылалар, Аллаһының Рәхмәте белән мөшрикләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә дә, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһегә дә зыян сала алмый.

Бу вакыйгалар, әлбәттә, билгеле булган очраклардан. Тик аларга игътибар белән күз салсак, үз тормышыбызда да мондый вакыйгаларның шактый икәнен күрә алабыз. Үзем тап булган, ишеткәннәре дә байтак.

Бер кеше йокларга ятар алдыннан матди яктан булган проблемалары чишелүен сорап дога кыла һәм эшләрен Аллаһыга тапшыра. Бу вакытта аның түләүләренә, бурычларын кайтарырга, ризык алырга да акчасы калмаган була. Ул төнге 12 ләр тирәсендә телефонына смс килгән тавышка уянып китә. Караса, банк картасына бик зур суммада акча күчкән була. Бу акчаны эшендәге җитәкчесе яхшы эшләгәне өчен премия буларак күчергәне ачыклана. Моннан соң аның ашарына да, түләүләренә дә, бурычларын кайтарырга да акчасы җитә.

Безнең тәвәккәл кыла белүебез безне Аллаһы Тәгаләгә якынайта. Ихлас күңелдән тәвәккәл кылучы кеше бөтен проблемаларын чишә ала, чөнки без никадәр тәвәккәллерәк булсак, проблемаларыбызның чишелеше дә безгә шуның кадәр якынрак.

Бу дөнья – сынау кырыдыр. Шушы сынауларны Аллаһы Тәгаләгә ышанып, изгелек кылып, тәвәккәллек кылучы гына җиңеп чыгар. Сәбәп кылып, Аллаһы Тәгаләнең Рәхмәтен өмет итеп яшәү безнең өчен иң хәерле тормыш.

Тормышыбызда күпчелек уңышсыз эшләр, хәлләр, бөтенесе дә Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кыла белмәү сәбәпле, чөнки Аллаһы Раббыбызга тапшырасы урынга без кешеләргә таянабыз һәм ахыр чиктә нык үкенәбез. Без кайвакыт дусларның, хезмәттәшләрнең, якыннарыбызның безгә ярдәм итә алмаганнарын, яки иң авыр вакытта калдырып киткәннәрен күрәбез. Аннан үзебезгә: «Ник шулай булды? Нигә шушы кеше миңа ярдәм итмәде икән?» – дип гаҗәпләнәбез. Ә моның сәбәбе бик гади: без Аллаһы Тәгаләне икенче урынга, ә ул кешеләрне беренче урынга куябыз. Раббыбыз аларны бездән ерагайтып, Үзенә якын булырга куша. Ул безгә ата-анабызга караганда да 70 мәртәбә якынрак. Димәк, җаныбыз, тәнебез

белән Аңа ышанып, таянып яшәргә кирәк. Ул безгә якын дусны, якын туганнарны, якын кардәшләрне дә бирүче. Тик шуны онытмаска кирәк: кайвакыт шундый хәлләр була: авырлыкларыбыз белән Аллаһы Тәгалә каршында ялгызыыз калабыз. Бу дөньяда бернәрсә дә мәңгелек түгел, шуның хакында онытмасак иде. Һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылып яшик. Аллаһыга тәвәккәл кылучы бик күпкә ирешә, чөнки иман, өмет, Раббыбызның Рәхмәтен сизү – бер бәхет һәм максатка этәргеч. Аллаһы Тәгаләне онытмыйк, Ул да безне онытмас, безгә Кодрәт ишекләрен ачар.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*17 нче февраль вәгазе,*

*раҗәб аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Исра вә Мигъраҗ – Раббыбызның бүләге

Мәрхәмәтле һәм Рәхимле булган галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкраналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның мостафасы Пәйгамбәребезгә салават-сәламнәр әйтәбез.

Динебез Исламда Исра вә Мигъраҗ кыйссасы дигән төшенчә бар. Исра – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккә шәһәреннән Әл-Кодес (Иерусалим) шәһәренә күченүе, ә Мигъраҗ Раббыбыз янына күтәрелүе ул.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән булган бу вакыйгалар сахих, ягъни дөрес булган чыганакларда китерелә. Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать фикере буенча без берничек тә боларны инкарь итә алмыйбыз, гәрчә кайбер кешеләр бу вакыйгаларны дөрес түгел дип ышандырырга тырышса да.

Болар хакында Изге Китабыбызда да әйтелгән. Раббыбыз Коръәни Кәримдә:

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ﴿١﴾

**«[Бер айлык юлны бер төн эчендә үтү, Бәйт Әл-Мәкъдисне зиярәт кылу, бөтен пәйгамбәрләрне тере килеш күрү, җиде кат күктә аларның урыннарында булу һәм Җәмалыбызны күрү кебек] Аятьләребездән кайберләрен күрсәтик дип, бер төнне [бик**

**кыска бер вакытта Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм колын Харам мәчетеннән [алып] Без тирә-ягын бәрәкәтле иткән Әкъса мәчетенә күчерүче [булган Аллаһы ниндидер бер урында булудан һәм бөек Затына килешми торган төрле түбән сыйфатлардан ерак һәм бөтен] кимчелекләрдән пакь. Һичшиксез, Ул – [һәрнәрсәне] Ишетүче, Күрүче».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:1

Олуг имамнарыбыз Әл-Бохари рахимәһуллаһи һәм Әл-Мөслим рахимәһуллаһидан тапшырылган хәдистә Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен риваять иткән: «Миңа Буракны китерделәр. Бу ишәктән зуррак, әмма мулдан кечерәк булган хайван иде. Аның күз карашы кая җитсә, ул шунда баса, ягъни ул шул дәрәҗәдә тиз бара ки, хәтта бер сикерүдә зур араны үтә иде. Мин аңа утырып бардым һәм Әл-Кодес шәһәренә килдем. Анда мин Буракны башка пәйгамбәрләр дә үз хайваннарын бәйләп куйган бер боҗрага бәйләдем. Шуннан соң Әл-Әкъса мәчетенә кереп, анда ике рәкәгать намаз укыдым[1]. Мәчеттән чыккач, минем яныма шәраб һәм сөт салынган савытлар тотып Җәбраил галәйһиссәлам килде. Мин сөтне сайладым. Җәбраил галәйһиссәлам миңа: «Син асылны (фитраны) сайладың, дөрес эшләдең», – диде.

Шуннан соң безне күккә күтәрделәр. Җәбраил галәйһиссәлам керергә рөхсәт сорады. Аннан:

– Кем бар анда? – дип сорадылар.

Ул:

– Җәбраил, – дип җавап бирде.

– Ә синең белән кем? – дип сорадылар.

Ул:

– Мөхәммәд, – диде.

[1] Башка риваятьләрдә «барлык пәйгамбәрләр өчен имам булып бастым» дип килә.

– Ул пәйгамбәр булып җибәрелгәнме инде? – дип сорадылар.

Җәбраил галәйһиссәлам:

– Әйе, җибәрелгән, – дип җавап бирде.

Безгә ишекне ачтылар һәм анда минем туганнарым Яхъя галәйһиссәлам һәм хәзрәти Мәрьямнең улы Гайсә галәйһиссәлам иде. Алар минем өчен куанды һәм Аллаһыдан минем өчен хәерлелек сорады. Моннан соң безне өченче кат күккә күтәрделәр, монда да шул ук хәлләр кабатланды. Безгә ишекне ачтылар һәм мин дөньяның ярты гүзәллеге бирелгән Йосыф галәйһиссәламне күрдем. Ул да миңа куанды һәм Раббыбыздан минем өчен хәерлелек сорады. Шуннан соң безне дүртенче кат күккә күтәрделәр. Монда да шул ук хәлләр кабатланды. Анда Идрис галәйһиссәлам иде. Ул да минем өчен куанды һәм Аллаһыдан минем өчен хәерлелек сорады. Аллаһы Тәгалә аның хакында:

وَرَفَعْنَاهُ مَكَانًا عَلِيًّا ﴿٥٧﴾

**«Без аны [пәйгамбәрлек кебек] өстен бер урынга күтәрдек»,** – дип әйткән.

«Мәрьям», 19:57

Аннары безне бишенче кат күккә күтәрделәр һәм анда да шул ук хәлләр кабатланды. Монда без Харун галәйһиссәламне күрдек. Ул да минем өчен куанды һәм Аллаһыдан минем өчен хәерлелек сорады. Алтынчы кат күктә Муса галәйһиссәлам белән очраштык. Ул да куанып, минем өчен Аллаһыдан хәерлелек сорады. Җиденче кат күктә Ибраһим галәйһиссәлам иде. Ул аркасы белән Бәйт Әл-Мәгъмүргә[1] сөялеп утырган иде. Бирегә көн саен 70 мең фәрештә керә. Шуннан соң без Сидратүл-Мөнтәһәгә[2] җиттек. Аның яфраклары филнең колакларына тиң, ә җимешләре зур чүлмәк кадәрле иде. Шулвакыт Аллаһы Тәгаләнең кушуы буенча агач

[1] Бәйт Әл-Мәгъмүр – җирдәге Кәгъбәнең җиденче кат күктәге тиңдәше ул.

[2] Сидратүл-Мөнтәһә – һәрвакыт яшеллектә утыра, җимеш бирә торган агач ул.

гаҗәеп матурлыкка күмелде һәм бер җан иясе дә тасвирлап бирә алмаслык гүзәллеккә ия булды.

Мигъраҗ вакытында Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә миңа илле вакыт намаз укуны күңелемә салды. Мин Муса галәйһиссәлам янына төштем һәм ул:

– Раббыбыз синең өммәтеңә нинди гамәлне боерды? – дип сорады.

Мин:

– Илле вакыт намаз, – дип әйттем.

Муса галәйһиссәлам:

– Раббыбыз янына кабат кайтып, Аннан җиңеллек сора. Хакыйкатьтә, синең өммәтең моны булдыра алмас. Мин кавемемне сынадым һәм аларның булдыра алмавына инандым, – диде.

Моннан соң мин Раббыбызга мөрәҗәгать итеп:

– Йә, Аллаһым, өммәтемә җиңеллек бир, – дидем.

Шул рәвешле мин Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә белән Муса галәйһиссәлам арасында йөрдем. Һәм Ул илле вакыт намазны биш вакытка киметте. Әмма монда да Муса галәйһиссәлам: «Синең өммәтең моны да булдыра алмас. Раббыбыздан җиңеллек сора», – диде. Болардан соң Раббыбыз:

– Ий, Мөхәммәд, хакыйкатьтә, тәүлегенә шушы биш вакыт намаз өчен Мин ун тапкыр арттырып бирермен һәм бу илле вакыт намаз укыган кебек булыр. Берәү изге гамәл кылырга ниятләп, аны кылмаса, аңа бер әҗер-савап язылыр. Ә берәү ниятләгәннән соң, ул гамәлен кылса, аңа ун әҗер-савап язылыр. Бер адәм начар гамәл кылырга ниятләп, аны кылмаса, аңа берни дә язылмас. Ә берәү ниятләгәннән соң аны кылса, аңа бер гөнаһ язылыр, – диде.

Мин Муса галәйһиссәламгә төшеп, болар хакында сөйләдем. Ул миңа:

– Раббыбызга кабат кайт һәм җиңеллек сора, – диде.

Әмма мин:

– Мин кабат Раббыбызга кайтырга оялам», – дидем».

Бу хәлләрдән соң пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шул ук төндә өенә кайтып җиткерелгән. Күз алдыбызга гына китерик: Мигъраҗ вакытында күпме вакыйгалар булса да, Расүлуллаһ бик аз вакытка гына җирдән аерылып торган, шул ук төндә яңадан Мәккәгә кайтып җиткән.

Раббыбыз Коръәндә:

لَقَدْ رَأَىٰ مِنْ آيَاتِ رَبِّهِ الْكُبْرَىٰ ﴿١٨﴾

**«Ул Раббысының иң бөек аятьләреннән иң әһәмиятле бер өлешен [Мигъраҗ кичәсендә] күрде»,** – дип әйтә.

«Ән-Нәҗм / Йолдыз», 53:18

Бу аять пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мигъраҗ вакытында Кодрәт иясенең бөек могҗизаларын: Бәйт Әл-Мәгъмүрне, Сидратүл-Мөнтәһәне, җәннәт белән җәһәннәмне, үз кыяфәтендә Җәбраил галәйһиссәламне һәм башка гаҗәеп хәлләрне күрүе хакында әйтә.

Әмма, белүебезчә, Расүлуллаһ үзе күргән могҗизалар белән уртаклашып, Мәккәлеләрне иман китерергә чакырса да, тәкәббер мөшрикләрнең күңелләренә аның сүзләре тәэсир ясый алмаган. Пәйгамбәребез Аллаһының Рәхмәте белән аларга Шам җирләреннән кайтып килә торган кәрваннары хакында төп-төгәл итеп әйтеп бирсә дә, кәрванның кайсы вакытта Мәккәгә кайтып җитүен, хәтта беренче булып нинди дөянең атлап баруын әйтеп күрсәтсә дә, кешеләрнең кирелек, үҗәтлекләре Пәйгамбәребезнең хаклыгын танудан өстен булган.

Биш вакыт намаз Раббыбызның Расүлуллаһ өммәтенә бирелгән бүләге ул. Тәүлегенә биш вакыт намаз фарыз кылынганчы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Ибраһим галәйһиссәлам кебек, иртән –

ике, кичен ике рәкәгать намаз укый торган булган. Исра вә Мигъраждан соң иртән Җәбраил галәйһиссәлам килеп, Пәйгамбәребезне намаз уку тәртибенә өйрәткән. Һәм алар көн дәвамында, вакыты керү белән, бергәләп биш вакыт намазны укыган.

Сүз дә юк, биш вакыт намаз илле вакыт намаз түгел. Әмма безнең берәр кайчан илле вакыт намаз укуны күз алдына китергәнебез бармы икән?! Әгәр без, чыннан да, намазны биш вакыт түгел, ә илле вакыт итеп укыган булсак, ничек булыр иде? Ничек калган эшләребезне башкарып өлгерер идек? Вакыт җитми дип зарланган бу заманда ниләр эшләп бетәр идек икән?.. Раббыбыз мәхлүкъларына күтәрә алмаслык йөкләр йөкләми, шуңа да биш вакыт намаз безгә фарыз кылынган икән, димәк, без аны укуны булдыра алабыз. Бары тик теләк, ихласлык һәм иман ныклыгы гына кирәк.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә үтәргә кушкан гамәлләрне Аның ризалыгы өчен дип башкарып, Раббыбызның Рәхмәтендә булуыбыз, кылган гамәлләребез илә ике дөнья бәхетенә ирешүебез насыйп булса иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

*24 нче фераль вәгазе,*

*шәгъбан аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Тәкәбберлек – гөнаһларның башы

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Кешегә тәкәбберлек, ягъни үзен башкалардан өстен кую сыйфаты хас. Әмма моның белән ул, иң беренче чиратта, үзенә зыян салганын аңламый. Иблис мәлгунь тәкәбберлеге сәбәпле, Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм булган сыман, кеше дә тәкәбберлеге аркасында бәлаләргә дучар була ала.

Гап-гади мисал: шәһәрдәге машиналар. Алар күп, юл бирәү генә, берсенең дә сүзнең туры мәгънәсендә башка кешегә юл бирәсе килми. Ник? «Мин бит яхшырак! Минем машина «текәрәк», – дип фикер йөртә адәм баласы. Нәтиҗәдә – юл һәлакәте. Тик монда да гаепле кеше хатасын табарга ашыкмый, чөнки тәкәбберлек үзенекен итә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр кешенең күңелендә тузан бөртеге кадәр булса да тәкәбберлек булса, ул җәннәткә кермәс», – дип әйткән. Моны ишетеп бер кеше: «Әмма кеше өс киеме һәм аяк киеме матур булуын тели бит», – дигән. Моңа Расүлебез: «Дөреслектә, Аллаһы күркәм һәм күркәмлекне ярата, ә тәкәбберлеккә килгәндә – ул хакыйкатьне кабул итмәү һәм үзеңне башкалардан хәерлерәк санау»[1], – дигән.

[1] Имам Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан.

Тәкәбберлек «кәбир» сүзе белән бер тамырдан. Кәбир – олуг, бөек дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме арасында «Мутткәббир» дигән исеме бар. Бу сыйфат Аллаһыга гына хас. Мәхлүкатлар бу сыйфатларга ия була алмый.

Белүебезчә, Аллаһы Тәгалә Иблис мәлгуньгә, Үзенең олуглыгын танып, Адәм галәйһиссәламгә сәҗдә кылырга кушкач, аның моннан баш тартуының сәбәбе – үзен Адәмнән яхшырак итеп санавы була. Ул моны: «Мин уттан яратылдым, ә ул туфрактан», – дип аңлата, утны туфрактан хәерлерәк, олуграк итеп күрә. Әмма, җәмәгать, әгәр без туфракка орлык салсак, ул безгә җимеш бирә, ә утка салсак, ул аны яндырып, һәлак итә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләреннән: «Сезгә җәннәткә кермәүчеләр хакында хәбәр биримме?» – дип сораган. Аңа, әйе, йә, Расүлуллаһ, дип җавап биргәннәр. Ул: «Һәрбер тупас, саран һәм тәкәббер», – дигән.

Шулай ук Пәйгамбәребез: «Үз-үзенә сокланып, (ягъни үзен башкалардан өстен куеп, хәерлерәк санап, тәкәбберләнеп) йөрүче кеше дә җәннәткә керми», – дигән.

Раббыбыз:

وَلَا تُصَعِّرْ خَدَّكَ لِلنَّاسِ وَلَا تَمْشِ فِي الْأَرْضِ مَرَحًا ۖ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ كُلَّ مُخْتَالٍ فَخُورٍ ﴿١٨﴾

**«[Тәкәбберләр кылган кебек] Йөзеңне кешеләрдән чөермә, җирдә масаеп йөрмә. Һичшиксез, Аллаһы һәр масаеп йөргән, үзен яратучы кешене сөйми [һәм аларның бу кыланышларыннан разый булмый]»,** – дип әйтә.

«Локман», 31:18

Җәмәгать, сүз һәрдаим үз-үзен генә күреп, үзендә булган нигъмәтләрнең булуында да үзе генә сәбәпче дип уйлап йөрүчеләр ту-

рында бара. Кайбер кеше үзенең матурлыгы, дәрәҗәсе яки берәр өлкәдә ирешкән уңышлары, кылган эшләре өчен мактанырга ярата. Әмма аңа бу сәләтне, мөмкинлекне, нигъмәтне кем биргәнен оныта. Кызганычка, боларны аңа Аллаһы Тәгалә биргән дип уйлау аның башында да юк. Бу хәл Коръәндәге Карун кыйссасы белән бер. Ул да: «Барысына да мин ирештем, мин булдырдым, мин, мин», – дип йөргән. Пәйгамбәребез: «Берәр кеше үз-үзенә сокланып, тәкәббер рәвештә йөрсә, Аллаһы аны ачуланган хәлдә каршы алыр», – дигән.

Шулай ук Пәйгамбәребез: «Өч төрле кеше җәһәннәмгә беренче булып керер. Ул: гаделсез җитәкче, зәкят бирергә теләмәгән кеше, фәкыйрь тәкәббер», – дигән. Гаделсез җитәкче җәбер-золым кылса, хәлле кеше, мөмкинлеге була торып та садака, зәкят бирмәсә, масаеп, үзен башкалардан хәерлерәк санап, мескеннәрнең хәленә кермәсә һәм кеше фәкыйрь була торып та, тәкәббер булса, Пәйгамбәребезнең әлеге хәдисенә туры килгән була.

Шулай ук Пәйгамбәребез Аллаһы Тәгаләнең Кыямәт көнендә кемнәр белән сөйләшмәвен һәм аларга карамавын хәбәр иткән. Ул кылган яхшылыгын башкаларга гел искә төшереп шелтәләүче, начар товарны ант итеп мактап, ялганлап сатучы һәм тәкәббер кеше.

Аллаһы Тәгалә безне бу сыйфатлардан Үзе сакласа, рәхмәтеннән аермаса иде, чөнки Нәмруд, Фиргавен кебек кешеләр бу гамәлләре өчен дөньялыкта ук җәзасын алган.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*3 нче март вәгазе,*

*шәгъбан аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Бәраәт кичәсе – догада булу вакыты

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Мөхтәрәм җәмәгать, шәгъбән аена да кердек, Рамазан ае да якынлашып килә. Шәгъбән ае Рамазанга әзерләнә торган ай ул. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм иң күп уразаны шәгъбән аенда тоткан дип риваять ителә. Хәдистә килгәнчә, Үсәмә бине Зәед радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребезгә: «Әй Аллаһының Расүле! Шәгъбан аеннан кала, башка айларда синең шул кадәр ураза тотканыңны күргәнем булмады», – дип әйткән. Пәйгамбәребез аңа: «Раҗәб белән Рамазан айлары арасында булган бу ай хакында кешеләр гафил. Бу айда кылган гамәлләр Галәмнәрнең Раббысы хозурына күтәреләдер. Шуңа да гамәлләрем күтәрелгән вакытта уразада булуымны телим»[1], – дип җавап биргән.

Шәгъбан аенда өстенлекләргә ия булган бер кичә бар. Бу шәгъбан ае уртасының 15 нче кичәсендә булган төн – Бәраәт кичәсе. Бәраәт кичәсе «гөнаһлардан арына торган көн» дип тәрҗемә ителә. Мөселманнар бу кичәне, өстенлекләргә ия булу өчен, намазда, зикердә, догада үткәрә. Кызганычка, безнең җирлектә яшәүче күпчелек мөселманнар бу кичәне белми һәм аны билгеләп үтү дөрес буламы икән дип, шикләнеп тә карый. Шикләнәсе юк, бу кичәнең өстенлеге хакында хәдисләр бар. Пәйгамбәребез

[1] Имам Ән-Нәсаинең хәдисләр җыентыгыннан.

салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Гыйззә вә Җәллә шәгъбан ае уртасының төнендә колларына карый, мөшриктән һәм кардәшенә ачу саклаучыдан кала, барлык колларын да ярлыкый»[1], – дигән.

Киләсе хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Шәгъбан ае уртасының төнендә Аллаһы Үзенең колларына карар, мөэминнәрне ярлыкар, имансызларны ярлыкарга ашыкмас, ә инде ачу саклаучыны, моннан арынганчы, ачуы белән калдырыр»[2], – дип әйткән.

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Шәгъбан ае уртасының төнендә Аллаһының Рәхмәте дөнья күгенә төшәр һәм, Бәнү Кәлб кабиләсе сарыкларының йон бөртекләре кадәр, колларының гөнаһларын ярлыкар»[3].

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатыны Гайшә радыяллаһу ганһәдән: «Бу төннең нинди төн икәнен беләсеңме?» – дип сораган. Гайшә радыяллаһу ганһә: «Моны Аллаһы һәм Аның Расүле генә белә», – дип җавап биргән. Пәйгамбәребез: «Бу шәгъбан ае уртасының төне. Аллаһы Гыйззә вә Җәллә бу төндә колларына карар һәм ярлыкау сораучыларны ярлыкар, Рәхмәтен сораучыларга Рәхмәтен ирештерер. Әмма ачу саклап йөрүчеләрне үз хәлләрендә калдырыр»[4], – дип әйткән.

Әлеге һәм бу хактагы башка хәдисләргә нигезләнеп, күпчелек галимнәр шәгъбан аеның 15 нче кичәсен гыйбадәттә, зикердә, истигъфарда, догада үткәрүне хуп күрде. Моның өчен хәтта төнлә белән уяну да кирәк түгел. Әгәр без ятар алдыннан күпмедер вакытыбызны гыйбадәттә, намазда уздырсак, бу төнне гафләттә үткәргән булмабыз һәм, иншәАллаһ, Пәйгамбәребез әйткән әҗерләргә, өстенлекләргә ирешербез.

---

[1] Имам Әт-Табәранинең хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Әл-Бәйһакыйның хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Имамнар Әхмәд, Әт-Табәранинең хәдисләр җыентыгыннан.

[4] Имам Әл-Бәйһакыйның хәдисләр җыентыгыннан.

Әйтелгән бу хәдисләргә карасак, алардан үзебезгә әхлакый дәресләр дә алабыз. Беренчесе, бирендә үз кардәшләренә ачу саклап, алардан аерылып йөрүчеләр хакында искә алына. Хәдистә ул кеше «мушахин» дип әйтелә. Андыйлар күңелләрендә булган ачуны юк итеп, үз кардәшләре белән килешми торып, бу кичтә дә һәм, гомумән, башка вакытта да ярлыканмас, Аллаһының Рәхмәтенә дә ия була алмас. Әмма күңелдәге ачуны бетереп, кардәшең белән килешү өчен, аңа кул сузу зур көч сорый торган эштер. Кардәше белән килешүче – көчле мөэминдер. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөселман кешеләре үзенең кардәшенә ачуланып, өч көннән дә артыграк вакытка аннан читләшергә, бер-берләреннән йөзләрен борырга тиеш түгел. Аларның иң хәерлесе – беренче булып сәлам бирүче»[1], – дип әйткән.

Хәдистән аңлашылганча, ачуланып, бер-береңнән читләшеп, күрешмичә йөрү зур гөнаһтыр. Ә бертуганыңнан читләшүнең гөнаһысы икеләтә булыр. Менә мондый читләшүләр мөселманнарны тарката, зәгыйфьләндерә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөселманнар бер-берсен ныгыта торган таш бина кебек нык булырга тиешләр», – дигән.  Икенчедән, Пәйгамбәребез бу кичәдә уяу булучыга Аллаһы Рәхимле булып, аның гөнаһларын ярлыкар, дип әйтә. Бәраәт кичәсе – гөнаһлардан арына торган кичәдер. Кеше күпме генә гөнаһ кылмасын, аның гөнаһлары биек таулар кебек күп булса да, Аллаһының Рәхмәте һәм ярлыкавы тагы да зуррак. Пәйгамбәребез безгә Аллаһының тәүбә капкалары хакында сөйләгәндә үзенең сахих хәдисләрендә: «Кеше бу капкаларның бер кырыеннан икенче кырыена кадәр атка атланып, җитмеш ел чабар иде», – дип әйткән. Хәтта бөтен дөнья халкы: кешеләр һәм җеннәр барысы бергә берьюлы тәүбә-истигъфар кылсалар да, бу капкалар аларның тәүбәләрен сыйдырыр иде. Кеше истигъфардан туктаганчы, хәтта аның җаны бугазына җиткәнче, Аллаһы аның гөнаһларын ярлыкавын дәвам итәчәк.

[1] Имам Мөслим, Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат Сәйфетдинов,*
*Балтач Үзәк мәчетенең икенче имам-хатыйбы,*
*мөгаллим*

*10 нчы март вәгазе,*

*шәгъбан аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Рамазан ае – зур мөмкинлек

Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын.

Аллаһы Раббыбыз безгә Рамазан аен бүләк итеп бирде. Раббыбыздан бу айда иминлек, сәламәтлек, иман ныклыгы, безләрне гафу итүен, изгелекләребезне кабул итүен сорыйбыз.

Ел әйләнәсендә айларның бөеге, солтаны Рамазан аедыр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әй Аллаһы коллары! Рамазан ае килде. Бу бөек ай сезне үзенең шәүләсе белән каплый», – дигән.

Бу ай – ганимәт, нигъмәт, табыш ае. Без «табыш» сүзен бик яратабыз. Табыш – ул дәүләт, байлык, дөнья малы. Рамазан ае табыш булгач, ул нинди дәүләт, байлык соң? Рамазан ае – дөнья малы, табышы түгел. Уразаны дөньяда байлыкка ирешер өчен түгел, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен, Ахирәт дәүләтенә ирешер өчен тотабыз.

Бу ай кемнәр өчен табыш соң? Рамазан ае бу айга исән-имин, сәламәт килеш ирешүчеләр өчен табыш булып тора. Рамазан аенда ураза тоту фарыз гамәл, ислам диненең рөкене. Мөселман кешесе бу айда Коръән иңгәнен, Коръәнне күп уку тиеш икәнен белә. Имам Әбү Хәнифә хәзрәтләре Рамазан аенда ике тапкыр: көндез вә кич (төнлә) Коръәнне хәтем кыла торган булган.

Рамазан – зикер ае. Бу айда мөселман кешесе Аллаһы Тәгаләне күпләп зикер итә: «Сүбехәнәллаһ, ләә иләәһә илләллааһ» кәлимәләрен еш

әйтә. Без бу айда вакытыбызны Аллаһы Тәгаләгә юнәлтәбез, шуңа күрә бу ай – ганимәт, отыш, дәүләт ае булып тора.

Бу айда Аллаһы Тәгалә тәүбәләрне кабул итә. Раббыбыз дөнья күгенә карап: «Тәүбә итүче, дога кылучы, Миннән сораучы бармы?» – дип сорый.

Коръәндә:

فَمَن شَهِدَ مِنكُمُ الشَّهْرَ فَلْيَصُمْهُ ۖ

**«Сездән берәү Рамазан аена ирешсә, аны ураза тотып үткәрсен...»,** – дип әйтелгән.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Ураза – асылда ашау, эчү, якынлык кылудан тыелу ул. Шулардан тыелмасаң, ураза бозыла. Әмма тыелу дигәндә гайбәт, ялган, ачуланышу кебек гамәлләрдән дә тыелу мөһим. Уразаның асылы – үзеңнең телеңне, колагыңны, күзеңне дә саклау. Рамазан аенда боларны сакламасаң, гамәлләребезнең әҗер-савабы югала. Кыямәт көнендә хәтта тел, күз, колаклардан да соралыр.

Ул тыюлар безнең өйдә генә түгел, кесәләрдә дә йөри. Кесәдән алып, интернетка кереп харам карыйбыз, укыйбыз, тыңлыйбыз. Бүген дөнья болар белән тулды. Шуңа да уразабызны ничек саклау хакында уйланырга тиешбез.

Кайбер кеше көне буе ураза тота, әмма «вакыт узсын» дип, радиодан көне буе җыр тыңлый, концерт, сериаллар карый. Бу вакытта йөрәк тә харамга катнашырга, харам булган начар уйлар да килергә мөмкин. Шушы тыюларны үтәгәндә генә уразабыз камил булыр, иншәАллаһ. Берсен тотып, башкасын тотмасак, ураза дөрес булырмы? Әҗер-савабы, бүләге булмаса, ни эшләрбез?

Тыелуны бозып, кеше үз гамәленең әҗерен үзе бетерә. Тавыш чыгарсак, начар сүзләр сөйләсәк әҗер-савапсыз калуыбыз бар. Шуңа күрә мөселман кешесенең бурычы – уразасын саклау. Ничек сакларга соң, дип

сорасалар, уразаны саклауның бер юлы – гөнаһлы гамәлләрдән ерагаю ул. Мәсәлән, гайбәт сөйләүче янында тормау. Өеңне уттан, малыңны карактан саклаган кебек, уразаңны да сакла. Уразабызны тырышып тотабыз бит, нигә аның әҗер-савабын югалтырга ди?

«Ураза – җәннәт базары», – дип тә әйтелә. Дөнья базарын яхшы беләбез: ул сату, алу, табыш кертү. Ә җәннәт базары – иң олуг табыш, ганимәт, нигъмәт, дәүләт.

«Берәү җәннәт базарын дөнья базарына алыштырса – һәлак була», – ди галимнәр. Уразаны саклау шулдыр, хәтта сине әрләүче, сүгүче булса да, сиңа «мин уразада», – дип әйтү җитә.

Беренче атнада ураза тоту авыррак тоела, кан тамырлары кысылмаган була, шәйтан кан тамырларыннан йөри, кешегә вәсвәсә кыла. Кан тамырлары кысылгач, шәйтанга да юл кысыла, тарая, кешегә дә ураза тоту җиңеләя. Рамазан аен хөрмәт итү: сөенеп каршы алу, моңаеп озату – мөселман кешесенең бурычы.

Монафикъка уразамы, түгелме икәнлеге барыбер. Аның тормышында үзгәреш юк, ул ашый, эчә, кино, театр, концерт карый, ә мөселман кешесе саклана.

Аллаһы Тәгалә безгә шул рәвешле мөмкинлек, форсат бирде. Шушы форсатны кулдан ычкындырмау мөһим. Безгә элек кылган, хәзерге, киләчәктәге хата-ялгышларыбызга тәүбә итү мөмкинлеге ачылды. Аллаһы Тәгалә бу айның дәрәҗәсен күтәрде: бу айда тәравих намазлары, Кадер кичәсе бар.

Белүебезчә, ураза ае өчкә бүленә: беренче ун көне – Аллаһы Тәгаләнең Рәхмәте; икенче ун көне – Аллаһы Тәгаләнең гафу итүе, ярлыкавы; өченче ун көне – уттан котылу көннәре. Боларны өмет итеп тырышучы кеше «мөхсин», ягъни ихласлы кешедер. Әйе, Аллаһы Тәгаләнең ихлас колы шушы айда өч нигъмәтне алып калырга тырыша. Тырышмасак, ай тиз үтеп китәр, бу нигъмәтләр булмас.

«Рамазан» сүзе «көйдереп яндыру» дигән мәгънәне аңлата. Бу җәһәннәм кызуыдыр. Бу айда, иншәАллаһ, шушы эсселектә мөселманның гөнаһлары «янар». Бу айда җәһәннәм утыннан йә котылабыз, йә юк.

Галимнәр: «Рамазан – мәктәптер», – дип әйтә. Мәктәпне тәмамлаганда имтихан бирәбез, аны ничәгә бирүебез мөһим. Әгәр Рамазан ае имтиханын да «яхшы» билгесенә тапшырсак, иншәАллаһ, Аллаһы Тәгаләнең ярлыкавына ирешербез.

Хәдистә болай дип әйтелгән: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөнбәргә күтәрелгәндә өч мәртәбә «әәмиин» дигән. Сәхабәләр аннан моны аңлатуын сораган. Ул: «Миңа Җәбраил галәйһиссәлам өч әйберне ирештерде. Шуңа мин: «Әәмиин», – дидем. Болар: берәү Пәйгамбәр исемен ишетеп тә, аңа салават-сәлам ирештермәсә – шул кеше Кыямәт көнендә үкенечтә булыр (җәннәтнең исен дә сизмәс). Берәү әти-әнисен картлыкта табып, аларга игелек күрсәтмәсә – шул Кыямәт көнендә үкенечтә булыр. Берәү Рамазан ае килеп тә, Аллаһының ярлыкавын алмаса – шул җәннәттән ерак булыр», – дигән. Димәк, уразаның олуг максаты – Аллаһы Тәгаләнең ярлыкавына өметләнеп, шуны алырга тырышу.

Рәхәттә яшәгәндә адәм баласы Раббысын оныта, тәмле ашап-эчеп, йоклап, гаиләсе белән бергә булып, рәхәтләнеп яши.

Аллаһы Тәгалә «Ашама, эчмә, якынлык кылма! Туктап тор!» дигән тыюы белән безне ураза мәктәбен «яхшы» тәмамларга әзерләде.

Шәйтан безне аздырырга тырыша. Әмма ураза аенда ул богауда булыр. Аллаһы Тәгалә безне:

كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ

**«Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды»,** – дип юата.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Димәк, без генә түгел, безгә кадәр яшәүчеләр дә ураза тоткан. Аллаһы Тәгалә безне, безнең тәкъвалыкны сыный. Тыелу – тәкъвалык билгесе ул. Ураза тотмаучы тыелмый, ул ваемсыз, куркусыз.

Һәр мөселман кешесе үз-үзенә: «Мин уразадамы?» – дип сорау бирергә тиеш. «Әйе, уразада», – дигән җавап алгач, «Ә шулай булгач, миндә нәрсә үзгәрде?» – дип уйлану, фикерләү мөһим.

Башка гыйбадәтләр күзгә күренә: кеше намаз укый, хаҗ кыла, зәкят түли, ә ураза – ул Аллаһы Тәгалә белән кеше арасындагы сер. Аллаһы Тәгалә Үзе генә безнең уразалымы, түгелме икәнне белә. Шуңа күрә дә Раббыбыз: «Ураза Минем өчен (чөнки ул яшерен). Аның әҗерен Үзем бирәм», – дип әйтә. Башка гыйбадәтләр өчен ун, җитмеш әҗер булса, ураза өчен  җиде йөз, мең, хәтта билгесез әҗер-саваплар каралган. Кеше әҗерне күпләп җыя, чөнки бу гамәлдә рия юк, беребез дә кеше күрсен, мактасын өчен ураза тотмый.

Галим, фәкыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди Ибне Габбастан риваять ителгән сүзләрне әйткән: «Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Дөреслектә, Рамазан ае кергәндә җәннәт зиннәтләнә. Рамазан киче булса, Гареш астында җил исәр («Мәсирә» җиле). Шул җилдән җәннәт агачының яфраклары, ишек боҗралары селкенер. Хур кызлары җәннәтнең югары баскычыннан карап: «Нинди кунак (яучы) килә?» – дип сорар. Ризван фәрештә: «Ий күркәм изге кызлар! Бу кич Рамазан аеның беренче киче», – диярь».

Аллаһы Тәгалә җәннәтне һәм җәһәннәмне яратты, җәннәттә алтын сарайлар булдырды. Хуш бакчаларда хуш агачларны, татлы елгаларны бар кылды, җәннәттән: «Йә җәннәтем! Ни әйтерсең?» – дип сорады. Җәннәт: «Дөреслектә, мөэминнәр уңышка иреште, ягъни алар җәннәт әһеле булды. Мөэминнәргә шундый матур, гүзәл урын насыйп булачак», – диде. Шуңа Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

قَدْ أَفْلَحَ الْمُؤْمِنُونَ ﴿١﴾

**«Иман китерүчеләр хәзердән уңышка иреште [һәм өметләре гамәлгә ашты]»,** – дип әйтә.

«Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:1

Ураза тотучылар да Аллаһы Тәгалә ризалыгын, җәннәтне, җәһәннәм утыннан котылуны өмет итә. Аллаһы Тәгалә бу дөньяны яратты, җанны, нәфесне бар кылды. Раббыбыз җаннан: «Йә җан! Кем синең Раббың?» – дип сораган. Җан: «Син минем Раббым», – дип таныган, әмма нәфес Раббысын танымаган. Аллаһы Тәгалә нәфесне 100 ел ач тотканнан соң кабат сораган, әмма нәфес бу юлы да танымаган. Моннан соң Аллаһы Тәгалә нәфесне тагын 100 ел ач тоткан. 200 ел ач торгач кына нәфес: «Син безнең Раббыбыз», – дип, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләне таныган.

Кешене ялгыш юлга, адашуга ике нәрсә этәрә: шәйтан һәм нәфес. Рамазан аенда нәфесне тыю – гыйбадәт булып тора. Бу айда шәйтанның зурлары богауда, ә нәфес юк. Нәфесне кеше үзе генә җиңә ала. Кеше нәфесен җиңсә, изге гамәлләр кыла.

Бу айда ураза җиңел тотыла, гамәл-гыйбадәтләр арта, ашамыйбыз, эчмибез, биш вакыт намазга 20 рәкагатьле тәравих намазлары, нәфел намазлары да өстәлә, әлхәмдүлилләһ, Коръәни Кәрим дә ешрак укыла. Әйе, Рамазан – Коръән ае ул. Бу айда мөселманнар көн саен Коръән укый. Рамазанда аеруча тырышлык кирәк, чөнки бу ай тәрбия ае. Аллаһы Тәгалә безне Коръәни Кәрим аша тәрбияли.

Гомәр радыяллаһу ганһе бер әмирдән: «Син җирлеккә вәли итеп кемне җибәрдең?» – дип сораган. Ул: «Ибне Әбзәәне», – дип җавап биргән. Гомәр радыяллаһу ганһе: «Кем ул?» – дигәч, әмир: «Азат ителгән кол», – дип җавап кайтарган. «Син колдан башка яхшырак кеше тапмадың мени?» – дип соралгач, әмир: «Ибне Әбзәә – Коръәнне иң яхшы белүче», – дип җавап биргән. Димәк, әмир өчен Коръәнне белү иң югары күрсәткеч булып торган.

Коръән Аллаһы Тәгаләнең сүзе. Коръән фикерләүчеләр өчен ачык нур, ачык сүз. Коръәнне иртә, көндез, кич, төнлә уку, аны кадерләү мөһим. Коръән – Кыямәт көнендә синең дәлилең. Расүлебезнең хәдисендә: «Кыямәт көнендә Коръән укучысын яклар», – диелә. Рамазан, Коръән – безнең яклаучыларыбыз. Ә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм – шәфәгатьчебез. Тәфсирләрдә: «Коръәни Кәрим – ул яңгыр кебектер», – диелә. Эре, яхшы яңгырдан соң җир төзек була, игеннәр гөрләп үсә, җир йөзе чәчәккә күмелә, җиләк-җимеш җитешә. Ә Коръән – адәмнәрнең төзеклегенә сәбәптер. Әгәр Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәсә, адәм баласы да төзек булыр. Аллаһы Тәгалә безгә нәрсәләр куша? Раббыбыз безгә даими рәвештә намазларны укуны, ураза тотуны, ураза һәм намаз белән Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорауны куша.

Рамазанда Аллаһы Тәгалә безгә Үзенең биш төрле Рәхмәтен насыйп итә. Болар:

1) Ифтар, сәхәр;
2) Тәүбә;
3) Коръәни Кәрим;
4) Тәравих;
5) Кадер кичәсе.

Хатын-кызларга да тәравих намазын уку, иманны ныгыту, мөселман өммәтенең бердәмлеген сизү өчен мәчеткә килү хуплана. Әмма бирегә хатын-кыз ачык, матур киемнәр киеп килергә тиеш түгел. Өеңнән чыкканда ук: «Мин бүген ураза идем», – дип уйла. Шулай ук мәчет әдәбен, мәчеткә керү-чыгу әдәпләрен истә тоту мөһим. Ифтардан соң да ураза әҗерен киметәсе түгел икәнне истә тотыйк.

Рамазан – бәрәкәт ае, хөрмәтле ай, аның кадерен белик. Бу айда Аллаһы Тәгаләнең бәрәкәте, сәкинәсе, Рәхим-Рәхмәте иңә. Әлеге айда мөселманнар Аллаһы Тәгаләнең Рәхмәтен өмет итә.

Адәм балалары үз тормышларын бизәр, ял итәр өчен төрле бәйрәмнәр оештыра: яңа ел, 8 март, 23 февраль, әтиләр, әниләр көне, туган көн, сабантуй һ.б. бәйрәмнәргә кешеләр алдан бик сөенеп әзерләнә: ризык, кием, бүләк әзерли, кунак чакыра, өй җыештыра, өй бизи. Бу – дөньяви бәйрәмнәр. Ислам динендәге бәйрәмнәребез: ике гает һәм алардан да олуг булган җомга көне. Тиздән кунак киләчәк. Ул – Рамазан аедыр.

Без дөньяви кунакларны каршы алырга, бәйрәмнәргә әзерләнгән кебек, Рамазан аен каршы алырга әзерме? Мөселман кешесе үзен рухи яктан ничек әзерләргә тиеш? Бу хакта галимнәрнең киңәшләре бар. Безгә: «Йә Раббым! Мине сәламәт хәлемдә Рамазанга ирештер!» – дип дога кылу тиешле, чөнки кеше сәламәт булмаса, ураза тота алмас, гыйбадәттә кимчелекле булып, җаны әрнер, үзен гаепле тояр. Әлхәмдүлилләһ, Рамазанга әзерләндек, дога кылдык. Аллаһы кабул кылсын.

Рамазан сүзе гарәпчә «саум» дип атала, «саум» – «тыелу» дигәнне белдерә. Ураза тоту – эссе, озын көннәрдә ашамыйча, эчмичә тыелып тору, Аллаһы Тәгалә кушканны үтәү ул. Аллаһы Тәгалә бу тыелуга фазыйләтләрен белдерде: «Әҗер-савабын Үзем бирәчәкмен», – диде.

«Әр-Райян» ураза тотучыларның җәннәткә керә торган капкалары. Рамазан аенда җәннәт капкалары ачылыр. «Әр-Райян» капкасыннан тыш:

– Намаз капкасы;

– Садака капкасы;

– Тәравих капкасы;

– Тәһарәт капкасы;

– Юмартлар капкасы;

– Сабырлар капкасы бар.

Берәү тәһарәтле булып намаз да укыса, ураза да тотса, тәравих намазын да укыса, юмартлык та күрсәтсә, сабыр да булса, аның хәле ничек булыр? Шуңа да Аллаһының Рәхмәтенә ирешүгә омтылыйк.

Рамазан – хөрмәтле, бәрәкәтле ай, аның кадерен белик. Бу айда изгелекләрнең әҗер-савабы арта. Аны Аллаһы Тәгалә арттыра. Кайбер изгелекләрне карап үтик.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә күчкәч, мәчет төзетә. Шул мәчеттә болай дип вәгазь сөйли: «Кешеләр! Киләчәктә үзегез өчен берәр нәрсә әзерләп куегыз. Белегез: Аллаһы Тәгалә: «Минем Расүлем сиңа килмәде мени? Сиңа әйтмәде мени? Ә син киләчәк өчен үзең ни әзерләдең?» – дип сорар. Кеше Кыямәт көнендә эзләнер: уңга, сулга карар. Алга карар – анда тәмуг булыр. Шуңа да адәм баласы ярты гына хөрмә белән булса да, үзен уттан коткарсын. Берәү аны да таба алмаса, яхшы сүз сөйләсен, яхшы уй уйласын. Аңа моның өчен 100 мәртәбә артыграк әҗер-савап бирелер. Ул – Аллаһы Тәгаләнең Рәхмәте (җәннәт)».

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу вәгазе безгә һәрвакытта да әһәмиятле, Рамазан аенда аеруча да. Үзебездән соң да кала торган садакаи-җәрияләр әзерлик: чишмәләр төзәтик, юлларны чистартыйк, агачлар утыртыйк, гыйлем алып, аны тапшырыйк, үзебездән соң изге бала калдырыйк.

Сезгә шундый кыйсса сөйләп үтәм: төрек солтаны Мурад үзенең казначысы белән биләмәләрен карарга чыга һәм бик карт бер бабайның агач утыртуын күреп: «Әй бабай! Ул агачны нигә утыртасың? Син бик карт, бу агачның җимешен инде ашый алмассың», – дип әйтә. Карт: «Мин ашамасам балалар, оныклар, башка кешеләр ашар. Агач күләгәсе астында ял итәрләр, хәл алырлар. Ә миңа Аллаһы Тәгалә әҗерен Үзе бирер», – дип җавап бирә. Бу кыйсса безне изге гамәлләр кылырга чакыра.

Аллаһы Тәгалә бу айда безнең гөнаһ-хаталарыбызны гафу итә. Уразада җәһәннәм ишекләре ябыла, җәннәт ишекләре ачыла. Шуңа да җәннәткә керер өчен тырышлык куйыйк, ул үзенә керүдә тырышлык куючыларны көтә».

Аллаһы Тәгалә безнең күк йөзенә Корьәнне Рамазан аенда тулысынча иңдерә. Аннары Корьәни Кәрим 23 ел дәвамында өлеш-өлеш итеп, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдерелә. Рамазан аеның соңгы ун төнендә мәртәбәле кичә бардыр. Ул бөек кичәләрнең берсе. Бу вакытта фәрештәләр иңәр, алар Корьән укыган җирдә җыелып, ана кош баласын саклаган кебек, шул урынны әйләндереп алыр, канатлары белән каплар. Җир йөзендә күпме вак таш булса, фәрештәләр саны шуннан күбрәк. Бу вакытта ай ялтырап торыр. Күп риваятьләрдә фәрештәләр Кадер кичәсендә яратылган, шул кичәдә җәннәттә агачлар утыртылган, шушы кичәдә Адәм галәйһиссәламне бар итү чималы җыелган, дип килә.

Мөэмин-мөселман һәрдаим Кадер кичәсен эзләгән, Аллаһы Тәгаләнең Рәхмәтенә өметләнгән. Әйе, әгәр динне белергә тырышсак, галәмәтләрен эзлибез.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин төштә Кадер кичен, балчыклы суда намаз укыганымны күрдем», – дигән. Һәм 21 нче төндә көчле яңгыр ява, мәчет түбәсен алып ыргыта, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм балчыклы суда намаз укый. Бер сәхәбә: «Аның маңгаенда балчык иде. Бу 21 нче төн иде», – дигән.

Аллаһы Тәгалә җиде кат күкләрне, җиде кат җирләрне яраткан. Адәм галәйһиссәламне җиде төрле балчыктан бар иткән, Адәм баласына җиде төрле ризык билгеләгән: су, сөт, тоз, җимеш, орлык (ярма, он), балык, ит. Никахка җиде төрле туган харам була. Хаҗда Кәгъбә тирәли җиде тапкыр әйләнелә, сәгыйдә җиде тапкыр йөреп узыла. Мөгаен, Кадер киче Рамазанның соңгы ун көненең җиденче кичәсендәдер. Бер карт Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе янына килеп: «Кадер киче кайчан? Мин бик карт. Ун төн буена намазларның кыямында басып торырга көчем җитми», – дип әйткән. Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе: «Рамазанның 27 нче кичәсен калдырма», – дип җавап биргән.

Шушы ун төнне уяу булып үткәрү авырмы икән? Уйлап карасак, кайбер хезмәт ияләренең, гаиләне тәэмин итү, ризык табу өчен, гомерләрен төнге эштә (мәсәлән, тимер юл, һава юллары, медицина, полиция, янгын сүндерү хезмәте) уздыруын беләбез. Ә безгә ун төн тырышсак, иншәАллаһ, Аллаһы Тәгалә 83 ел гыйбадәт кылган әҗер-савабын бирер, Үзенең Рәхмәтен салыр, безне уттан коткарыр.

Гает көнендә Аллаһы Тәгалә фәрештәләрдән: «Әй фәрештәләрем! Эшне яхшы башкаручыга ни хак булыр?» – дип сорар. Фәрештәләр: «Тулы хак», – дип җавап кайтарыр. Аллаһы Тәгалә: «Күрегез фәрештәләрем! Минем колларым уразаны тәмам кылып, гает намазына килде, Миңа дога кылалар. Үземнең Бөеклегем, Кодрәтем, Гыйззәтем белән ант итәм, Мин аларны гафу итәм, догаларын кабул кылам», – дип әйтер.

«Берәү гает көнендә әрвахларга дип, 300 тапкыр «Сүбехәәнәллааһи вә бихәмдиһи» дип әйтсә, һәр әрвахка 1000 нур ирешер», – диелә.

Гает иртәсендә Аллаһы Тәгалә фәрештәләрне җир йөзенә җибәрә. Фәрештәләр юл чатына басып, көчле тавыш белән: «Әй Мөхәммәд өммәте! Юмарт булган Раббыга барыгыз, Ул сезне бүләкләр һәм гөнаһларыгызны гафу итәр», – дип чакырырлар икән.

Рамазан ае фазыйләтләре:

1. Кешедә тәкъвалык арта, тәкъвалык иманны куәтли. Ураза тотып кеше Аллаһы Тәгалә боерыгын үти, Ул тыйганнан тыела.

2. Күңелләр йомшара, нечкәрә. Бай кеше дә, фәкыйрь кеше дә ураза тота. Аллаһы Тәгалә каршында без барыбыз да тигез.

3. Кешедә гөнаһка каршы тору көче арта, адәм баласы сабырлык дәресләре ала.

4. Аллаһы Тәгалә – Мәрхәмәт иясе. Ул ризыкландыра. Ризыкны Аллаһы Тәгалә бирмәсә, яңгыр яумаса булмый. Уразада ризык булса да, без Аллаһы Тәгалә тыюын үтәп, аңа кагылмыйбыз.

5. Уразалы булулары белән, Аллаһы Тәгалә каршында кешеләр бертигез, әмма кемнең иманы куәтлерәк, шул кеше Аллаһы Тәгалә каршында өстенрәк. Кем баерак, шул өстенрәк түгел, чөнки байлыкны Аллаһы Тәгалә бирә.

6. Әхлакый тәрбия дәресләре алабыз: гайбәт сөйләмә, сүзләшмә, күршеңнең, туганнарыңның хәлен бел.

7. Рамазан – юмартлык ае. Бу айда садакалар бирелә, бер-береңә ярдәм күрсәтелә, Аллаһы Тәгалә биргән байлыктан фәкыйрьләргә өлеш чыгарыла.

8. Бу айда бердәмләшү көчле. Уразада, ифтарларда, тәравихларда без үзебезне өммәт итеп сизәбез, шуңа сөенәбез, шөкер итәбез.

9. Рамазан – югары дәрәҗәдәге бәрәкәт ае. Уразаның беренче ун көне – Аллаһы Тәгаләнең Рәхмәте, икенче ун көне – гафу ителү, өченче ун көне – уттан котылу көннәре булды. Бу югары дәрәҗәләрне Аллаһы Тәгалә мөэминнәргә вәгъдә итте.

10. Рамазан аенда сәламәтлегебез яхшыра. «Сәламәт буласың килсә – ураза тот», – дип әйтелгән. Уразада безнең әгъзалар: ашказаны, эчәклекләр ял итә. Ял итү – сәламәтлек ул. Кеше күп ашап, йоклап сәламәтлегенең начарлануын аңлый.

Рамазан – ул шундый айдыр, ул айда җирне, барлык галәмне нурландырып, Коръән иңде, ул якты маяк булып балкып, безгә туры юлны күрсәтте, хак белән батылны аерып аңлатып бирде. Коръән буенча гамәл кылу, Аллаһыбыз кушканча яшәү нинди зур шатлык, никадәр бөек дәрәҗә бит ул, туганнар! Быелгы Рамазан аен да без – мөселманнар шатланып, сөенеп каршы алабыз. Раббыбыз Аллаһы Тәгалә билгеләп куйган әлеге сынауны һәммәбезгә дә уңышлы үтәргә насыйп булсын.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рәдиф хәзрәт Тимергалиев,*

*Кукмара районы мөхтәсибе*

*17 нче март вәгазе,*

*шәгъбан аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Рамазан ункөнлекләренең хикмәте

Мәрхәмәтле һәм Рәхимле булган галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкраналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның мостафасы Пәйгамбәребезгә салават-сәламнәр әйтәбез.

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ, хөрмәтле мәхәллә халкы, мөселман дин кардәшләрем! Айларның солтаны Рамазан ае һәркемгә әҗерләр алып килсен. Ошбу айны гамәл-гыйбадәттә: ураза тотып, төннәрен тәравихта булып, Коръән укып, Кадер кичен каршы алып, аны табу бәхетенә ирешеп, дога-истигъфарда уздырырга насыйп итсен. Көннәрнең иң хәерлесе булган җомга көне һәрбарчабызга мөбарәк булсын. Җомга көненең фазыйләтләренә, вәгъдә ителгән әҗер-савапларына ирешергә насыйп итсен. Аллаһы Тәгалә һәрбарчабыздан разый булсын.

Газиз дин кардәшләрем! Аллаһы Тәгалә күп әҗер-саваплар, дәрәҗәләр вәгъдә иткән Рамазан аеннан файдаланып калыйк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Бер адәм Рамазан аен шатланып каршы алса һәм Рамазан аеның үтеп китүенә күңеле белән яхшы айлар үтте дип кайгырса, ул адәмгә мәңгелек сәгадәт, рәхәт йорты булган җәннәт вәҗиб (тиешле) булыр».

Икенче бер хәдистә Аллаһының Расүле болай дигән: «Әгәр кешеләр Рамазан аеның бөтен хасиятләрен, савапларын белсәләр, бөтен ел әйләнәсе Рамазан ае булуын теләрләр иде». Бу хәдистән аңлашылганча, Рамазан аеның хасиятләре күп булып, хәтта без аның күп өлешен дөньяда, алдагы гомеребездә һәм Ахирәттә күрәчәкбез, сөенәчәкбез.

Мөхтәрәм җәмәгать! Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Рамазан аеның беренче ункөнлеге Аллаһы Тәгаләнең Рәхмәте көннәре, икенче ункөнлеге гөнаһлардан пакьләнү көннәре һәм соңгы ункөнлеге җәһәннәм утыннан котылу көннәре», – дигән. Ягъни, Рамазан ае тулаем алганда саваплы һәм изге ай булып, Пәйгамбәребез безгә һәрбер вакытының хасиятләрен җиткерә. Һәрбер эшнең үз нәтиҗәсе булган кебек, ошбу айның да һәр вакыты безгә билгеле бер җимеш китерә.

Рамазан аеның беренче ун көне – Аллаһы Рәхмәтенә ирешергә мөмкинлек бирелә торган вакыт. Аллаһы Рәхмәтенә ирешү исә бик тә мөһим нәрсә, аңа ирешүче кеше чын бәхет иясе булды дигән сүз. Дөнья һәм Ахирәт бәхете бары тик Аллаһы Тәгалә Рәхмәтенә генә ирешеп килә. Дөрестән дә, безнең ниндидер уңышка ирешүебез, эш-максатларыбызның тормышка ашуы фәкать Аллаһы Рәхмәте һәм ярдәме белән бәйле. Бервакыт Аллаһының Расүле сәхабәләрен җыйды да: «Бер кеше дә гамәлләре белән генә җәннәтле булмый, бары тик Аллаһының Рәхмәтенә ирешеп кенә җәннәтле була», – диде. Чыннан да, гамәлләребезне кылып, алар Аллаһының рәхмәтенә ирешүгә сәбәп булса, без мәңгелек бәхеттә булабыз икән.

Рамазан аеның икенче ун көне – гөнаһларның гафу ителү көннәре (мәгъфирәт). Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә гөнаһларыбызны ярлыкасын өчен, Аңа ихлас күңелдән мөрәҗәгать итеп, гафу итүне сорарга кирәк. Хәдисләрнең берсендә шундый тирән мәгънәле, уйландыра торган мәгълүмат хәбәр ителә: көннәрдән бер көнне пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер кеше килә дә фәкыйрьлектән, акча җитмәүдән зарлана. Пәйгамбәребез аңа: «Аллаһыдан гөнаһларың өчен гафу итүен сора», – дип киңәш бирә. Икенче кеше килеп: «Хатыным белән ничә ел торабыз, әмма балаларыбыз юк», – дип, борчуы белән уртаклаша. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа да: «Тәүбә-истигъфар

кылыгыз, гөнаһлар өчен Аллаһыдан гафу үтенегез», – дип җавап бирә. Өченче кеше килеп Пәйгамбәребезгә: «Безнең җирлектә корылык, инде күп вакыт яңгыр яумый», – дип әйтә, дүртенче кеше исә: «Бездә яңгыр ява, ләкин уңыш юк», – дип зарлана. Аларга да Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шул ук сүзләрне кабатлый: «Тәүбә-истигъфар кылыгыз, Аллаһыдан гөнаһларыгыз өчен гафу үтенегез», – дип нәсыйхәт кыла. Моны ишеткән сәхабәләр аптырап: «Йә, Аллаһының Расүле, дүрт кеше дүрт төрле мәсьәлә белән мөрәҗәгать итте, әмма барысына да бер үк киңәш бирдең...», – дип әйтә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә: «Бу минем сүзем түгел, моны Аллаһы Тәгалә Коръәндә шулай киңәш итә...», – дип җавап бирә. Әйе, Аллаһы Тәгаләнең мәгъфирәте (ярлыкавы) олуг нигъмәт, Галәмнәрнең Раббысы кичермәсә, безне якын итмәсә без мескен, ятим хәлдә калабыз.

Рамазан аеның өченче ун көне – тәмуг утыннан котылу көннәре. Бу вакыт – уразаның ахыры. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Гамәлләр ахырына карап бәяләнә», – дип әйткән. Ягъни, эшне башлау гына түгел, тулы рәвештә тәмамлау да бик мөһим икән. Кем дә кем шул көннәрне тәкъвалык белән ихластан гыйбадәттә үткәрсә, аның җәһәннәм утына керүгә сәбәпче булган гөнаһлары ярлыканыр һәм Рамазан ае ахырына ул гөнаһсыз, чиста күңелле бала кебек булыр. Шунысын да аерым әйтеп китәргә кирәк: ахыргы ункөнлегенә мең айдан да хәерлерәк булган Кадер кичәсе дә туры килә. Игътикяф гыйбадәтенең дә нәкъ менә шушы чорга билгеләнүендә зур хикмәт бардыр.

Шулай итеп, Рамазан аенда Аллаһы Тәгалә мөэмин-мөселманнарга бик күп бүләкләр вәгъдә итә, белгәнебезчә, Аллаһы Раббыбыз вәгъдәсен бозмас. Ә безгә бары тик Аллаһының шушы Рәхмәтеннән файдаланырга гына кирәк. Аллаһы Тәгалә хәерле сәламәтлекләр биреп, Рамазан айларыбызны да, үзенә муафыйк булганча, изгелектә, гамәл-гыйбадәттә үткәрүләребезне насыйп итсә иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Инсаф хәзрәт Ибатуллин,*

*«Динислам» мәчете имам-хатыйбы*

*24 нче март вәгазе,*

*Рамазан аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Рамазан ае – кадерле кунак

Мәрхәмәтле һәм Рәхимле булган галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкраналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның мостафасы Пәйгамбәребезгә салават-сәламнәр әйтәбез.

Иң хуш, күркәм кунакларның берсе Рамазан аедыр. Рамазан ае һәр елны безгә үзенең бүләкләре белән килә. Бу айның иң бөек бүләге – өммәтебез өчен коткару чарасы булган уразадыр. Бер өммәткә дә мондый күркәм вазифа бирелмәде. Безгә кадәр яшәүчеләр бик теләгән булсалар да, ахырзаман өммәтенең шундый нигъмәт белән бүләкләнүен хәтта күз алдына да китерә алмаслар иде. Раббыбыз Коръәни Кәримдә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»** – дип, безне гыйбадәт кылырга чакыра.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Бу аять безгә кадәр яшәгән өммәтләргә дә Аллаһы Тәгаләнең ураза тоту гыйбадәтен йөкләвен аңлата. Әмма аларда сәхәр ашау юк иде, ә безгә Раббыбыз сәхәр вакытында ашау мөмкинлеген биргән, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аша аның тәртипләрен өйрәткән. Безнең

өммәткә хәтта соңгы минутына кадәр сәхәр ашау мөстәхәб гамәл булып тора. Шулай ук ифтар вакыты җиткәннән соң авыз ачарга ашыгу да өммәтебез өчен хәерле. Ә безгә кадәр булган өммәтләргә сәхәр вакытында ашау ярамый иде. Алар кич ашаган белән, икенче көнне көне буе ураза тоталар, авыр эшләр эшлиләр иде. Чыннан да, безнең өммәткә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә җиңеллекләрне күп биргән. Шул ук сәхәрләр, ахшам вакыты керү белән үк авыз ачулар – болар барысы да Аллаһы Тәгаләнең бүләге. Без боларның кадерен белергә тиеш.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең икенче бүләге – Коръәни Кәрим китабы. Кызганычка, еш кына Изге Китабыбызның кадере кимегәнен күзәтәбез. Коръәндә:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۚ

**«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән [ай]»,** – дип әйтелгән.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Бу аятьтә аңлавыбызча, Раббыбыз Үзе кешегә тугры юлдан барырга ярдәм итә, хәләл белән харамны аерырга өйрәтә. Әмма бездә Аллаһының шушы нигъмәтен, Аның сүзен кадерләү аз.

Кызганычка, бик еш Коръәнгә тиешле дәрәҗәдә карамаганнарын, аны саклык белән кулга алмаганнарын күрәбез. Ә бит анда безне туры юлга күндерү аятьләре, Аллаһының рәхмәте белән, безне җәһәннәм газабыннан коткара торган, безнең өчен каберстанда һәм Кыямәт көнендә шәфәгатьче була торган аятьләр язылган.

Раббыбызның өченче бүләге – тәравих намазы. Әлеге намазга килгәндә, безгә бик еш аның ничә рәкәгать укылганлыгын, кемнән кал-

ган гыйбадәт икәнлеген аңлатырга туры килә. Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе үзе Коръәни Кәримне яхшы белүче сәхабәләрнең берсе булган Үбәйй бине Кәгъб радыяллаһу ганһене тәравих намазын укытырга бастырган. Әгәр уйлап карасак, Гомәр бине Әл-Хаттаб вакытында берәрсе, бүгенге вакыттагы кебек, тәравих намазын укымыйча мәчеттән чыгып китә алыр идеме икән?! Гомәр бине Әл-Хаттаб Үбәйб бине Кәгъб радыяллаһу ганһенең бөтен өммәтне җыеп, аларның бергәләшеп тәравих намазларын укуларына бик нык шатлана торган булган. Шуңа да тәравих намазына карата шик булырга тиеш түгел.

Әбү Бәкер Әс-Сиддыйк, Гомәр бине Әл-Фәрук, Госман бине Гаффан Зиннурайн радыяллаһу ганһүмә, Гали бине Әбү Талиб кәррамәллаһу вәҗһәһу – бу дүрт хәлифәнең һәр сүзе, һәр сулышы безгә Расүлебез тарафыннан вазифа булып калган гамәлдер. Тәравих намазы да шулай ук безгә йөкләнгән намаздыр, җәмәгател-мөслимин.

Рамазан аеның дүртенче бүләге – Гает. Аның кадерен, дәрәҗәсен Рамазан аенда ураза тоткан кеше генә тулысынча аңлый аладыр. Әйе, ул бик зур бүләк. Әгәр дә мөселман өммәтендә Корбан Гаетенең икенче исеме «Гыйдел-Кәбир», ягъни «Зур Гает» булса, Ураза Гаете исә «Гыйдел-Сагыйр», ягъни «Кечкенә Гает» дип аталадыр.

Гает – зур нигъмәт. Җәйге озын вакытларда безнең җирлектә дә, җылы яклардагы кебек, егермешәр сәгать ураза тотабыз. Тәүлегенә егерме сәгать ураза тоткан кеше калган дүрт сәгатенең һәр минутын кадерләп үткәрә. Шул сәбәпле вакытны кадерләргә дә өйрәнәбез. Гаетләр, ифтарлар бик зур шатлык, зур бәхеттер. Адәм баласына һәр ифтар шатлык китерәдер һәм һәр ифтар бәйрәмдер.

Раббыбыз тоткан уразаларыбызны кабул кылып, кадерле кунагыбыз булган Рамазан аеның бүләкләрен тиешле дәрәҗәдә, файдалы итеп кулланыуыбызны насыйп итсә иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин,*

*Коддус мәчете имам-хатыйбы*

*31 нче март вәгазе,*

*Рамазан аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Гафиллектән ерак булыйк

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, мактауларыбыз, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булса иде. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Хөрмәтле мөселманнар! Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында болай дип әйтә:

ٱقْتَرَبَ لِلنَّاسِ حِسَابُهُمْ وَهُمْ فِي غَفْلَةٍ مُّعْرِضُونَ ﴿١﴾

**«Кешеләргә [Аллаһы Тәгалә тарафыннан] хисаплары бик якынлашты. Алар исә [хисаптан, аңа әзерләнүдән] гафләт эчендәләр, [бу мәсьәләне җитдигә санамыйча] йөз чөерәләр».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:1

Нәрсә соң ул гафиллек? Гафиллек ваемсыз, гамьсез, саксыз, игътибарсыз дигәнне аңлата. Хөрмәтле кардәшләрем, хәзерге заманда гафиллеккә кереп китү аеруча да куркынычтыр. Ни өчен дисәгез, чөнки Адәм баласы ни тели – шуны эшли ала, аңа барлык юллар ачык. Моның өчен хәтта өеннән дә чыгып торырга кирәкмидер. Үзебезгә генә игътибар итик: безгә гыйбадәт кылу авыр, ә гөнаһ кылу җиңел. Намаз вакыты үтеп китә, уйланмыйбыз да, «иһ, намазым калды», дип йөрәкләр дә сыкранмый. Гөнаһ кылабыз, ә йөрәгебез борчылмый, әгәр инде мең тәңкә акчабыз югалды икән, аһ-ваһ киләбез. Әлбәттә, гафиллекнең төп сәбәбе – ул

дөнья сөюдер. Әгәр кешегә мал бирәм дисәләр, кеше тырыша, булдыра, ләкин нәрсәне дә булса Аллаһы ризалыгы өчен эшләргә ашкынмый.

Раббыбыз: «Мәчет төзегән кешегә җәннәттә йорт төзермен», – дип әйтә. Әгәр «Мәчет төзегән кешегә чит илдә фатир бирәбез» дисәләр, бөтен кеше мәчет төзергә тырышыр иде. Әмма Аллаһы Тәгалә, ошбу гамәл өчен әҗерен Ахирәттә бирәм дип, безләрне сыный. Мөэмин кеше моны белә һәм шуңа омтылып гамәлен кыла. Ә дөнья малына кызыгу – Ахирәтне оныттыра.

Гафиллектә булуның тагын бер сәбәбе булып, гөнаһ кылу тора. Гөнаһ кылганда йөрәк карала, караңгылана, сукырая, Аллаһыдан ерагая, Ахирәт турындагы уй-фикерләре сүнә, шул ук вакытта андый йөрәк дөньяга якыная.

Начар, әдәпсез иптәшләрең булу да гафиллеккә илтә. Авыру кешедән авыруы йокмасын дип сакланган кебек, начар, әдәпсез иптәшләрдән дә сакланырга кирәк. Сакланмасак, безгә дә әдәпсезлекнең йогуы көн кебек ачык.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, дөреслектә, гафиллек ишекләре безгә сизелерлек итеп ачылмый. Ашханәгә кергәч ризык исе борынга килеп бәрелә, аны сизәбез, әмма бераз вакыт үткәч без аңа ияләнәбез һәм игътибар итми башлыйбыз. Шулай ук ярамаган эшләрне, начар иптәшләрне дә йөрәгебез шунда ук сизә, әгәр сакланмасак, гафиллек безләрне дә камап алыр, сизмичә дә калырбыз.

Гафиллектән ничек котылырга, сакланырга соң?

Беренчесе, дога кылу, Аллаһыдан сорау. Әлбәттә, бу ысулның дәвамлы, даими булуы мөһим. Без һәрвакыт Аллаһыдан сорарга тиешбез, чөнки дога – гыйбадәтнең җелегедер. Раббыбыз: «Сорагыз – җавап бирермен», – дип әйтә.

Икенчесе, үлемне искә төшерү, җеназага йөрү, мәет озатканда яисә каберстанга баргач: «Шушы мәет урынында мин дә булачакмын бит, мине

дә җирләрләр, бәлки миңа дигән кәфенлек, минем өчен кабер казырга дигән көрәк әзердер?» – дип фикерләү. Үлемне искә алу онытылудан, гафил булудан айнытып җибәрәдер. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ләззәтләрне кисүчене (үлемне) еш искә алыгыз», – дип әйткән. Белгәнебезчә, кайбер сәхабәләр хәтта кабер казып, шунда ятып та карый торган булган, үлемне искә алып елаган.

Имам Әд-Дәххак рахимәһуллаһи болай дип әйткән: «Үлемне еш искә алучы кешегә өч нигъмәт биреләчәк: кичектерелмәгән тәүбә, тыйнак йөрәк һәм тырыш гыйбадәт. Ә үлемне онытучыларга өч җәза булыр: тәүбәне кичектерү, сузу, ризыгына канәгать булмау, гыйбадәттә ялкаулык күрсәтү.

Өченчесе, зикер итү, тәүбә итү, дәресләргә, вәгазьләргә йөрү, Аллаһы Раббыбыз хакында фикерләү. Бу гамәлләр дә гафиллектән арынуның бер чарасы булып торадыр.

Хөрмәтле мөселманнар, өметләнеп кенә яшәмик, эшләребезне иртәгәгә калдырмыйк, изге гамәлләр кылуны кичектермик. Планнар кору – бер нәрсә, әмма изге гамәлгә, гыйбадәткә килгәндә, иртәгә эшли башлармын, иртәгә үтәрмен, дип кичектерү – үз-үзеңне алдаудыр. Гафиллек ишекләрне этә, ачмакчы, кермәкче була, әгәр без ишекне саклап, аны терәп тормасак, аңа бик куймасак, безне гафиллекнең камап алуы билгеле.

Раббыбыз вәгазебездән файдаланырга насыйп итсен, безләргә аек фикер, фикерләү сәләте биреп, хәләлне харамнан, хак юлны ялгыш юлдан аерып яшәүне насыйп әйләсен, гафил булудан сакласын.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Динар Зыятдинов,*

*ТР МДНнең «Зәкят» хәйрия фонды хезмәткәре*

*7 нче апрель вәгазе,*

*Рамазан аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Гайбәт сөйләүнең афәтләре

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салаватшәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Гайбәт сөйләү, тарату динебез Ислам буенча тәнкыйтьләнә торган гамәлләрнең берсе булып тора. Гайбәт тарату кешеләр арасын бозарга, аларны дошманлаштырырга сәләтле. Хәтта гайбәт сөйләүче хакында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гайбәт сөйләүче җәннәткә кермәс», – дип тә әйткән[1].

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләреннән: «Арагыздан иң яманы хакында әйтимме?» – дип сораган. Сәхабәләр: «Әйе, йә Расүлуллаһ», – дип җавап биргәннәр. Расүлуллаһ: «Гайбәт таратучылар, дуслар арасын өзүчеләр, пакь кешеләрдән гаеп эзләүчеләр»[2], – дип әйткән.

Шундый кыйсса риваять ителә: берьюлы Исраил улларына бик нык корылык килгән. Муса галәйһиссәлам берничә тапкырлар яңгыр сорап дога кылса да, яңгыр яумаган. Шул вакытта Раббыбыз аңа: «Сезнең арада гайбәт сөйләүче булганда Мин синең догаңа да, синең белән булучыларның догасына да җавап бирмәм», – дип вәхи иңдергән. Муса галәйһиссәлам: «Йә, Аллаһым, миңа аларның кем икәнен әйт, мине аларга юнәлт

[1] Имамнар Әл-Бохари, Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Әхмәднең хәдисләр җыентыгыннан.

һәм мин аларны безнең арадан чыгарырмын», – дигән. Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә аңа: «Ий, Муса, Үзем гайбәттән тыя торып Үзем гайбәт сөйлимме?» – дигән. Моннан соң бу халык гөнаһлары өчен тәүбә кылган һәм Раббыбыз яңгыр яудырган.

Имам Әбү Хәмид Әл-Газали элеккеге китаплардан шундый кыйсса китерә: бервакыт хикмәт иясеннән: «Күк йөзеннән авыррак, җир йөзеннән киңрәк, таштан катырак, уттан эссерәк, зәмһәрирдән[1] салкынрак, диңгез нигъмәтләреннән мулрак һәм ятимнән бәхетсезрәк нәрсә ул?» – дип сораганнар. Шунда хикмәт иясе болай дип җавап биргән: «Пакь, гаепсез кешегә яла ягу – күк йөзеннән авыр, хакыйкать – җир йөзеннән киң, иман китермәүченең йөрәге – таштан каты, көнчелек – уттан эссе, берәүнең мөмкинлеге булып та ярдәмгә мохтаҗ туганнарына ярдәм итмәү – зәмһәрирдән салкынрак, канәгать булучының йөрәге – диңгез нигъмәтләреннән мул, күрсәтеп гайбәт сөйләүче – ятимнән бәхетсез», – дигән.

Безгә берәрсе гайбәт сөйли башласа, нәрсә эшләргә тиеш булабыз соң?

Беренчедән, гайбәтченең сүзләрен күтәреп алмаска, аңа ышанмаска кирәк.

Икенчедән, аның гайбәт сөйләвен тыярга, бу гамәлне кылуның ярамаганлыгын аңлатырга кирәк. Коръәни Кәримдә:

وَلْتَكُن مِّنكُمْ أُمَّةٌ يَدْعُونَ إِلَى الْخَيْرِ وَيَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ ۚ وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ ﴿١٠٤﴾

**«Арагызда [дини һәм дөньяви] хәергә [файдалы эшләргә] чакыра, яхшы гамәлләрне [кылуны] әмер итә, начар гамәлләрдән тыя торган җәмәгать булсын. Менә шулар – уңышка ирешүчеләр»,** – диелгән.

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:104

[1] Зәмһәрир – җәһәннәм газапларының бер төре булган бик нык салкынлык (ред.).

Өченчедән, бу хәлләргә карата куралмау хисләре кичерү, чөнки Аллаһы Тәгалә гайбәт сөйләүчене куралмый.

Дүртенчедән, хәбәр килеп ирешү белән кардәшегез хакында начар уйламау. Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اجْتَنِبُوا كَثِيرًا مِّنَ الظَّنِّ إِنَّ بَعْضَ الظَّنِّ إِثْمٌ ۖ

**«Ий иман китерүчеләр! Фаразларның бик күбеннән сак булыгыз, чөнки, һичшиксез, кайбер фаразлар – гөнаһ»,** – дип әйтә.

«Әл-Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:12

Монда сүз мөэминнәргә карата булган фараз кылулар һәм кемгә дә булса карата нигезе булмый торып начар фикер йөртү турында бара. «Кайбер фаразлар – гөнаһ» дигән сүзне ничек аңларга соң? Телдән әйтмәгән уй-фикерләр гөнаһ булып саналмый бит. Галимнәр бу очракта «гөнаһ» дигәнне ялган дип аңларга куша. Хәдисләрнең берсендә болай дип әйтелгән: «Яман уйлар (шик-шөбһәләр) – иң ялган сүзләр»[1].

Икенче бер галимнәр сүз яман уйларны яки шик-шөбһәләрне уйда гына калдырмыйча, телдән әйтү хакында бара дип әйтә. Ә аларны әйтми торып, алар өчен гөнаһ юк, чөнки без башыбызга килгән очраклы уй-фикерләр өчен җавап бирмибез.

Бишенчедән, безгә килеп сөйләгәннәргә колак салмау һәм дөреслеген белү өчен кеше артыннан күзәтмәү. Ислам динендә шымчылык итү, кеше күзәтү тыела. Коръәндә:

وَلَا تَجَسَّسُوا

**«Янә [бер-берегездән] гаеп эзләмәгез»,** – диелгән.

«Әл-Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:12

[1] Имамнар Әл-Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Алтынчыдан, гайбәт сөйләүченең гамәлләрен кабатламагыз. Гайбәтченең гайбәт сөйләвен тыюыгыз белән куанып, мин гайбәт сөйләргә теләүче кешене кире кактым, дип әйтмәгез. Икенче сүз белән әйткәндә, болай эшләгән очракта үзебез үк тыйган нәрсәне эшләгән булабыз. Гомәр бине Габделгазиздән тапшырыла: «Бервакыт аның янына бер кеше килә һәм башка берәүнең гамәлләре турында сөйли. Гомәр бине Габделгазиз аңа: «Әгәр син алдаган булсаң, Аллаһы Тәгаләнең:

إِن جَاءَكُمْ فَاسِقٌ بِنَبَإٍ فَتَبَيَّنُوا

**«Әгәр [гөнаһтан сакланмаган, шуңа ялган сөйләмәячәгенә ышаныч булмаган] фасикъ бер кеше сезгә [мөһим] хәбәр китерсә, [аның асылын] тикшереп белегез»,** – дигән кешеләре исәбеннән булырсың.

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:6

Әгәр син хаклы булсаң, Коръәндә:

هَمَّازٍ مَّشَّاءٍ بِنَمِيمٍ ﴿١١﴾

**«[Һәркемне] Хурлаучыга, [бозык уйлар белән] сүз йөртүчегә [дә буйсынма]»,** – дип искә алынган кешеләрдән булырсың.

«Әл-Каләм», 68:11

«Әгәр теләсәң, мин сине гафу итәрмен», – дигән. Шуннан соң бу кеше: «Ий, мөэминнәрнең әмире, мине гафу ит, мин башка бу гамәлгә кайтмам», – дигән.

Элек яшәгән кешеләрнең берсе кардәшенең хәлен белергә килгән һәм башка бер кешенең үзенә ошамаган сыйфаты хакында сөйләгән. Кунак итүче кеше аңа болай дип әйткән: «Йә, кардәшем, син миңа гайбәт белән килдең һәм мин өч гөнаһка төштем», – дигән. Беренчесе, минем кардәшемә ачуым чыкты. Икенчесе, минем калебем Аллаһыдан читкә

юнәлде. Өченчесе, мин синнән шикләнә башладым.

Чыннан да, әгәр берәү безгә килеп, башка кешенең безнең хакта начар сөйләгәне хакында сөйли башласа, без нигә бу кеше алай эшләде икән, мин аны нәрсә белән үпкәләттем икән, кайчан хәтерен калдырдым икән, дип уйлый башлыйбыз. Шул вакытта бу хәбәрләрне китерүче кеше дә шикле һәм ышаныч тудырмый торганга әйләнә.

Бервакыт Сөләйман бине Габделмәлик имам Зөһри рахимәһуллаһи янында утырганда алар янына бер кеше килгән, һәм Сөләйман бине Габделмәлик аңа: «Дөреслектә, миңа син минем хакта гайбәт сөйләгән дип килеп иреште», – дигән. Теге кеше: «Мин алай эшләмәдем, синең хакта берни дә сөйләмәдем», – дигән. Сөләйман бине Габделмәлик: «Дөреслектә, бу хакта миңа хәбәр итүче дөрес һәм ышанычлы кеше», – дип әйткән. Моңа имам Зөһри рахимәһуллаһи: «Гайбәт сөйләүче дөрес һәм ышанычлы кеше була алмый», – дигән. Моннан соң Сөләйман бине Габделмәлик: «Син дөрес әйттең», – дигән һәм әлеге кешене җибәргән.

Хәсән Әл-Басри рахимәһуллаһи: «Сиңа башкалар хакында гайбәт сөйләүче башкаларга да синең хакта гайбәт сөйли», – дигән.

Чыннан да, гайбәтнең зыяны бик зур, һәм шуңа да бу гамәлдән сакланырга кирәк. Гайбәт сөйләүче кешеләр Аллаһы бәйләргә кушканны өзә һәм җир йөзендә бозыклык тарата. Раббыбыз Коръәни Кәримдә:

إِنَّمَا السَّبِيلُ عَلَى الَّذِينَ يَظْلِمُونَ النَّاسَ وَيَبْغُونَ فِي الْأَرْضِ بِغَيْرِ الْحَقِّ ۚ أُولَٰئِكَ لَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ ﴿٤٢﴾

**«Шелтәле юл тик кешеләргә золым кылган һәм җирдә хаклары булмыйча, бозыклык эшләгәннәргә генә. Алар өчен тилмерткеч бер газап [әзерләнгән]»,** – дигән.

«Әш-Шура / Киңәш», 42:42

Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребезнең мондый сүзләрен тапшырган: «Кемнең явызлыгыннан башкалар куркып тора, шул кешеләрнең иң яманы»[1].

Раббым Аллаһы Тәгалә безне гайбәт кебек яман гадәтләрдән ерак итсен, кешеләр хакында бер сәбәпсез начар уйлар уйлап, бер-берләребезнең арасын бозудан имин кылсын иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Мөхәммәд хәзрәт Хөсәенов,*
*Югары Ослан муниципаль районы*
*Яр буе Морквашы имамы*

[1] Имамнар Әл-Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

# «Нәрсә?
# Кайда?
# Кайчан?»

# Октябрь-Ноябрь

## Диния нәзарәтендә өлешчә мобилизация шартларында дини эшчәнлекне алып бару мәсьәләләре буенча Пленум узды

Рабигыль-әүвәл аеның 12 нче көнендә (8 нче октябрьдә), Татарстан мөфтияте бинасында Диния нәзарәте Пленумы утырышы узды. Утырышта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары, ТР баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, шулай ук бөтен республикадан имам-мөхтәсибләр һәм мөфтият эшчәнлегенең барлык юнәлешләре һәм оешмалары җитәкчеләре катнашты. Көн тәртибенә өлешчә мобилизация шартларында туган сораулар, шулай ук әлеге вәзгыятьтә мөхтәсибәтләр эшен алып бару үзенчәлекләре, мобилизацияләнгән мөселман солдатларына ярдәм күрсәтү мәсьәләләре чыгарылды.

Моннан тыш, пленум барышында ТР мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмәгә аерым мәсьәләләр буенча өстәмәләр кертү, шулай ук Татарстанда – Түбән Камада тагын бер казыят төбәген булдыру турында да карарлар чыгарылды. Бертавыштан Түбән Кама төбәге казые итеп Салих хәзрәт Ибраһимов сайланды. Шул рәвешле, Нәзарәтнең Казыйлар шурасы составында хәзер 10 төбәк казыяте эшләячәк.

## Нәзарәт Татарстан солдатларына ярдәм күрсәтү өчен җыелган акчага хәрби кием һәм хәләл тушенка сатып алды

2022 елның 21 нче сентябрендә РФ Президенты Владимир Путин тарафыннан Рәсәйдә өлешчә мобилизация игълан ителгәч, ТР мөселманнары Диния нәзарәте Татарстаннан махсус хәрби операциядә катнашучы мөселман солдатларына һәм аларның якыннарына ярдәм итү

эшен башлап җибәрде. 27 сентябрьдә Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды акча җыюны игълан итте. Башлангыч кысаларында республиканың төрле почмакларыннан, аеруча мөхтәсибәтләр тырышлыгы белән, барлыгы 7 556 683,53 сум акча җыелды. Моннан тыш, «Зәкят» фонды тагын 500 000 сум күләмендә акча өстәде. Җыелган акчалар хисабына республика сугышчыларына хәрби кырларда кирәк булачак әйберләр сатып алынды. Шул исәптә: 14 000 данә хәләл тушенка, 40 комплект хәрби обмундирование (шлемнар, бронежилетлар, бронеплитәләр, кан агуны туктата торган жгут-турникетлар), 14 комплект хәрби кием (кышкы аяк киемнәре, эчке термокием, балаклава, перчатка, оекбашлар, хәрби келәмнәр), медикаментлар һәм шәхси гигиена әйберләреннән торган 14 җыелма.

## Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин мобилизацияләнгән татарстанлылар белән очрашты

Рабигыль-әүвәл аеның 4 нче көнендә (30 нчы сентябрьдә), Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге базасында оештырылган мобилизацияләнгән солдатларны җыю пунктында хәрби хезмәткә чакырылган дин кардәшләр белән аралашты, аларның дини сорауларына җавап бирде; мөселманнар өчен оештырылган намаз уку бүлмәсен карады. Биредә тәһарәт алу, намаз уку, дога кылу өчен шартлар тудырылган.

Татарстаннан мобилизацияләнгән солдатлар белән шулай ук Нәзарәтнең Голәмәләр шурасы гыйльми секретаре Рөстәм хәзрәт Нургалиев очрашты. Моннан тыш, солдатларны җыю пунктларында намаз укыту һәм сугышчылар белән даими рәвештә эшләү өчен Нәзарәт тарафыннан махсус имамнар беркетелде.

## Казанда мобилизацияләнгән солдатларны җыю пунктлары хәләл ризык белән тәэмин ителә

Казанда мобилизацияләнгән солдатларны җыю пунктларында – «Казан Экспо» Халыкара күргәзмәләр үзәгендә, танк училищесында һәм танк полигонында намаз уку бүлмәләренә йөрүче мөселманнарга хәләл ризык ашату оештырылды. Солдатларны кайнар хәләл ризык белән тәэмин итү кафелары һәм битараф булмаган мөселманнарның акчалата ярдәме белән гамәлгә ашырыла.

## Диния Нәзарәте мобилизацияләнгән мөселманнар белән аларның якыннары белән аралашу өчен WhatsAppта махсус төркемнәр булдырды

Диния нәзарәте Татарстаннан мобилизацияләнгән мөселман солдатлары һәм аларның якыннары белән элемтәдә тору, мөһим мәгълүмат җиткерү, туган шәргый сорауларга җавап бирү һәм рухи ярдәм күрсәтү өчен, WhatsApp мессенджерында махсус төркемнәр булдырды. Мессенджердагы 2 аерым аралашу чатында мөфтиятнең мөселман сугышчылары белән эшләргә билгеләнгән имамнар һәм шәригать бүлеге белгечләре бар. Чатлар ярдәмендә мөфтият вәкилләре «Казан Экспо» Халыкара күргәзмәләр үзәгендә, танк училищесында һәм танк полигонында урнашкан чакырылган солдатларны җыю урыннарында хәләл туклануны һәм җәмәгать намазларын оештыра, сугышчыларның ихтыяҗларын күрә, дини консультацияләр бирә, ә аларның якыннарына нәсыйхәт, киңәшләрен җиткерә, психологик ярдәм күрсәтә.

## Диния нәзарәте Татарстаннан мобилизацияләнгән солдатлар һәм аларның якыннары өчен махсус дога җыентыклары чыгарды

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрияты күпсанлы сораулар буенча, Татарстаннан һәм Рәсәйнең башка төбәкләреннән мобилизацияләнгән дин кардәшләребез, шулай ук аларның туганнары һәм якыннары: хатыннары, ата-аналары, балалары өчен түш кесәсенә салып йөри торган 25 000 данәдә махсус дога җыентыклары әзерләп чыгарды һәм бушлай таратты. «Молитвы – дуа» дип исемләнгән догалык – уч төбенә сыйдырышлы, димәк, солдатлар аларны һәрвакыт үз янында тота һәм махсус хәрби операция үткәрү урыннарында авыр минутларда файдалана ала. Әлеге басмада Аллаһыдан ярдәм һәм яклау сорау өчен, шулай ук борчылу һәм куркудан, дошманнардан котылу өчен һ.б. догалар тупланган.

## Казанда татар мәкаме буенча курслар узды

Рабигыль-әүвәл аеның 13-17 нче көнендә Казанның Галиев мәчетендә Коръәнне татар мәкаме белән уку буенча бер атналык курслар узды. Дәресләрне оештыру һәм башлап җибәрү башында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин торды. Татар мәкамен фәнни һәм гамәли яктан өйрәнү һәм үстерү ихтыяҗыннан чыгып, мөфти бу өлкәдә эш алып бару өчен, филология фәннәре кандидаты Резеда Сафиуллина һәм Татарстанның атказанган артисты, дини җырлар башкаручы Марсель Вәгыйзевне җәлеп итте.

Киләчәктә татар мәкамен нотага салып өйрәнүне һәм саклауны күздә тоткан курсларны Төркиядән махсус чакырылган мөгаллим, Дин эшләре министрлыгының Коръән уку һәм азан әйтүдә хаталарны төзәтү мәсьәләләре буенча киңәшчесе Али Усман Алаҗа алып барды. Дәресләр,

теоретик белемнәр үзләштерү белән беррәттән, остаз белән күнегүләр башкаруны да күздә тотты. Али Усман Алаҗа, татар азаннарын, халык көйләрен тыңлап, мәкамнәрне аеру буенча практик күнегүләр үткәрде. Дәрес барышында татар мәкаменә хас төп үзенчәлекләрне аерып күрсәтте һәм дәрестә катнашучылар аның белән бергәлектә азан әйтү, Коръән аятьләре уку буенча күнекмәләр алды. Дәресләрдә шулай ук сулыш алу, тавышның чыгарылышы (тавышны матур итеп чыгара белү), вокал буенча кайбер күнегүләр үткәрелде.

## Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин «Татар дин галимнәренең Коръән фәннәрен һәм Коръән расмын (язу кагыйдәләрен) өйрәнүгә керткән өлеше» темасына докторлык диссертациясе яклады

Рабигыль-әүвәл аеның 15 нче көнендә Болгар ислам академиясендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Татар дин галимнәренең Коръән фәннәрен һәм Коръән расмын (язу кагыйдәләрен) өйрәнүгә керткән өлеше» темасына язылган докторлык диссертациясен яклады. Камил хәзрәтнең фәнни җитәкчесе булып шәригать фәннәре докторы, БИА һәм Әбү Даби университеты мөгаллиме, фикһ (ислам хокукы) һәм фикһ ысулы (ислам хокукы нигезләре), шулай ук гакыйдә (инану) фәне белгече, Әбү Даби провинциясе мөфтияте белгече Сәиф Али Әл-Асри торды. Фәнни тикшеренү хәзерге заманның танылган мөселман галимнәреннән саналган рецензентлар тарафыннан өйрәнелде. Камил хәзрәтнең фәнни эшен өйрәнгәннән соң, аның чыгышын һәм сорауларга җавапларын тыңлаганнан соң, диссертация советы тарафыннан аңа «Коръән белеме» белгечлеге буенча ислам фәннәре докторы дәрәҗәсен бирү хакында карар чыгарылды.

Фәнни тикшеренүне Рәсәйнең хәзерге ислам гыйлеме фикере үсешендә иң әһәмиятле хезмәтләрнең берсе дип атарга мөмкин. Ул татар дин белгечләренең XIX–XX гасыр башында Коръән фәннәрен үстерүгә һәм өйрәнүгә керткән өлеше хакында мәгълүматларны җыеп, аларны гарәп телендә әзерләп, беренче тапкыр системалы рәвештә ислам дөньясына чыгарды.

## Мөселман эшмәкәрләре ЦУМда намаз бүлмәсен ачты

21 нче октябрьдә «Казанский ЦУМ» сәүдә үзәгендә тантаналы рәвештә намаз бүлмәсе ачылды. Ул – Татарстан башкаласының сәүдә үзәкләрендә РФ Мөселман эшмәкәрләре Ассоциациясе тарафыннан оештырылган унынчы бүлмә. Тантаналы чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Президенты каршында эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Фәрит Габделганиев, ТР Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина, «Торговый дом Казанский ЦУМ» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Илдар Гафаров катнашты.

Намаз бүлмәсе сәүдә үзәгенең цоколь катында урнашкан. Аның мәйданнарында киләчәктә мөселман сәүдә рәтләре ачу планлаштырыла. Бүлмәне үзәк ишекләрдән кергәч, эскалатордан төшеп табарга була. Ул РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясенең стандарт дизайны буенча һәм мөселманнарның тәкъдимнәрен истә тотып эшләнгән. Бүлмә ике өлешкә: ирләр һәм хатын-кызларныкына бүленгән, һәр өлешнең үз тәһарәтханәсе бар. Гомуми мәйданы – 36,5 кв.м.

## «Әхмәт бине Фадланның Итил елгасына сәяхәте» китабы буенча бәйге үтте

Сентябрь-октябрь айларында Нәзарәттә «Әхмәт бине Фадланның Итил елгасына сәяхәте» китабы буенча республикакүләм бәйге үтте. Бәйге сайлап алу турыннан һәм финалдан торды. Анда барлыгы 100 кеше катнашты, алар тест рәвешендәге 49 сорауга җавап бирде. Татарстан мөфтиенең мәгариф буенча урынбасары Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге жюри аларга бәя бирде. Бәйге нәтиҗәләре буенча I урынга Буа районы Иске Суыксу авылыннан Резеда Якупова чыкты. Аңа тауда йөри торган велосипед бүләк ителде. II урынны Казаннан 14 яшьлек Мөхәммәд Зарипов яулады, аңа электросамокат тапшырылды. III урынга Казан шәһәреннән 28 яшьлек Ләйсән Җиһангәрәева лаек булды һәм робот тузан суырткыч белән бүләкләнде.

## Баулы районында яңа мәчет ачылды

Рабигыль-әүвәл аеның 29 нчы көнендә (25 нче октябрьдә), Баулы районы Васькино-Туйралы авылында яңа мәчет ачылды. Әлеге күркәм вакыйга уңаеннан, дин кардәшләребезнең сөенечен бүлешергә кунаклар, район дин әһелләре, Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге имам-мөхтәсибләре килде. Аларны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән аның беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов тәбрикләде.

Әлеге мәчет төзелеше 2018 елның июль аеннан Хәсәншин Рафаил Шәрипҗан улының тырышлыгы һәм матди-финанс ярдәме белән алып барылды. Төзелешкә авылда яшәүчеләрнең, фермерларның, җирле җитәкчеләрнең дә өлеше керде. Мәхәллә тәкъдиме белән, яңа мәчеткә Рафаил хәзрәтнең әтисе – шулай ук игелекле эшләре белән мәгълүм Шәрипҗан абый хөрмәтенә «Шәрип» исеме бирелде. Мәчет төзелешенә сәбәпче булган Рафаил хәзрәт Хәсәншин имам-хатыйб вазифасына керешә.

Яңа мәчет – 14х8 метр зурлыгында, бер катлы, төп намаз залында, чаршау белән аерып, хатын-кызлар өчен дә намаз уку урыны билгеләнгән, барлык уңайлыклар тудырылган уку сыйныфы, янәшәдә котельная, тәһарәтханә бар. Васькино-Туйралы авылында яңа мәчет ачылу белән Баулы мөхтәсибәтендәге мәчетләр саны 15кә тулды.

## Казанда мөселман уку йортлары мөгаллимнәренең ике көнлек форумы узды

26-27 нче октябрьдә Казанда мөселман белем бирү оешмалары мөгаллимнәренең Бөтенрәсәй форумы эшләде. Форум Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100-еллык һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә 140 ел тулу кысаларында Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә теләктәшлек фонды ярдәмендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм Рәсәй ислам институты тарафыннан оештырылды һәм мөселман мәгарифе һәм тәрбиясе өлкәсендә мөһим проблемаларны тикшерү һәм хәл итү, тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгы булып торды. Форумның беренче көне мәчет каршындагы курсларда белем бирүче 350дән артык мөгаллимне җыйса, икенче көнне мөселман мәгарифе һәм тәрбиясе системасындагы проблемалар буенча фикер алышуга Татарстанның гына түгел, Саратов, Оренбург, Уфа һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең һөнәри уку йортлары директорлары, мөгаллимнәре дә кушылды.

Икенче көнне форум эше «Мөхәммәдия»нең яңа бинасында мәдрәсәнең оешуына 140 ел тулу уңаеннан фәнни конференция белән дәвам итте. Әлеге фәнни җыен – мәдрәсә тарихында беренче. Кунаклар һәм галимнәр бертавыштан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең татар халкы тарихында иң абруйлы, билгеле уку йорты булуын, революциягә кадәр татар университеты дәрәҗәсендә эшләвен ассызыклап үтте. Конференциядә чыгыш ясаучылар уку йортының үзенең бай традиция-

се булуын, аның дәрәҗәсе Татарстанда гына түгел, ә бар Рәсәйгә хезмәт итүен ассызыклады.

## Татарстанда рекордлы күләмдә гошер садакасы җыелды – мохтаҗларга 1377,34 т азык-төлек таратылды

Сентябрь-октябрь айларында Татарстан Республикасы Диния нәзарәте башлангычы белән тормышка ашырылган гошер садакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясе барды. Кампания нәтиҗәләре буенча барлыгы 1377,34 тонна гошер садакасы җыелды. Мөхтәсибәтләр арасында беренче өчлекне Балык Бистәсе (256 т), Питрәч (250 т) һәм Сарман (143,5 т) районнары алып тора. Шулай ук Арча районы (68 т), Балтач районы (62,9 т), Кукмара районы (55 т), Әтнә районы (45 т), Саба районы (43,12 т), Теләче районы (42 т), Буа һәм Чирмешән районнары (40 шар тонна) зур активлык күрсәтте.

Татарстан мөселманнары, мохтаҗларга ярдәм итү йөзеннән, республика мәчетләренә яшелчә (бәрәңге, чөгендер, кәбестә, кишер, кабак, ташкабак, суган һ.б.), җиләк-җимеш кайнатмалары, тозлаган кыяр-помидорлар, бал алып килде. Искәрмәләр дә булды: мәсәлән, Сарман районында мөселман эшкуарлары гошерне бодай һәм арпадан чыгарды. Кампания кысаларында җыелган азык-төлек хәйрия оешмаларына (ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды һәм «Ярдәм» гомуммилләт хәйрия фонды тернәкләндерү үзәге), социаль учреждениеләргә (районнардагы картлар йортлары, балалар йортлары), мөселман уку йортларына (мәдрәсәләр, мәктәпләр һәм балалар бакчалары, Коръән хафизлар әзерләү үзәге һ.б.), шулай ук турыдан-туры мохтаҗ гаиләләргә җибәрелде. ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Казанның 600 дән артык аз керемле гаиләсен азык-төлек белән тәэмин итте.

## Казанда фәтвалар чыгару методологиясе буенча семинар узды

Ноябрь башында Казанда «Фәтвалар чыгару методологиясе: хәзерге заман проблемалары» дип исемләнгән ике көнлек семинар узды. Әлеге чараны Рәсәй ислам институты Татарстан мөфтияте Төркия дин эшләре идарәсе һәм Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм фонды белән бергәлектә үткәрде. Семинарда Төркия дин эшләре Югары Советы, шулай ук Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Әзербайҗан, Монголия, Беларусия һәм Рәсәй төбәкләренең Диния нәзарәте җитәкчеләре катнашты. Төрле илләрнең галимнәр шуралары вәкилләре үз илләрендә ничек итеп фәтвалар чыгарылуы, шулай ук әлеге эш барышында нинди проблемалар белән очрашырга туры килүе турында сөйләде. Төркиянең дин эшләре буенча Югары совет рәисе Габдрахман Хачкали, Кыргызстан мөселман галимнәре советы әгъзасы Самаган Мурзаибраимов, Төркиянең дин эшләре буенча Югары совет рәисе урынбасары Фатыйх Мехмет Айдын, КИУ проректоры, Татарстан мөфтиятенең Голәмәләр шурасы гыйльми сәркатибе Рөстәм Нургалиев, Төркиянең дин эшләре буенча Югары совет әгъзасы Мехмет Хаҗи Гюнай, КИУның дини фәннәр кафедрасы мөдире Габдулла Әдһәмов чыгыш ясады.

## Ютазы районында «Фәнис» мәдрәсәсенең 15 еллыгы уңаеннан бәйрәм чаралары узды

Рабигыль-ахыр аеның 17-19 нчы көннәрендә Ютазы районында «Фәнис» мәдрәсәсе оешуга 15 ел тулу уңаеннан оештырылган бәйрәм чаралары узды. Бу уңайдан рабигыль ахыр аеның 18 нче көнендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Ютазы мөхтәсибәтенә эшлекле сәфәр кылды һәм тантаналарда катнашты, «Фәнис» мәдрәсәсенең көндезге бүлегендә укучы студентлар белән очрашты. Шулай ук ул Ютазы районы башлыгы Аяз Шәфигуллин белән очрашып, райондагы дини вәзгыять турында сөйләште.

Юбилей кысаларында «Фәнис» мәдрәсәсендә Татарстан мөфтиенең мәгариф буенча урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин җитәкчелегендә республикадагы мөселман уку йортлары директорларының күчмә киңәшмәсе узды. Киңәшмә вакытында студентларны кабул итү нәтиҗәләре чыгарылды, мәдрәсәләрнең торышы һәм алга таба эшчәнлеге белән бәйле мәсьәләләр күтәрелде. Моннан тыш, республиканың көньяк-көнчыгыш казыятенә караган мәчетләр каршындагы курсларда белем бирүче барлык мөгаллимнәрнең очрашуы булды. Шулай ук әлеге мәдрәсәдә белем алып, аны төрле елларда тәмамлап чыккан дин әһелләренең очрашуы узды.

## Түбән Камада «1100-еллык»ка стела ачылды һәм яңа мәчет белән рухи үзәк төзелеше башланды

Рабигыль-ахыр аеның 19 нчы көнендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Түбән Кама шәһәренә эшлекле сәфәр кылды. Әлеге район мөселманнары тормышы белән танышуны ул Түбән Кама муниципаль районы башлыгы, Түбән Кама шәһәре мэры Рамил Муллин белән күрешеп очрашудан башлады. Имам-мөхтәсиб Салих хәзрәт Ибраһимов белән бергәлектә узган әңгәмәдә җитәкчеләр Түбән Кама районындагы дини һәм милли вәзгыять хакында фикер алышты.

Алга таба җитәкчеләр Түбән Кама шәһәрендә яңа мәчет һәм рухи-мәгърифәт үзәге салыначак урынга юнәлде. Ул шәһәргә керү юлында, Вахитов проспекты, 3Б адресы буенча урнашкан. Мөселман гыйбадәтханәсенә киләчәктә, исемен җисеменә туры китереп, «Сәлам» исеме бирү көтелә. Хәзерге вакытта җирне төзелеш алып бару өчен әзерләү, документларны рәсмиләштерү, мәхәллә халкының фикерләрен тыңлау эшләре алып барыла. Әлеге мәчет салыначак урында тарихи вакыйга – Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына истәлек билгесе – стела да ачылды. Хәзерге вакытта Түбән Кама мөхтәсибәтендә 25 мәчет,

шуның икесе – шәһәрдә. Мөхтәсибәттә, «Сәлам» мәчетен дә кертеп, ике яңа мәчет төзелә.

Төшке аштан соң Түбән Кама шәһәренең «Адымнар» күп телле мәктәбендә мөфти рухи тәрбия мәсьәләләре буенча сөйләшүдә катнашты. Биредә панель дискуссия рәвешендә җәмгыятьтә һәм үсеп килүче буында әхлакый сыйфатлар тәрбияләү хакында фикер алышу булды.

## Нурлат һәм Лаеш мөхтәсибәтләрендә имам-мөхтәсибләр сайланды

Рабигыль-ахыр аеның 8 нче көнендә Нурлат мөхтәсибәтендә Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин исемендәге мөселман мәгариф үзәгендә район имамнары җыелышы узды. Анда мөхтәсибәтнең 42 мәчете имамы катнашты. Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары, республиканың көньяк төбәге казые Равил хәзрәт Зөфәров, утырышны ачып җибәреп, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән сәламләде һәм шушы вакытка кадәр Нурлат районында имам-мөхтәсиб булып эшләгән Наил хәзрәт Әбелхановның яңа вазифага күчү теләге хакында белдерде. Равил хәзрәт яңа мөхтәсиб кандидатурасына имамнарга моңарчы Нурлат шәһәренең «Әфзалетдин» мәчете имам-хатыйбы булып хезмәт иткән Ирек хәзрәт Сәйфуллинны тәкъдим итте. Район имамнары аның өчен бердәм тавыш бирде.

Җыелыш барышында район хакимияте, җирле дин әһелләре тарафыннан 5 ел дәвамында имам-мөхтәсиб булып эшләгән Наил хәзрәт Әбелханов турында җылы сүзләр әйтелде. Ул кыска вакыт эчендә мөхтәсибәттә эшчәнлекне җайга салып, дин әһелләре һәм нурлатлылар белән уртак тел табып, район халкы файдасына күп хезмәт кылырга өлгерде.

Наил хәзрәт Әбелханов рабигыль-ахыр аеның 14 нче көнендә Лаеш мөхтәсибәтенең район имамнары җыелышында бертавыштан Лаеш

имам-мөхтәсибе булып сайланды. Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары, республиканың көньяк төбәге казые Равил хәзрәт Зөфәров Наил хәзрәткә Лаеш мөхтәсибе булып эшләргә мөмкинлек бирә торган Шәһадәтнамә тапшырды.

## Казанның мохтаҗ гаиләләре азык-төлек белән тәэмин ителде

Рабигыль-ахыр аеның 22 нче көнендә Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды 30 мохтаҗ гаиләгә азык-төлек җыелмалары таратты. Хәйрия фондыннан әлеге ярдәмне бер ялгызы балалар үстерүче аналар, күп балалы гаиләләр, ялгыз пенсионерлар, авыру мохтаҗлар, инвалид бала тәрбияләүчеләр алды. Азык-төлек җыелмасында он, ярмалар, көнбагыш мае, шикәр, тушенка, макарон һәм чәй бар. Фонд тарафыннан азык-төлек җыелмалары дин кардәшләребез күрсәткән садакалар, битараф булмаган кешеләрнең матди ярдәме белән әзерләнде. Быел 11 ай эчендә мохтаҗларга барлыгы шундый 1202 җыелма таратылды.

## Яшел Үзәндә яңа мәчет ачылды

Рабигыль-ахыр аеның 24 нче көнендә Яшел Үзән районы Зур Өтәк авылында яңа мәчет ачылды. Район халкының сөенечен бүлешеп, тантанада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Мәчет, 2020 нче елның язында төзелә башлап, 1882 нче елдан алып 1917 нче елгы революциягә кадәр Аллаһы йорты булган урында күтәрелгән. Төзелешне Фәрит Ярхәм улы Зыятдинов башлап йөргән һәм Яшел Үзән районы халкы, хәйриячеләр ярдәме белән мәчетне ике ел эчендә сафка бастырган. Бер катлы агач мәчет берьюлы 40 кешене сыйдыра, барлык уңайлыклары булган тәһарәт бүлмәсе бар. Зур Өтәк авылында яңа мәчет ачылганнан соң, Яшел Үзән мөхтәсибәтендә мәчетләр саны 48 гә җитте.

## Нәзарәттә «Яшь килен» проектының 7 нче сезоны төгәлләнде

Рабигыль-ахыр аеның 24 нче көнендә Татарстан мөфтиятендә мөселман яшьләре арасында популярлык казанган «Яшь килен» курсларының җиденче сезоны төгәлләнде. MUSLIMMOL мөселман яшьләр хәрәкәте чаралары һәрвакытта заманча, иҗади, эчтәлекле уза, «Яшь килен» проектының саубуллашу кичәсе дә искәрмә булмады, ул гадәттәгечә Коръән аятьләре уку һәм Аллаһыга якынаю, иминлек, күңел тынычлыгы, гаиләдә бәрәкәт сорап дога кылу белән башланды. Бу юлы проектта 50 мөслимә катнашты. Алар, курсларны тәмамлап, матур итеп эшләнгән дипломнар алды.

Киленнәр мәктәбе 17 яшьтән алып һәм өлкәнрәк булган, кияүдә булмаган, кияүдәге һәм кызларын кияүгә бирергә җыенган әниләр өчен оештырылды. Дәресләр Коръән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәте һәм дин галимнәренең гыйлемнәренә нигезләнде. Берничә ай эчендә мөслимәләр укырга йөреп белем туплады һәм соңгы дәрестә үзенчәлекле имтихан тотты. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: бу лекцияләр яшь киленнәр кабат таныша алсын өчен, проектның махсус чатларына урнаштырылган. Иҗади кичә мөнәҗәтләр, дустанә аралашу, татар гаиләсе традицияләрен чагылдырган гамәлләр, катнашучыларның рәхмәт сүзләре белән үрелеп барды.

## «Ислам. Беренче адымнар»ның 10 нчы сезоны тәмам: намаз укырга һәм Ислам нигезләренә 100 кеше өйрәнде

Җөмәдәл-әүвәл аеның 2 нче көнендә Нәзарәтнең халык арасында зур популярлык казанган проекты – «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбе үз эшен төгәлләде. Бу юлы намаз укырга 100 кеше өйрәнде. Курсларның ябылу өлеше тантаналы рәвештә үтте. Алты дәрес дәвамында белем

биргән укытучылар нәсыйхәт сүзләрен җиткерде. Һәр елдагыча, курсларга йөрүчеләр 6 дәрестә (атнасына бер тапкыр) намаз уку күнекмәләрен һәм Ислам дине нигезләрен бушлай үзләштерде. Беренче дәрестә укучылар тәһарәт алу тәртипләрен өйрәнсә, калган өч дәрес – намаз укуга, бишенче дәрес – хәләл һәм харам төшенчәләрен аңлатуга, алтынчы дәрес – ураза тәртипләре турында булды. Дәресләр татар һәм рус телләрендә оештырылды.

# Нәсыйхәт

# Тәүбә бәянының икенче бүлеге

Факыйһ[1] радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять итә. Дөреслектә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәүбә ишеге турында хәбәр иткән. Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһе: «Әй, Расүлуллаһ, нәрсә ул тәүбә ишеге?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Тәүбә ишеге кояш иңә торган тарафның артында. Ул ишекнең алтыннан ике канаты бар, алар энҗе һәм якут белән тукылганнар. Бер канаты белән икенче канаты арасы атка атланып ашыгып йөрүче кешегә кырык еллык юлдыр. Бу ишек Аллаһы Тәгалә халык кылган көннән алып, кояш көнбатыштан туачак кичнең таңына кадәр ачыктыр. Аллаһының бәндәләреннән булган бер бәндә чын тәүбәне кылса, бу ишектән керер. Могаз бине Җәбәл радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Йә, Расүлуллаһ, атам һәм анам фида булсын, нәрсә ул чын тәүбә?» Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип җавап биргән: «Гөнаһ кылучының кылган гөнаһы өчен үкенү һәм Аллаһы Тәгаләгә ялыну, моннан соң ул гөнаһка кайтмау. Тәүбә ишеге ачык булып торыр-торыр да, кояш белән ай шул ишектә батарлар. Моннан соң ике канат кара-каршы килер һәм араларында һич ярык булмаган хәлдә ябылыр. Бу вакытта бәндәдән тәүбә кабул ителмәс, Исламда кыла торган изге эш аңа файда бирмәс, бары моңа кадәр иман китергән кешенең изгелеге генә файда бирер, чөнки тәүбә ишеге бикләнмәстән беренче гамәле бәндә белән булыр. Моңа Аллаһы Тәгаләнең сүзе дәлил:

يَوْمَ يَأْتِي بَعْضُ آيَاتِ رَبِّكَ لَا يَنفَعُ نَفْسًا إِيمَانُهَا لَمْ تَكُنْ آمَنَتْ مِن قَبْلُ
أَوْ كَسَبَتْ فِي إِيمَانِهَا خَيْرًا ۗ

[1] Бу язмада «факыйһ» дигәндә, «Тәнбиһүл гафилин» китабының авторы Әбү Ләйс Сәмәрканди хакында сүз бара.

**«Раббыңның аятьләреннән кайберсе киләсе көнне, элегрәк ышанмаган яки иманында [ихлас һәм тәүбә кебек] бер хәер казанмаган җанга [ул көндәге] иманы файда бирмәячәк».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:158

Габдулла бине Мәсгудтән риваять ителә, дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Чын тәүбә – ул тәүбә кылып, соңыннан бу гөнаһка кире кайтмау».

Габдулла бине Мәсгудтән риваять ителә. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Тәүбә ишеге ачык, тәүбә һәркемнән кабул ителер, бары өч кешедән генә кабул ителмәс. Көферлекнең башы булган Иблистән, хата кылучыларның башы булган Кабил бине Адәмнән һәм пәйгамбәрләрдән булган кешене үтерүчедән».

Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Тәүбә ишеге тәүбә итүчеләргә мәгъриб тарафыннан кырык ел йөрерлек юл чаклы ачыктыр. Кояш бата торган тарафыннан туганга кадәр, ул ишек тәүбә кылучылар өчен бикләнмәс».

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять итә. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Тәүбә һавада бикләнгәндер, кич тә, көндез дә: «Мине кабул иткән кеше газапланмас, ягъни газап күрмәс», – дип кычкырыр. Һәр заманда, хәтта кояш бата торган тарафтан туганга кадәр ошбу халәттә булыр. Әгәр кояш бата торган тарафтан туса, ул тәүбә күтәрелер».

Бу хәбәрләрдә тәүбәгә кызыктыру бәяны бардыр. Дөреслектә, бәндә тәүбә кылса, тәүбәсе кабул булыр. Аллаһы Тәгалә мөэминнәрне тәүбәгә өнди һәм болай дип әйтә:

وَتُوبُوا إِلَى اللَّهِ جَمِيعًا أَيُّهَ الْمُؤْمِنُونَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿٣١﴾

**«Ий мөэминнәр! Бөтенегез бергә Аллаһыга тәүбә итегез! Бәлки, сез [ике җиһан бәхетенә ия булып] уңышка ирешерсез».**

«Ән-Нур», 24:31

Ягъни Аллаһы Тәгаләнең газабыннан котылуыгыз һәм Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешүегез өчен тәүбә кылыгыз. Аллаһы Тәгалә бәян итте, дөреслектә, тәүбә һәр изгелекнең ачкычыдыр, мөэминнең котылуы тәүбәсендәдер. Аллаһы Тәгалә мөэминнәргә тәүбә белән әмер итә һәм болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا تُوبُوا إِلَى اللَّهِ تَوْبَةً نَّصُوحًا

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыга ихлас бер тәүбә белән тәүбә итегез».**

«Әт-Тәхрим / Тыю», 66:8

Моннан соң Аллаһы Тәгалә тәүбәдә булган кәрамәтләрне бәян итеп болай дип әйтә:

عَسَىٰ رَبُّكُمْ أَن يُكَفِّرَ عَنكُمْ سَيِّئَاتِكُمْ وَيُدْخِلَكُمْ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ

**«Бәлки, Раббыгыз сезнең начар эшләрегезне кичерер һәм Аллаһы пәйгамбәре салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның белән бергә иман китергәннәрне рисвай итмәячәк беркөнне сезне асларыннан елгалар агып торган җәннәтләргә кертер».**

«Әт-Тәхрим / Тыю», 66:8

Ягъни Ахирәттә сезгә утыра торган урыннар һәм агачлар астында елгалар ага торган бакчаларны бирер, дип Аллаһы Тәгалә аларга хәбәр бирде. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә тәүбә кылучыларның гөнаһларын ярлыкаучыдыр. Зикере газиз булган Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَالَّذِينَ إِذَا فَعَلُوا فَاحِشَةً أَوْ ظَلَمُوا أَنفُسَهُمْ ذَكَرُوا اللَّهَ فَاسْتَغْفَرُوا لِذُنُوبِهِمْ
وَمَن يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلَّا اللَّهُ وَلَمْ يُصِرُّوا عَلَىٰ مَا فَعَلُوا وَهُمْ يَعْلَمُونَ ﴿١٣٥﴾

**«Янә алар [тәкъвалык ияләре, зур гөнаһлар кылып] бик кабахәт бернәрсә эшләсә яки [кечерәк гөнаһ кылып] үзләренә золым китерсә, Аллаһыны искә төшерәләр дә, [шунда ук үкенә-үкенә тәүбә итеп] гөнаһлары өчен ярлыкау сорыйлар. Гөнаһларны исә Аллаһыдан башка кем гафу итә? Һәм алар белә торып гөнаһларын кабатлауда үҗәтлек күрсәтмиләр».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:135

Монда «үзләренә золым китерсә» сүзенең мәгънәсе, ягъни кеше зур һәм кечкенә гөнаһларны кылса дигәнне аңлата.

Сәгыйд бине Әбү Бөрдәдән, ул атасыннан, ул бабасыннан, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Мин көнгә йөз мәртәбә Аллаһы Тәгаләдән ярлыкауны телим һәм Аңа тәүбә итәм».

Икенче бер риваятьтә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әй, кешеләр, Аллаһы Тәгаләгә тәүбә кылыгыз, чөнки мин Аллаһыга көненә йөз мәртәбә тәүбә итәм».

Аллаһы Тәгалә аның үткән һәм элек булган гөнаһысын ярлыкаган булса да, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакыт ярлыкауны теләде һәм тәүбә кылды. Инде кеше үзенең ярлыканганмы яисә юкмы икәнен белмәгәч, ничек Аллаһыга һәрвакыт тәүбә кылмасын һәм ничек телен мәңге истигъфар[1] белән мәшгуль итмәсен?!

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе Аллаһы Тәгаләнең сүзен тәфсир итте. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

بَلْ يُرِيدُ الْإِنسَانُ لِيَفْجُرَ أَمَامَهُ ﴿٥﴾

**«Әмма кеше [булган хәлендәге кебек] алга таба да хактан тайпылуын дәвам итәргә тели».**

«Әл-Кыямә / Кыямәт», 75:5

[1] Тәүбә кылу.

Ягъни гөнаһны кыла, аннан соң тәүбә кылырмын, дип тәүбәсен кичектерә һәм шул явызлыгында аңа үлем ирешә.

Җөвәйбердән, ул Даххәктән, ул Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Мөсәүвыйфлар һәлак булды». Мөсәүвыйф дип шундый кешегә әйтелә, ул тиздән тәүбә итәрмен дип әйтә, әмма тәүбәсен кичектерә. Һәр кешегә үлгәнгә кадәр һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә тәүбә кылу вәҗибтер, чөнки Аллаһы Тәгалә тәүбәне кабул кылучы.

Шул рәвештә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَهُوَ الَّذِي يَقْبَلُ التَّوْبَةَ عَنْ عِبَادِهِ وَيَعْفُو عَنِ السَّيِّئَاتِ وَيَعْلَمُ مَا تَفْعَلُونَ

**«Ул [Үзе теләгән] колларыннан тәүбәне кабул итә, [кылган] начар нәрсәләрен гафу итә һәм кылган нәрсәләрен белә».**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:25

Ягъни кеше тәүбә кылса һәм Аллаһыга кайтса, Аллаһы Тәгалә аның явызлыкларын кичектерә. Тәүбә – шул кылган гөнаһына калебе белән үкенү, теле белән истигъфар кылу, һәм күңеленнән, мәңгегә ул гөнаһка кайтмыйм, дип сүз бирү ул.

Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Берәү, олуг Аллаһыдан ярлыкауны телим, дип әйтсә, «Аллаһыдан башка гыйбадәт кылына торган зат юктыр, мәгәр Ул терек һәм эшне аңлатучы Аллаһы гынадыр һәм Аңарга тәүбә итәм», ягъни: «Әстәгъфируллаһил-гаҙыйм әлләҙи ләә иләәһә иллә һувәл-хаййүл-каййум вә әтүүбү иләйһи», – дип өч мәртәбә әйтсә, бөтен гөнаһлары диңгез күбеге кадәр булса да – ярлыканыр».

Әюб Әбү Каләбәдән риваять ителде. Әбү Каләбә болай дип әйткән: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Иблискә ләгънәт кылгач, Иблис Аллаһы Тәгаләдән Кыяматкә кадәр үлмәүне сорады. Аллаһы Тәгалә аны Кыяматкә

кадәр үлми торган кылды, Иблис болай дип әйтте: «Синең гыйззәтең белән ант итәм, бәндәнең җаны чыкканчыга кадәр бәндәңнең күкрәгеннән чыкмам». Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: «Гыйззәтем һәм җәләлем белән ант итәм, ул бәндәнең җаны чыкканчыга кадәр бәндәмнән тәүбәне пәрдәләмим». Аллаһының бәндәләренә булган рәхмәтенә һәм шәфкатенә игътибар ит: гөнаһ кылганнан соң да, аларны мөэминнәр дип атады. Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَتُوبُوا إِلَى اللَّهِ جَمِيعًا أَيُّهَ الْمُؤْمِنُونَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿٣١﴾

**«Ий мөэминнәр! Бөтенегез бергә Аллаһыга тәүбә итегез! Бәлки, сез [ике җиһан бәхетенә ия булып] уңышка ирешерсез».**

«Ән-Нур», 24:31

Аллаһы Тәгалә ул бәндәләрен тәүбә кылганнан соң ярата. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ التَّوَّابِينَ وَيُحِبُّ الْمُتَطَهِّرِينَ ﴿٢٢٢﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы тәүбә итүчеләрне һәм тәмам чистарынучыларны сөя».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:222

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Гөнаһтан тәүбә итүче гөнаһысы булмаган бәндә кебектер».

Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһедән риваять ителде. Дөреслектә, бер ир аннан сорады һәм: «Дөреслектә, мин гөнаһка төштем», – дип әйтте. Гали радыяллаһу ганһе аңа: «Аллаһы Тәгаләгә тәүбә ит, моннан соң кабат кайтып, ул гөнаһны кылма», – диде. Ул кеше: «Дөреслектә, мин гөнаһ кылдым һәм соңыннан янә кылдым», – дип әйтте. Гали радыяллаһу ганһе: «Аллаһыга тәүбә кыл, аннан соң гөнаһыңа кабат кайтма», – диде. Бу кеше: «Кайчанга кадәр?» – дип сорады. Гали

радыяллаһу ганһе: «Хәтта шәйтан өметсез булганга кадәр», – дип җавап бирде.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَلَيْسَتِ التَّوْبَةُ لِلَّذِينَ يَعْمَلُونَ السَّيِّئَاتِ حَتَّىٰ إِذَا حَضَرَ أَحَدَهُمُ الْمَوْتُ قَالَ إِنِّي تُبْتُ الْآنَ

**«[Дәвамлы рәвештә] Явызлык кылган, үлем килгәч [кенә]: «Мин хәзер тәүбә иттем», – дип әйткәннәргә ул [кабул ителә торган] тәүбә юк».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:18

Мөҗәһид Аллаһы Тәгалә сүзенең тәфсирендә болай дип әйткән: «Дөреслектә, кайбер кеше гомер буе начар гамәлләр кыла һәм тәүбә итү турында уйламый, бары тик үлем килгәч кенә тәүбәгә килә».

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр кеше бер гөнаһны кылганнан соң: «Әй, Раббым, мин гөнаһ кылдым, Син мине ярлыка», – дисә, Аллаһы Тәгалә болай дип әйтер: «Минем бәндәм гөнаһ кылды һәм ул бәндә гөнаһны ярлыкаучы Раббысы булуын белә, дөреслектә, Мин бәндәмне ярлыкадым».

Боларның бөтенесе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дәрәҗәсе өчендер. Үткән өммәтләрдә гөнаһ кылсалар, аларга хәләл нәрсә харам ителә иде. Әгәр аларның берсе гөнаһ кылса, капкаларында: «Фәлән улы фәлән гөнаһ кылды һәм аның тәүбәсе шулдыр», – дигән сүзләр табылыр иде. Шул рәвешле алар оятка калыр иде. Ә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтенә исә эш җиңел кылынды. Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

وَمَن يَعْمَلْ سُوءًا أَوْ يَظْلِمْ نَفْسَهُ ثُمَّ يَسْتَغْفِرِ اللَّهَ يَجِدِ اللَّهَ غَفُورًا رَّحِيمًا

**«Кем дә кем [башка берәүгә карата] начарлык эшләп яки [үзе белән бәйле бер-бер гөнаһ кылып] үз-үзенә золым итеп, соңыннан Аллаһыдан ярлыкау сораса, Аллаһыны [гөнаһларны] Гафу итүче, [тәүбә итүчеләргә карата бик] Рәхимле дип табар».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:110

Һәр мөселманга таңга һәм кичкә кергән вакытта Аллаһы Тәгаләгә тәүбә итү вәҗибтер. Бер кеше кичкә һәм таңга кереп тәүбә кылмаса, ул бәндә залимнәрдәндер. Бәндәгә һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә тәүбә кылу һәм намазны вакытыннан калдырмыйча укырга тырышу тиеш була, чөнки Аллаһы Тәгалә бәндәләрнең зур гөнаһларыннан башка гөнаһларын пакьләү өчен биш вакыт намазны фарыз кылды.

Галкамә Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһедән риваять итте. Ул болай дип әйткән: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бер ир килде һәм болай дип әйтте: «Бакчада мин бер хатынга очрадым, аны үптем, аның белән һәрнәрсәне эшләдем, ләкин якынлык кылмадым». Пәйгамбәребез бераз вакыт тик торды һәм бу аять инде:

وَأَقِمِ الصَّلَاةَ طَرَفَيِ النَّهَارِ وَزُلَفًا مِّنَ اللَّيْلِ ۚ إِنَّ الْحَسَنَاتِ يُذْهِبْنَ السَّيِّئَاتِ ۚ ذَٰلِكَ ذِكْرَىٰ لِلذَّاكِرِينَ ﴿١١٤﴾

**«Көннең ике очында [өйлә һәм икенде вакытында] һәм [иртә вакыты белән ахшам-ястү кебек] төннең [таңга] якын сәгатьләрендә [фарыз булган биш вакыт] намаз укы. Һичшиксез, ул яхшы гамәлләр начар эшләрне йолалар. Бу – үгет алучылар өчен бер вәгазь».**

«Һуд», 11:114

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ул ирне өндәде һәм бу аятьне укыды. Гомәр радыяллаһу ганһе әйтте: «Әй, Расүлуллаһ, бу эш ул ирнең үзенә генәме яки бөтен кешегәдәме?» Пәйгамбәребез салләллаһу

галәйһи вә сәлләм: «Барча кешеләргәдер», – дип әйтте.

Хәсән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итте. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Һәрбер кешенең гамәлләрен язып баручы ике фәрештә бар. Уң яктагы фәрештә сул як фәрештәсенә сакчыдыр. Әгәр бәндә явызлык кылса, сул як фәрештәсе: «Ул явызлыкны языйммы?» – дип сорар. Уң як фәрештәсе аңа: «Син аны биш явызлыкны кылганга кадәр язмый тор», – дип әйтер. Кеше биш явызлыкны кылса, сул яктагы фәрештә: «Бу гамәлләрне языйммы?» – дип сорар. Уң як фәрештәсе: «Бер изгелек кылганга кадәр язмый тор», – дип әйтер. Әгәр кеше бер изгелек кылса, уң яктагы фәрештә: «Дөреслектә, безгә мондый хәбәр бирелде: бер яхшылык ун яхшылык кебек була. Без биш гөнаһны сөртик һәм аңа биш яхшылык язып куйыйк».

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Бу вакытта шәйтан: «Адәм баласы кайчан бу дәрәҗәгә иреште?» – дип кычкырыр».

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять итә. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Бер кичтә Пәйгамбәребез белән ястү намазы укыганнан соң, урамга чыктым. Шул вакытта йөзенә пәрдә каплап, юлда торучы хатынны очраттым. Ул: «Әй, Әбү Һөрайра, дөреслектә, мин зур гөнаһ кылдым, минем өчен тәүбә булырмы?» – диде. «Гөнаһың ни?» – дип сорадым. Хатын: «Дөреслектә, мин зина кылдым, зинадан булган баламны үтердем», – диде. Мин аңа: «Син үзең дә һәлак булдың һәм баланы да һәлак иттең. Аллаһы белән ант итәм, сиңа тәүбә юк», – дидем. Ул каты итеп кычкырды һәм һушы китеп егылды. Бу вакытта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яныбызда түгел иде. Таңга кергәндә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килдем һәм аңа: «Әй, Расүлуллаһ, дөреслектә, бер хатын мондый эш хакында фәтва сорады, дөреслектә, мин фәтваны болай бирдем», – дидем. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм

болай дип әйтте: «Валлаһи, Әбү Һөрайра, син һәлак булдың һәм һәлак тә кылдың. Бу аятьне белми иденме? Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

وَالَّذِينَ لَا يَدْعُونَ مَعَ اللَّهِ إِلَٰهًا آخَرَ وَلَا يَقْتُلُونَ النَّفْسَ الَّتِي حَرَّمَ اللَّهُ إِلَّا بِالْحَقِّ وَلَا يَزْنُونَ ۚ

**«Янә алар Аллаһы белән беррәттән башка илаһка табынмыйлар [үтергән бер кеше өчен кыйсас, Исламга кергәннән соң диннән чыгу һәм өйләнгән килеш зина кылу кебек] хак белән булмыйча, Аллаһы тыйган җанны үтермиләр, зина да кылмыйлар»,**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:68

إِلَّا مَن تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ عَمَلًا صَالِحًا فَأُولَٰئِكَ يُبَدِّلُ اللَّهُ سَيِّئَاتِهِمْ حَسَنَاتٍ ۗ

**«Тик [көферлектән] тәүбә иткән, иман китергән һәм изге гамәл кылган кешеләр булмаса гына! Аларның [тәүбәләре сәбәпле сөртелгән] начарлыкларын Аллаһы күркәм нәрсәләр белән алмаштырачак».**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:70

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Расүлуллаһ яныннан чыкканнан соң, Мәдинә урамнарында йөгереп йөреп: «Кем мине кичә миннән фәтва сораган хатынга илтер?» – дип сорадым. Балалар миңа ул хатынны җенләнгән дип әйттеләр. Кич җиткәч, ул хатынны беренче мәртәбә күргән урында очраттым һәм аңа Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Дөреслектә аңа тәүбә бар», – дигән сүзләрен җиткердем. Ул хатын бик каты шатланды һәм: «Дөреслектә, минем бакчам бар, ул бакча гөнаһыма кәффарәт йөзеннән мескеннәргә садака булсын», – диде.

Кайбер имамнар болай дип әйткән: «Дөреслектә, бәндә гөнаһлардан тәүбә итсә, үткән гөнаһларының барчасы изгелеккә әверелер».

Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Кыямәт көнендә кеше үзенең дәфтәренә карар, ул дәфтәрнең башында гөнаһларын, соңгы ягында изгелекләрен күрер. Әгәр яңадан китапны башыннан караса, ул китапның барчасында игелекләр икәнен күрер».

Әбү Зәрр Әл-Гафәри моның мисалын Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итте. Бу Аллаһы Тәгаләнең: «Аллаһы Тәгалә аларның явызлыкларын изгелекләргә алыштырыр», дигән сүзенең мәгънәсе. Дөреслектә, ул явыз гамәл изге гамәлгә әйләнер. Аллаһы Тәгалә явызлыклар урынына изгелекләрне уңайлы итәр.

Әй, кардәшем, бел: дөреслектә, көфердән зуррак гөнаһ юк. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

قُل لِّلَّذِينَ كَفَرُوا إِن يَنتَهُوا يُغْفَرْ لَهُم مَّا قَدْ سَلَفَ

**«[Расүлем!] Кяфер булганнарга: «Әгәр алар [Исламга кереп, сиңа дошманлыктан] ваз кичсәләр, элекке [начар] нәрсәләр аларга гафу ителәчәк».**

«Әл-Әнфәл / Табышлар», 8:38

Хәсән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр сезнең берәрегез җир белән күк арасы тулганга кадәр хата кылса, моннан соң тәүбә итсә, Аллаһы Тәгалә аның тәүбәсен кабул итәр».

Язид Ракашидән риваять ителде: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең минбәрендә Әбү Һөрайра безгә болай дип хотбә сөйләде: «Пәйгамбәребездән ишеттем, ул салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Адәм баласы Аллаһы Тәгалә мәхлүкъларының иң изгеседер. Аллаһы Тәгалә аңа Кыямәт көнендә өч төрле сорау белән гозер кылыр[1]. Аллаһы Тәгалә ул бәндәгә болай дип әйтер: «Әй, адәм, әгәр ялганчылар-

[1] Үтенер.

га ләгънәт кылмасам, ялганга ачуланмасам, аларга җәза бирмәс идем, дөреслектә, Минем сүзем хак булды:

لَأَمْلَأَنَّ جَهَنَّمَ مِنَ الْجِنَّةِ وَالنَّاسِ أَجْمَعِينَ

**«Мин җәһәннәмне җеннәр һәм кешеләр белән бергә тутырачакмын!»**

«Әс-Сәҗдә», 32:13

Әгәр аларны ләгънәт кылмасам, бу көндә барча адәм балаларына рәхмәт кылыр идем». Аллаһы Тәгалә аңа болай дип әйтер: «Әй, Адәм, дөреслектә, синең балаларыңнан һичкемне утка кертмим һәм аны ут белән газапламыйм, бары тик Үземнең гыйлемем белән белгән кеше генә (газапка тартылыр). Дөреслектә, ул кешене дөньяга кайтарган булсам, ул дөньяда иң яман булган нәрсәгә кайтыр иде. Моннан соң тәүбә дә кылмас иде». Аллаһы Тәгалә аңа болай дип әйтер: «Дөреслектә, сине Үзем һәм балаларың арасында хак ният белән карап торучы кылдым, мизан янында тор. Балаларыңның гамәлләреннән сиңа күтәрелгән нәрсәгә кара. Берәүнең тузан бөртеге кадәр генә изге гамәле булса да, аңа – җәннәтләр, залимнан кала берәүне дә утка кертмим».

Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять иткән. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дәфтәрләр өчтер: бер дәфтәрдәге гөнаһларны Аллаһы Тәгалә ярлыкар, икенче дәфтәрдәге гөнаһларны Аллаһы Тәгалә ярлыкамас, өченче дәфтәрдәгедән һичнәрсәне калдырмас. Аллаһы Тәгалә ярлыкамый торган дәфтәр – ул Аллаһы Тәгаләгә ширектер. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

إِنَّهُ مَن يُشْرِكْ بِاللَّهِ فَقَدْ حَرَّمَ اللَّهُ عَلَيْهِ الْجَنَّةَ وَمَأْوَاهُ النَّارُ ۖ

**«Кем дә кем Аллаһыга ширек кушса, Аллаһы [тәүхид ияләренә булган] җәннәтне аңа харам кылды. Аның сыенасы урыны [мөшрикләр өчен әзерләнгән] Ут [булыр]».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:72

Аллаһы Тәгалә ярлыкый торган гөнаһлар – кешенең үз-үзенә һәм Аллаһы Тәгаләгә карата мөнәсәбәттә булган гаделсезлекләр белән бәйле гөнаһлардыр. Ә тулысынча ярлыкый торган гөнаһлар – колларның бер-берсен җәберләве белән бәйле булган гөнаһлардыр.

Әбү Һөрайра Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итте. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һичшиксез, Кыямәт көнендә мәхлүкъләр арасында хисап кылыныр, хәтта мөгезсез хайван файдасына мөгезле хайваннан да хисап булыр», – дип әйткән.

Кешеләр өчен дошманнарының ризалыгын алырга тырышу тиешледер. Әгәр гөнаһ аның белән Аллаһы Тәгалә арасында булса, Аллаһы Тәгаләдән ярлыкау сорау тиештер, чөнки Аллаһы Тәгалә колларына карата рәхмәт итүчедер. Гөнаһ үзе белән бәндәләр арасында булса, дөреслектә, ул гөнаһ, һичшиксез, Кыямәт көнендә соралыр. Аңа дошманының ризалыгын алмый торып, ярлыкауны теләү яки тәүбә кылу файда бирмәс. Кыямәт көнендә аның изгелекләреннән алынып, кимсетелгән кешесенә бирелер.

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итте. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кешеләрдән болай дип сораган: «Йә, минем өммәтемнән мөфлиснең (банкротның) кем икәнен беләсезме?» Расүлебезгә: «Бездә мөфлис – ул ярлы булган, көмеше дә, алтыны да һәм башка нәрсәсе дә булмаган кешедер», – дип җавап бирделәр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Минем өммәтемнән мөфлис кеше шулдыр: ул Кыямәт көнендә нама-

зы һәм уразасы белән килер. Әмма аның кемнедер тиргәгән, кемнедер сүккән, кемнеңдер малын ашаган, кемнеңдер канын түккән, кемгәдер суккан булуы ачыкланыр. Моның өчен аның изгелекләре алынып, фәлән кешегә бирелер. Әгәр аның бирерлек изгелекләре бетсә, аның өчен булган нәрсәләрне биреп бетермәстән элек, аңа җәбер ителгән бәндәләрнең гөнаһлары өстәлер һәм моннан соң ул утка ташланыр».

Аллаһы Тәгаләдән безгә тәүбәләребезнең дөрес булуын һәм тәүбә итүчеләрдән булуыбызны сорыйбыз, чөнки тәүбәдә нык булу – тәүбәдән катырактыр.

Мөхәммәд бине Сирин болай дип әйткән: «Изгелектән бер нәрсәне кылып, моннан соң аны калдырудан үзеңне ерак кыл, ягъни изгелекне бер мәртәбә кылып та, аннан соң аны кылуны ташлама. Андый эштән үзеңне ерак кыл, чөнки тәүбә кылып, моннан соң яңадан (гөнаһка) кайтып, котылу тапкан берәү дә юктыр. Тәүбә кылучыга, тәүбәдә нык булу өчен, әҗәлне ике күз арасында кылу, гөнаһыннан үткән нәрсә хакында уйлау, ярлыкауны теләүне күбәйтү тиештер. Моның өчен тәүбәдән аңа ризыкландырган нәрсәгә, аны тәүбәгә уңайлы кылганы өчен, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итәр. Кыямәт көнендәге савабын уйлаган кеше изгелек теләр. Дөреслектә, Ахирәтнең савабын уйлаган кеше изгелекләргә омтылыр. Газап турында уйлаган кеше явызлыклардан тыеладыр».

Зәед бине Вәһһәб Әбү Зәррдән риваять итә. Әбү Зәрр болай дип әйткән: «Әй, Расүлуллаһ, Муса галәйһиссәламнең сохефләрендә (күктән иңгән битләр) булган нәрсәләр хакында безгә хәбәр бир, дидем. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Анда алты сүз бар иде: тәмугның барлыгын белгән кешегә гаҗәпләндем: ничек ул көлә ала? Үлемне анык дип белгән кешегә гаҗәпләндем: ул ничек шатлана ала? Хисапны анык дип белгән кешегә гаҗәпләндем, ул ничек явызлыкларны кыла ала? Тәкъдирне белгән кешегә гаҗәпләндем, ул ничек мәшәкатьләнә ала? Икенче хәбәрдә «ничек кайгыра ала», диелә. Дөньяны

һәм ул дөньяның әһеле алмашуын күргән кешегә гаҗәпләнәм: ничек аның күңеле тыныч халәттә кала ала? Җәннәтне анык дип белгән кешегә гаҗәпләнәм: ни өчен ул изгелекләр кылмый? Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылуга лаеклы зат юктыр, Мөхәммәд – Аллаһының Расүледер».

Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһедән риваять ителә, бер көнне ул Куфа тарафларыннан булган бер урыннан үтте. Шул вакытта гөнаһлы кешеләр җыелып, хәмер эчәләр иде. Араларында «Зәзән» исемле уенчы бар иде. Ул барабан кагып, уен коралларында уйный, күркәм тавышы белән җырлый иде. Габдулла бине Мәсгуд моны ишеткәч: «Нинди гаҗәеп, күркәм тавыш. Бу тавыш Аллаһы Тәгаләнең китабын уку өчен булса иде», – дип әйтте дә, бөркәнчеген башына куеп, үз юлы белән китте. Уенчы аның сүзен ишетеп: «Бу кем иде?» – дип сорады. Аңа: «Расүлуллаһның иптәше – Габдулла бине Мәсгуд», – дип җавап бирделәр Уенчы: «Ул нәрсә әйтте?» – дип сорады. Аңа: «Нинди гаҗәеп, күркәм тавыш. Бу тавыш Коръән укырга булса иде, дип әйтте», – диделәр. Уенчының күңеленә курку керде, урыныннан торып, думбрасын җиргә сугып сындырды. Моннан соң Габдулла бине Мәсгудне куып тотты һәм елый башлады. Габдулла бине Мәсгуд аны кочаклады һәм алар икесе дә еларга тотындылар. Моннан соң Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһе: «Ничек мин Аллаһы Тәгалә сөйгән һәм гөнаһтан тәүбә иткән бәндәне сөймәскә мөмкинме?!» – дип әйтте. Зәзән Ибне Мәсгудкә иярүчеләрдән булды, аннан Коръән өйрәнде, гыйлемнән өлеш алды һәм хәтта танылган гыйлем иясе булды. Күп риваятьләр Зәзәннән һәм Габдулла бине Мәсгудтән дип килә.

Факыйһ үзенең әтисеннән риваять итә. Мин атамнан ишеттем, ул болай дип сөйләде: «Дөреслектә, Исраил уллары арасында зиначы хатын бар иде. Ул үзенең күркәмлеге белән кешеләрне фетнәгә төшерә иде. Аның өенең ишеге һәрвакыт ачык иде. Аның капкасыннан үткән һәр кеше ул хатынны өендә, ишек каршысындагы урындыкта утырган хәлдә күрә иде. Аңа караган һәр кеше аның белән фетнәләнә иде. Әгәр берәү аның яны-

на керергә теләсә, ул кешегә рөхсәт бирелгәнгә кадәр, ун алтынны яисә аннан азракны яисә күбрәкне әзерләргә тиеш иде. Беркөнне гыйбадәт кылучылардан булган бер кеше ул хатынның өе яныннан үтте һәм аның күзе йорт эченә төште. Әлеге хатын урындыкта утыра иде. Бу кеше аның белән фетнәгә төште һәм нәфесе белән сугышырга тотынды, Аллаһы Тәгаләгә йөрәгеннән моны җибәрсен өчен, дога кыла башлады. Бу фетнә аннан чыкмады, ул нәфесенә бирелде, хәтта үзендә булган бүзен[1] сатты һәм аңа мохтаҗ булган ун алтынны җыйды, хатынның капкасына килеп, ул хатынның вәкиле булган кешегә акчаны тапшырырга боерды. Ул кеше килсен өчен, хатын бер вакытны вәгъдә кылды. Бу кеше билгеләнгән вакытка хатын янына килде. Дөреслектә, ул хатын зиннәтләнгән һәм урындыкка утырган иде. Бу кеше ул хатын янына керде һәм аның белән урындыкка утырды, аңа кулын сузды. Ул хатынга якынлашкач, Аллаһы Тәгалә Үзенең рәхмәте һәм бу колның элек булган гыйбадәтенең бәрәкәте белән җитеште. Аның күңеленә: «Бу вакытта мин кылган нәрсәне Аллаһы Тәгалә Гареш өстендә күрәдер. Мин бу харамда, дөреслектә, минем гамәлемнең барчасы югалды», – дигән уй төште. Ул колның күңелен курку биләп алды, аның бар тәне тетрәде һәм йөзе үзгәрде. Хатын аңа карап, йөзе үзгәргәнен күрде һәм: «Сиңа нәрсә булды?» – дип сорады. Бу кеше: «Мин Аллаһы Тәгаләдән куркам, миңа чыгарга рөхсәт бир», – дип әйтте. Хатын аңа: «Тукта, синең урыныңда күпләр булырга тели. Сиңа килгән бу халәт нәрсә ул?» – дип сорады. Ул кеше аңа: «Дөреслектә, мин Аллаһы Тәгаләдән куркам, сиңа биргән мал сиңа хәләл булсын, миңа чыгарга рөхсәт ит», – диде. Хатын бу кешегә: «Мөгаен, син беркайчан да зина кылмагансыңдыр?» – дип сорады. Бу кеше: «Юк», – диде. Хатын: «Син кайдан һәм исемең ничек?» – дип сорады. Ул хатынга фәлән авылдан һәм аның иseме фәлән дип хәбәр бирде. Бәс, хатын аңа чыгарга рөхсәт итте. Бу кеше хатын яныннан чыкты, үкенеч һәм һәлакәт белән «харап булдым», дип кычкырды

[1] Яулык.

һәм туфракны башына чәчеп, үзалдына елады. Бу кешенең бәрәкәтендә хатынның күңеленә дә курку төште, үзалдына: «Дөреслектә, бу әлеге кешенең беренче кылган гөнаһысыдыр, ә мин инде ничә еллардан бирле гөнаһ кылам. Ул курка торган Аллаһы Тәгалә минем дә Аллаһымдыр. Минем Аллаһыдан куркуым катырак булырга тиеш», – дип фикер йөртте. Бу хатын гөнаһлары өчен Аллаһы Тәгаләгә тәүбә кылды, капкасын бикләде, иске киемнәр киде һәм гыйбадәткә юнәлде. Аллаһы Тәгалә теләгән кадәр гыйбадәтендә булды. Хатын үз эченнән: «Дөреслектә, мин бу кешене очратсам, шаять, ул мине хатынлыкка алыр, аның каршында булырмын, дин эшенә өйрәнермен. Ул Аллаһы Тәгаләнең гыйбадәтенә минем өчен ярдәм бирер», – дип әйтте. Моннан соң ул әзерләнде, үзе белән Аллаһы теләгәнчә мал һәм хезмәтчеләр алды һәм әлеге кеше авылына барып туктады. Аның турында сорашты. Ул кешегә: «Дөреслектә, эш буенча сиңа бер хатын килде, сине сорады», – дип хәбәр бирделәр. Бу кеше аның янына чыкты. Хатын аны күргәннән соң, үзен таныту өчен, йөзеннән пәрдәсен ачты. Ул кеше хатынны таныды, үзе белән хатын арасындагы булган эшне исенә төшереп, кычкырып җибәрде һәм аның җаны чыкты, хатын хәсрәтле калды һәм: «Мин аның өчен йортымнан чыгып киттем. Дөреслектә, ул вафат булды, йә, туганнарыннан хатынга мохтаҗ берәү бармы?» – дип сорады. Аңа: «Аның бер изге кардәше бар, аның малы юк», – дип әйттеләр. Хатын: «Зарар юк, минем өчен малдан булган нәрсә бар, мин бай», – диде. Шул кешенең бертуган кардәше килде, ул хатынга никахланды. Ул хатыннан җиде улы туды, аларның барчасы Исраил уллары арасында пәйгамбәрләр булдылар».

*«Тәнбиһүл гафилин» китабыннан*

# Үрнәк затлар

# Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләре кая гына искә алынса да, һәрвакыт аның артыннан, шәүлә сыман, күп сүз сөйләшмәүче, серле сәхабә Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһенең исеме килә. Бу исемне барысы да белә, ул күпләрнең телендә. Мөэмин-мөселманнар арасында аның хакында ишетмәүчеләр табылмастыр, чөнки бу сәхабә 1600 дән артык хәдис риваять иткән. Әмма без аның хакында нәрсә беләбез соң? Кем булган ул? Нинди изгелекләре белән аерылып торган?

Ислам динен кабул иткәнче һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән танышканчы, Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһенең исеме Габдешшәмс (Кояш колы) булган. Әлбәттә, бу исем Ислам диненә каршы килә, шуңа да Пәйгамбәребез аңа күркәм исем биреп, Габдрахман (Рәхимленең колы) дип атаган.

Бу сәхабә хакында тагын шул факт та билгеле: ул мәче белән аның балаларын үзендә сыендырганы өчен, Әбү Һөрайра кушаматын алган. Ул аларны шулкадәр ярата торган була, аларга күп вакытын багышлый, шуңа да Әбү Һөрайра, ягъни «песи баласының әтисе» дип йөртелә башлый.

Әбү Һөрайра Дәүс кабиләсеннән була. Ул Ислам динен үзләренең башлыклары Туфаиль бине Гамрдан кабул итә, бу вакытта аның кабиләсендәге күп кеше Расүлуллаһ артыннан иярүдән баш тарта.

## Расүлуллаһка булган ихлас яратуның үрнәге

Әбү Һөрайра үзенең кабиләдәшләре белән Кызыл диңгез ярында яши һәм 7 нче һиҗри елда аларның кайберләре һәм әнисе белән Мәдинә шәһәренә күчә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән танышу бәхетенә лаек булганнан соң, ул бөтен вакытын тулысынча аңа багышлый. Әбү Һөрайра һәрвакытта диярлек мәчеттә яшәп, Пәйгамбәребезгә хезмәт итүдә була. Расүлуллаһ белән аралаша алудан тәм

табып, аннан гыйлемнәр алып, һәр җирдә аның юлдашчысына әйләнә. Ул Пәйгамбәребез исән вакытта гаиләле, бала-чагалы кеше булмый.

## Гыйлемгә омтылуы һәм гаҗәеп зиһене

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе гыйлем алуга күп вакытын багышлый торган була, хәтта Мәдинә шәһәренә күченүенең максаты да гыйлемгә омтылу була. Ул Аллаһы Тәгаләнең гыйлемле, тәкъва коллары янында булуга өметләнә.

Зәед бине Сабит радыяллаһу ганһедән тапшырыла: берьюлы ул, Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе һәм тагын бер сәхабә бергәләп мәчеттә булганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кергәндә аларның икесе дә дога кылып утырган һәм Расүлуллаһны күреп, дога кылуларын туктатканнар, әмма Пәйгамбәребез аларга дәвам итәргә кушкан һәм аларның сүзләренә «әәмин» дип торган. Зәед һәм аның дусты дога кылуны тәмамлаганнан соң да, Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе дога кылуыннан туктамаган һәм: «Йә, Раббым, миңа да иптәшләрем сораганны һәм онытылмый торган гыйлемнәрне бирсәң иде», – дип дога кылган. Расүлуллаһ аның бу догасына: «Әәмин», – дип әйткән.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе гаҗәеп хәтергә ия кеше булган һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән сүзләрне һәм эшләп күрсәткән гамәлләрне җентекләп әйтеп бирә һәм эшләп күрсәтә алган. Әбү Һөрайра үзенең бу сәләте хакында болай дип әйтә торган булган: «Безнең мөһаҗир кардәшләребез базарда сәүдә эшләре белән, ә әнсар кардәшләребез кырлардагы һәм бакчалардагы эшләре белән мәшгуль булганда мин Аллаһы Расүленең нәсыйхәтләрен истә калдыра идем». Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе өчен Пәйгамбәребезнең мирасыннан да һәм мәчеттә калып намаз, Коръән уку, Аллаһыны зикер кылудан да кадерле берни дә булмаган.

Шулай ук Әбү Һөрайра болай дип әйткән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән, Габдулла бине Гамрны санамаганда, миннән дә

күбрәк хәдис тапшыручы булмады, ул хәдисләрне язып бара иде, мин исә беркайчан да алай эшләмәдем».

Имам Әл-Бохариның хәдисләр җыентыгында хәбәр ителгәнчә, Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе берьюлы Пәйгамбәребезгә мөрәҗәгать итеп: «Йә, Расүлуллаһ, дөреслектә, мин синнән ишеткәннәремнең күбесен онытам», – дип әйткән. Шунда Пәйгамбәребез Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһегә өстендәге япмасын ачарга кушкан һәм япманы нәрсә беләндер тутырган сыман итеп, кулларын шул япмада йөртеп алган, ә аннары Әбү Һөрайрага яңадан япмасына төренергә кушкан. Шул вакыттан башлап, сәхабә бернәрсәне дә онытмаган.

## Гыйбадәт кылуда һәм изге гамәлләрдә үрнәк

Әбү Һөрайра бик күп гыйбадәт кыла торган булган: өстәмә намазлар, һәр дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә ураза тоткан. Шулай ук аның 12 000 тапкырлар тәсбих әйткәне хәбәр ителә.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм миңа һәр айны өч көн ураза тотуны, көндез доха һәм йоклар алдыннан витр намазын укуны кушты».

Имам Әл-Бохариның хәдисләр җыентыгында Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһенең әлеге сүзләре китерелә: «Мин төнне өч өлешкә бүлә идем: бер өлеше Коръән укыр өчен, икенчесе йокы өчен һәм тагын берсе хәдисләрне кабатлар өчен». Кайбер риваятьләрдә аның өендә төне буе гыйбадәт кылу туктатылмаганы хакында хәбәр ителә: төннең өчтән бер өлешендә ул үзе гыйбадәт кылган һәм Коръән укыган, аннары ул хатынын уяткан, ә үзе ял итәргә киткән, ә инде төннең соңгы өлешендә аның кызы гыйбадәт кылган. Озак еллар дәвамында шул рәвешле дәвам иткән дип хәбәр ителә.

## Әнисенә карата мөнәсәбәттә күркәмлеге

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе ятим булган. Бездә аның әтисе хакында мәгълүмат аз. Әнисе мәҗүси хатын-кыз булган, бу Әбү Һөрайраны бик нык борчуга салса да, ул сабырлык күрсәткән. Тик берьюлы аның әнисе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне сүгә башлагач, Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребезгә килеп, әнисе хакында әйткән һәм Расүлуллаһтан аның өчен дога кылуын сораган. Пәйгамбәребез Әбү Һөрайраның үтенечен игътибар белән тыңлаган һәм Әбү Һөрайраның әнисенә һидаять сорап, Раббыбызга дога кылган. Моннан соң сәхабәнең әнисе Ислам динен кабул иткән.

Риваятьләрдә Әбү Һөрайраның әнисенә карата бик тә күркәм мөгамәләдә булуы хакында хәбәр ителә, ана белән улның мондый күркәм мөнәсәбәте үрнәк итеп алына. Ул әнисен шул дәрәҗәдә хөрмәт иткән ки, хәтта сәлам юлламыйча әнисенең йортыннан чыгып та китә алмаган. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе һәр көнне аңа болай дип әйтә торган булган: «Аллаһы Тәгалә сиңа Үзенең Рәхмәтен ирештерсен, син мине кечкенә яшемнән үк тәрбияләп үстердең бит». Әнисе дә аңа: «Миңа карата булган яхшылыгың өчен Аллаһы Тәгалә сиңа да Рәхмәтен ирештерсен», – дип җавап биргән. Бу сүзләр иртәләрен һәм кичләрен кабатлана торган булган. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе бик тә фәкыйрь булган, бик еш ач хәлдә йөргән, хәтта, ачлыкны басар өчен, корсагына таш бәйләп куйган вакытлары да булган. Бер кисәк ипи өчен, кайвакыт Әбү Һөрайрага хәлле кешеләрнең дөяләрен куу эше белән кәсеп итәргә туры килгән. Әмма берьюлы ул зур табышларга ирешкән һәм моннан соң йортлы булып, гаилә корган. Аларның искиткеч кыз баласы дөньяга килгән. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе 59 нчы һиҗри елга кадәр гомер иткән һәм 78 яшендә авырып дөнья куйган. Раббыбыз аннан риза булса иде.

*Гөлназ Ситдикова*

# Фәтвалар

# Намазда Коръән укудагы хаталар

Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Имам намаз укыганда «Фатиха» сүрәсендә соңгы сүздә «ض» хәрефе урынына «ظ» хәрефен укыды. (Мөхәррир искәрмәсе – (الضَّالِّينَ) сүзендә. Бу намаз дөресме?

Җавап: Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһы исеме белән. Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Гарәп авазлары «ض» һәм «ظ» ясалу урыны (мәхраҗ) буенча берберсенә якын. Намаз укучы бу авазларны аера алмаса, яки мондый әйтелеш гадәткә керсә – намаз дөрес булачак. Әмма белә торып бу хәрефләрне әйтүдә хата ясап уку намазны бозачак:

«وإن كان لا يمكن الفصل بين الحرفين إلا بمشقةٍ كالظاء مع الضاد، والصاد مع السين، والطاء مع التاء؛ قال أكثرهم لا تفسد صلاته. هكذا في «فتاوى قاضي خان». ...إن تعمد فسدت، وإن جرى على لسانه أو كان لا يعرف التميز لا تفسد».

يُنظر: «الفتاوى الهندية»، ١/٧٩.

«Әгәр хәрефләрне тырышлык куймыйча аерып булмаса, мисал өчен «ظ» һәм «ص» ;«ض» һәм «ط» ;«س» һәм «ت», күпчелек галимнәрнең фикере буенча намаз бозылмый. Бу хакта шулай ук «Фәтава Кадыхан»да китерелгән... Әгәр белә торып [әлеге хәрефләрне әйтелештә хата ясап укылса] – намаз бозыла, әгәр шулай уку гадәткә керсә яки кеше [әлеге хәрефләрне] аера алмаса – бозылмый» («Әл-Фәтава әл-Һиндия», 1/79).

Аллаһы яхшырак Белүче.

*Татарстан мөфтиятенең фәтвалар (дарул-ифта) бүлеге*